МӘГАРИФ

education

mәğәrif

просвещение

№4 / 2021

ТАТАР ТЕЛЕ

Оештыручысы:
«ТАТМЕДИА»
АКЦИОНЕРЛАР ҖӘМГЫЯТЕ

МӘГАРИФ education
mağarif просвещение
ТАТАР ТЕЛЕ

Декабрь, 2021 ел

№ 4

ЮСУПОВ Р. Телебез бозылмасын... 3

НУРМИЕВА Г. Укучыларыбызны фикерләргә өйрәтик 11

МИНҺАҖ Р. Туган телдән биздерү, яки Себер мәктәпләрендә татарлык ни хәлдә?...16

ФАИЗОВА Р. Мәктәптә милли кием һәм милли бизәк 23

ЙОСЫПОВА Ә. Онытылган сүзләр 29

НИГЪМӘТИ И. Татар әдәби телен баетучы чишмәлә 35

ФӘТТАХОВ И. «Без бетә торган кавем түгел...»..................................... 39

АКИРОВА Р. Предметның урыны. Кайда? 42

ГАЙНЕТДИНОВА Л. Исем сүз төркемен кабатлау 46

ХӨСӘЕНОВА Р. Синонимнар 51

ҺАДИЕВА Г. Китапчы галим 56

АНДРЕЕВА Е. Сыйфат турында төшенчә.. 65

ГАППАСОВА Р. Бәйлек сүзләр 71

ТИМЕРГАЛИЕВА Л. Эндәш сүзләр 75

ВӘЛИЕВА Л. Туган телем – дуслык теле 78

КАМАЛИЕВА Г. Сыйфат фигыль 83

ӘХМӘТШИНА А. Р.Фәхреддиннең «Әсма, яки Гамәл вә җәза» романы 89

ВОРОБЬЕВА Л. М. Мәһдиевның «Кеше китә – җыры кала» повестенда рухи-әхлакый мәсьәләләр чагылышы................................ 94

12+

УЧРЕДИТЕЛЬ: **АО «ТАТМЕДИА».**
Телефон редакции: (843) 222-06-09

Адрес издателя:
420097, г.Казань,
ул. Академическая, 2

www.magarif-uku.ru

Создано при поддержке Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям.

Зарегистрирован в Федеральной службе по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций 04.09.2014 г.

Эл № ФС 77 – 59204

Периодичность выхода – 1 раз в квартал.

Мнение редакции не всегда совпадает с мнением авторов. Редакция не располагает возможностью выступать ходатаем в официальных организациях. За достоверность рекламных объявлений ответственность несёт рекламодатель.

Почтовый адрес:
420066, г.Казань, а/я 47
e-mail: magarif@bk.ru

Адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.
«Мәгариф» журналы редакциясе, а/т 47
E-mail: magarif@bk.ru
Сайт: magarif-uku.ru
«Мәгариф», 2021 ел

Баш мөхәррир: **Таишева С.Н.**
Чыгаручы мөхәррир: **Фаизова Р.Г.**
Әдәби редактор: **Газизова И.М.**
Корректор: **Фәйзуллина Р.Ә.**
Вёрстка:
Зөфәрова Д.И., Шәрипова А.Г.

Беренче тышлыкта:
Асия Зимагулова Казанлы мәктәбендә 38 ел татар теле укыта. *Фото шәхси архивыннан*

Журналда кулланылган фотосурәтләр «Мәгариф» редакциясе архивыннан алынды.

Журнал распространяется бесплатно.

01

ТЕЛЕБЕЗ БОЗЫЛМАСЫН

Рүзәл ЮСУПОВ,

академик, филология фәннәре докторы

Соңгы елларда телебез мәсьәләсенең катлаулана баруы һәркемгә мәгълүмдер: татар телендә аралашучыларның саны азая, аны мәктәптә өйрәнү өчен мөмкинлекләр кими һәм иң хәтәре: кешеләрнең туган телләренә мөнәсәбәте, карашы битараф була бара. Болар турында матбугатта инде күп язылды, бу язмабызда без телебезнең сафлыгы, кулланылышының сыйфаты хакында әңгәмә корырга кирәк дип таптык.

Телнең кулланылышын кайгырту аның дөреслеген, чисталыгын, чын әдәби тел сыйфатын саклау белән янәшә барырга тиеш. Чөнки тел ул югары дәрәҗәдәге, дөрес, матур, күңелгә ятышлы, аһәңле, бай булганда гына үзенең иясе халыкка игелекле хезмәт итә, аның рухи ихтыяҗларын тулы канәгатьләндерә ала. Алдынгы җәмгыять вәкилләренең телләре дә нык үскән, камил төзелешле, сүзлек хәзинәсе мул тел булырга тиеш.

Шушы фикергә таянып эш иткәндә, без туган телебезнең югары таләпләргә ни дәрәҗәдә җавап бирүе белән даими кызыксынып, аны яхшы сыйфатлы итеп саклау чараларын күреп торырга тиеш. Бу бурыч хәзерге чорда аеруча актуаль. Чөнки объектив һәм субъектив сәбәпләр аркасында телебезне куллану мәсьәләсендә проблемалар кискенләшә, тәгаенрәк итеп әйткәндә, бүгенге татарча сөйләмдә, матбугат язмаларында, радио-телевидение тапшыруларында, әдәбиятта, башка төрле материалларда телебезне тупас бозып куллану күренешләре күп, һәм алар торган саен арта бара.

Телдән һәм язма сөйләмебезне игътибар белән тыңласаң һәм укысаң, аның һәрьяклап, һәр яссылыкта бозыла баруына инанасың. Кайбер сүзләр, тәгъбирләр еш кына ялгыш мәгънәдә кулланыла, табигый сүз төзелеше кагыйдәләре бозылып ясалган сүзләр дә шактый күп, сүзләрнең сөйләмдә үзара табигый мәгънәви бәйләнеше бозыла һәм бу бәйләнешне булдыручы грамматик чаралар ялгыш кулланыла, кайбер сүзләр стилистик яктан дөрес файдаланылмый, кайчакта сүз тәртибе бозыла, татар теленең кайбер авазларын әйтә белмиләр, сүз басымын һәм интонацияне дөрес билгеләмәү, сүзләрне ялгыш язу һәм тыныш билгеләрен куя белмәү күренешләре дә күп. Телдән һәм язма сөйләмебезнең бозылуы хәлләрен яза башлаганчы, шуны искәртеп кую мөһим: телебезне ялгыш куллану күренешләренең күп булуы һәм аларның торган саен арта баруының төп сәбәпләре: туган телне укыту сыйфатының гомумән алганда тиешле дәрәҗәдә булмавы, каләм белән эш итүчеләрнең күбесенең телне камил белмәве, аны дөрес куллануга катгый таләпләр куелмавы һәм күп кешеләрнең туган телләренең сафлыгына, дөреслегенә, матурлыгына битараф, ваемсыз караштa булуы, икенче төрле итеп әйткәндә, сөйләм культуралары түбән булуы.

Бүгенге татарча мәгълүмат чараларында телне бозып куллану күренешләренең күп булуының тагын бер җитди сәбәбе каләм ияләренең күбесенең дөрес тәрҗемә итә белмәвендә. Мәгълүм булганча, безнең илдә тормышның барлык өлкәләренә дә караган бөтен әһәмиятле информация, төрле халыкларга, нигездә, рус теле аша ирештерелгәнлектән, руслардан башка кешеләр аны үзләренә күпчелек очракта шушы телдән тәрҗемә итеп алалар. Безнең татарча матбугат һәм радио-телевидение дә, мәгариф тә, әлбәттә, үзләренә кирәкле мәгълүматның күбесен рус теленнән тәрҗемә итеп ала. Ләкин бу эшне башкаручылар, тәрҗемә итү һөнәренә махсус өйрәтелмәгәнлектән, гадәттә, күп хаталар җибәрәләр: кайчакта оригиналның мәгънәсен дөрес белдермиләр, күбесенчә татар телен бозып язалар һәм сөйлиләр. Шулай итеп, монда ике ялгыш күренеш -- татар һәм рус телләрен бөтен үзенчәлекләре белән белмәү һәм аларны берсеннән икенчесенә дөрес тәрҗемә итү һөнәрен үзләштермәгән булу күренешләре, бергә кушылып, татар телендәге информациягә зур хилафлык китерә.

Хәзер телебез кулланылышындагы проблемалар хакында әйтелгән фикерләребез дәлилле булсын өчен, бүгенге газета-журналларда, төрле китапларда, радио-телевидение тапшыруларында һәм сөйләмебездә аеруча күп очрый торган тел ялгышларының кайберләрен карап китәрбез һәм укучыларга аларның әдәби дөрес вариантларын тәкъдим итәрбез.

Бүгенге көндә язма һәм сөйләмә телебезнең ялгыш кулланылуы очраклары, әй

телгәнчә, күптөрле һәм күпсанлы. Бигрәк тә еш очрый торганнары шушылардан гыйбарәт: кайбер сүзләр, тәгъбир-әйтелмәләр (сүзтезмәләр) ялгыш мәгънәләрдә кулланыла, сөйләмдә сүзләрнең мәгънәле бәйләнеше бозыла, сүзләрнең семантик бәйләнешенең грамматик чаралары дөрес билгеләнми, кайбер очракларда татар теленең табигый сүз төзелеше бозылып ясалган лексик чаралар кулланыла, алынма сүзләрдән дөрес файдаланылмый, фигыль сүз төркеме формалары дөрес кулланылмый, диалектизмнар һәм гади сөйләм сүзләрен куллануда ялгышлар бар, кайчакта сөйләмдә табигый сүз тәртибе бозыла, сүзләрнең стилистик кулланылышында хаталар китә, телнең кайбер авазлары ялгыш әйтелә, сүзләрнең дөрес язылышы кагыйдәләре бозыла һәм башка төрле хаталар ясала.

Сүзләрне дөрес мәгънәләрендә куллана белмәү соңгы елларда телебездә киң таралган ялгышларның берсен тәшкил итә. Шуларның кайберләрен мәгълүмат чараларыннан һәм кайбер китаплардан алынган мисалларга анализ ясау рәвешендә күздән кичерик.

Авыл, авыл советы, берләшмә һәм башка шундый мәгънәләрдә хәзер, рус телендәге *поселение* сүзен ялгыш тәрҗемә итеп, *җирлек* сүзен кулланалар: «Бу авыл *җирлегендә* берничә милләт вәкиле яши» («Бу авылда ... яши» кирәк); «Күгеш җирлеге халкы яңа клуб көтә» («Күгеш авылы халкы...» яки «Күгеш халкы...»); «Алан-Бәксәр авыл *җирлеге* башлыгы...» (дөресе – «Алан-Бәксәр авылы башлыгы...»). *Җирлекнең* башлыгы була алмый: *җирлек* чын татарча – *җир, нигез, төс, фон, чыганак, нигез, шарт, мөмкинлек* мәгънәләрендәге сүз.

2020 нче елда, мәгълүм сәбәпләр аркасында, үлем-җитемнәр күп булды. Бу уңайдан газеталарда якты дөньядан мәңгегә киткән кешеләр белән аерылышу мәгънәсен *хушлашу* сүзе белән белдереп язалар. Мәсәлән, «...диктор Илфат Абдрахманов белән *хушлаштылар*». Бу – тупас хата. *Хушлашу* ул – исән кеше белән *саубуллашу*, ә үлгән кеше белән яки үлем алдындагы кеше белән *бәхилләшәләр.*

Кайбер каләм ияләре ярлы, фәкыйрь, мохтаҗ, авыр хәлле кешене *хәерче* дип атый: «Җитәкчелек *хәерчеләр* санын киметмәкче» (дөресе – «...*ярлылар* санын киметмәкче»). *Хәерче* ул *ярлы* түгел, *ярлы хәерче* дигән сүз түгел.

«Бакча нигъмәтләрен кышка *туңдырабыз».* Кешеләрне һәм башка җан ияләрен генә туңдырып була, ә җансыз нәрсәләрне туңдырмыйлар, *өшетәләр, катыралар.* Безнең кайбер журналистларыбыз хәтта әйбер бәясен дә катырып куялар: «Хөкүмәт... үсемлек мае *бәясен катырырга* җыена» (дөресе – «...үсемлек мае *бәясен үзгәртмичә* (күтәрмичә) торырга җыена»).

Кыйммәт сүзен күбесенчә ялгыш мәгънәдә кулланалар. Моның сәбәбе – рус телендәге *ценность* сүзен тәрҗемә итә белмәү.Журналистлар күп очракта оригинал сүзенең төрле мәгънәләре арасыннан (сүзләр барлык телләрдә дә, нигездә, берничә мәгънәле) тәрҗемә телендәге конкрет сөйләм (текст) таләп иткәнен белдерерлек тәңгәллекне сайлап ала белмиләр, дөресрәге, аны эзләп, көчләрен түкмичә, башларына беренче килгән вариантын гына кулланалар, һәм нәтиҗәдә тәрҗемә теленә ялгыш мәгънәдә кулланыла торган сүз кереп урнаша: туган телнең дөрес сөйләм нормасы (кагыйдәсе, тәртибе) бозыла. *Ценность* сүзенең татар телендәге *бәһа, әһәмият, кыйммәтле әйбер (нәрсә), байлык, хәзинә* дигән һ.б. мәгънәләрендәге тәңгәллекләрен белмичә яки исәпкә алмыйча, аны күп очракта *кыйммәт* сүзе белән тәрҗемә итеп, мәгънәсез, аңлашылмый торган әйтелмә-тәгъбирләр китереп чыгаралар. Мәсәлән, *рухи кыйммәтләр* диләр. Дөресе – рухи хәзинәләр яки байлыклар. «*Ул көннең кыйммәте* елдан-ел арта». «Ул көннең әһәмияте (кадере) елдан-ел арта» дияргә кирәк. «Фәридә Сөнгатова кебек *җырчыларыбызның кыйммәте* ныграк беленә». Дөресе – «...*җырчыларыбызның кадере* ныграк беленә».

Русларның *призвать (призывать)* сүзен һәр очракта *чакыру* дип тәрҗемә итү аркасында да хәзер татар телендә зур ялгышлар хөкем сөрә. Мәсәлән, бер газетада «Арча читекләрен Германиягә соратып алдылар» дип әйтәсе урында «...Германиягә *чакыртып алдылар*» дип яздылар.

Армиягә алуны да армиягә чакыру диләр: «Армиягә *чакырылыш* план буенча бара». «*Армиягә алу* план буенча бара» кирәк. *Кушу, өндәү, таләп итү,* тәкъдим итү һәм башка сүзләр урынына да *чакыру* сүзен кулланалар: «Анна Попова, коронавирус инфекциясе белән зарарлану аркасында, балаларны көньякка алып бармаска *чакыра»* («...көньякка алып бармаска өнди»), (*куша, барырга кирәкми, ди* һ.б. дип әйтергә кирәк).

Просить сүзен дә күп урында *сорау* дип ялгыш тәрҗемә итәләр. Мәсәлән, «Кондуктор пассажирдан битлек киюне *сорый*». Дөресе – «...битлек кияргә куша, яки битлек киюен *таләп итә».*

Алдагы сүзен еш кына ялгыш *элекке, үткән* сүзләре урынында кулланалар: «2019 елда Татарстанда 3,6 миллион турист булып киткән. *Алдагы елдан* 6 процентка күбрәк бу» («...*Элекке елдан* ...күбрәк бу» кирәк).

Сүзләрнең ялгыш мәгънәдә кулланылуы турында сөйләгәндә, шуны әйтү урынлы булыр иде. Соңгы берничә дистә елда тел белән эш итүче кешеләрнең аннан саксыз файдаланулары, аңа ваемсыз, битараф караулары аркасында, татар теле күп кенә ялгыш, мәгънәсез, сәер, аек акыл белән аңлап булмый торган әйтелмә, тәгъбир, сүзләр белән чуарланды, чүпләнде.

Кайбер каләм һәм сүз ияләренең халык телендә күптәннән кулланылып килгән, һәркемгә аңлаешлы сүзләрне, үзбелдекләләнеп, үзгәртеп куюларын аңлап булмый. Мәсәлән, татарларда гасырлар буена диярлек кулланылып килгән *союз* сүзен *берлек* белән алмаштыруларын эш юктан эш ясап, мөгез чыгару дип әйтми мөмкин түгел. *Берлек* ул – *бер сум акча*, лингвистика термины, *бердәмлек, ныклы бәйләнеш, уртаклык* мәгънәләрендәге сүз, *союз* исә – дәүләт берләшмәсе (Советлар Союзы), оешма. Шулай булгач, татар теленең үз сүзе кебек бөтен кешегә мәгълүм союзны тиешле мәгънәне төгәл белдерми торган берлек сүзе белән алмаштырып кую кемгә кирәк булган икән? *Язучылар союзы, Журналистлар союзы, Советлар Союзы* атамалары кемгә ошамаган икән?

«Сәхнәләрнең бер өлеше Казан үзәгендә төшерелде» (сүз кинога төшерү турында бара. – *Р.Ю.*). *Күренеш (сцена)* сүзен ничек *сәхнә* белән бутарга мөмкин?

Рәсем астына *фәлән кеше эше* дип язып кую гадәткә керде. Мәсәлән, «Казанны камау. В.Бодрова эше». Ни өчен В.Бодрова *рәсеме* дип язмаска?

Хәзер *әйтте, белдерде, диде, сөйләде* кебек сүзләр урынында еш кына *җиткерде* сүзен кулланалар. Ни өчен? «Бу хакта... Александр Шадриков *җиткерде*» (дөресе – «...*әйтте*»). «С.Мамонтов аңа шундый сүзләрне *җиткерә»* («...сүзләрне *әйтә* яки *сөйли*»).

Рус теленең *к сожалению* сүзен *кызганыч* дип тәрҗемә итеп куллану гадәткә керде. Бу дөрес түгел, әлбәттә. «*Кызганыч*, республика буенча төгәл саннарны белә алмадык».Монда бернинди дә *кызгану* мәгънәсе юк. Кызганыч урынында *аяныч* сүзе кулланылырга тиеш.

Инвалидлык группасын төркем дип атау да дөрес түгел, монда төркемнең катнашы юк. «Мин – 1 нче *төркем инвалид*». Дөресе – «Мин – 1 нче *группалы инвалид».*

Кайчакта шулкадәр уйламыйча язылган нәрсәләр очрый, аларны аңлау да мөмкин булмый. Мәсәлән, «Без укыган елларда укытучылар балаларга *йөз белән карыйлар иде»* (тагын нәрсә белән карарга мөмкин икән?).

«...республика күләмендә *соры хезмәт базары* эшләп килә». Нәрсә икән ул *соры хезмәт базары?*

«Аның һәр җыры, биючесе – *бәһасез хәзинә». Бәһасез хәзинә* буламы икән?

«Аны (файдалы ризыкны. – *Р.Ю.*) *нәсел утарыннан алу* яхшырак». «... *үз бакчаңнан (үз хуҗалыгыңнан) алу»* дияргә кирәк булгандыр, бәлки.

Сүз ияләренең күбесенең язганда һәм сөйләгәндә җитди ялгышлар җибәрүе, тәрҗемә методлары һәм принципларыннан хәбәрдар булмыйча, рус теленең күп сүзләрен һәм сүзтезмәләрен хәрефкә-хәреф тәрҗемә итүләрендә, ягъни калькалаштырып алуларында чагылыш таба. Бу күренеш – бүгенге көндә телебезнең бозылуындагы төп бәла. Татар теленең сүзлек составы хәзер көннән-көн рус те

леннән ялгыш калькалаштырылган бозык сүзләр белән тутырыла бара. Сәбәбе: каләм һәм сүз ияләре күп очракта тиешле мәгънәне белдерерлек сүзне татар теленең үзеннән эзләп тормыйлар, бераз гына булса да башларын ватып, уйлап эш итәргә теләмиләр, бәлки рус сүзләренең татар телендә иң еш кулланыла, ике тел сүзлекләрендә теркәлгән һәм зиһеннәренә беренче килгән тәңгәллекләрен генә кулланалар. Нәтиҗәдә ул тәңгәллек дип саналган сүзләр тиешле мәгънәне төгәл белдермиләр һәм татар теле өчен дөрес, табигый булып чыкмыйлар. Хәзер шул рәвешле телебездә ялгыш кулланыла торган сүзләр меңнәрчә исәпләнә. Без бу язмабызда шундыйларның аеруча еш очрый торганнарын күрсәтербез.

Саннарны яңгырату, чынбарлыкны яңгырату, сорауларны, гаепләүләрне, җан ачысын, мәзәкне,идеяләрне, тәкъдимнәрне, мәсьәләләрне, теләкләрне, фикерләрне, мәгълүматларны, җавапларны, чагыштыруны, сүзләрне һәм тагын әллә нәрсәләрне яңгырату дип язалар һәм сөйлиләр хәзер. Боларның берсе дә саф татарча түгел. Бу һәм башка бик күп гарип әйтелмә-тәгъбирләрдәге яңгырату урынында *белдерү, әйтү, китерелү, бирелү, ясалу һәм башка сүзләр кулланылырга тиеш*.

Рус телендәге *расти, развиваться* сүзләрен күп очракта үсү дип тәрҗемә итү аркасында, хәзер телебездә йөзләрчә табигый булмаган сүзтезмәләр кулланыла. *Хезмәттәшлек, мөнәсәбәтләр үсә (хезмәттәшлек, мөнәсәбәтләр киңәя, ныгый һ.б. кирәк), нәфрәт үсә (нәфрәт көчәя), сыйфат үсә (сыйфат күтәрелә, яхшыра), чыгымнар үсә (арта), бәяләр үсә (бәяләр арта, күтәрелә), хәл үсә (хәл киеренкеләнә), авыру үсә (авыру көчәя), омтылыш, куркыныч, җинаятьчелек, сан, канәгатьсезлек* һәм тагын әллә нәрсәләр *үсә* дип язалар һәм сөйлиләр кайберәүләр. Болар һәм *үсү* сүзе белән ясалган башка күп әйләнмәләр чын татарча түгел.

Тере тавыш, тере акча, тере традиция, тере тәгълимат кебек *тере* сүзе белән ясалган тузга язмаган тәгъбирләр торган саен ныграк тарала бара.

*Текә егетләр*дәге кебек *текә* сүзе (*крутой*ның калькасы) белән килгән гайре табигый әйтелмәләрнең модага керүен дә дөрес хәл дип әйтеп булмый.

Рус теленең *глубокий* сүзен күбесенчә, хәрефкә-хәреф әйләндереп, *тирән* дип кенә тәрҗемә итү аркасында ялгыш ясалган сүзтезмәләр хәзер телебездә йөзләрчә санала: *тирән рәхмәт (зур рәхмәт), тирән кайгы (зур кайгы), тирәнтен өйрәнү (ныклап, яхшылап өйрәнү), тирән йоклау (изелеп, тәмләп, рәхәтләнеп йоклау)* һ.б.

«Иреннәрем калын, ә аныкы неп-нечкә». Татарчаны уртача гына булса да белгән кеше болай дип әйтмәс, *юка ирен* дияр, ә телне яхшы белергә тиешле журналист кеше нечкә ирен дип яза.

«Газетаның 95 яшьлеген бәйрәм итәләр». Дөресе – «*газетаның 95 еллыгы»: яшьлеге (яшь)* дип кешеләргә һәм хайваннарга карата гына әйтелә.

«Машиналар хәрәкәт итә». Татарча – *«Машиналар йөри»*, машинаның детальләре, частьлары гына *хәрәкәтләнә*.

«Бәйрәмнәрдә олы ямьнәр бар»: ямь олы яки кече була алмый. *«Бәйрәмнәр бик ямьле* яки *матур була*» дияргә кирәк.

Рус телендәге *предупредить* сүзен һәр очракта да кисәтү дип ялгыш тәрҗемә итү аркасында, хәзер телебездә дистәләрчә гайре табигый тәгъбирләр кулланыла: *һәлакәтләрне кисәтү, авыруны кисәтү, хокук бозуларны кисәтү, җиләк куакларының өшүләрен кисәтү* һ.б. Бу һәм башка шундый сүзтезмәләрдә *кисәтү* урынында *булдырмау, булдырмый калу, саклану* кебек сүзләр кулланылырга тиеш. Чын татарча кисәтү кешегә карата гына кулланыла.

«Аяклары калын» дип яза кайсыдыр бер каләм иясе, татарча аякның юан яки нечкә булуын, ә *калын* яки *юка* дип такта, кәгазь кебек яссы нәрсәләргә карата әйтелүен дә белми ул, димәк.

Сократить сүзен ялгыш тәрҗемә итеп, күп хаталар ясыйлар: *мәктәпләрне кыскарту, хезмәт хакын кыскарту,чыгымнарны кыскарту, эшчеләрне кыскарту* һ.б. Бу һәм башка әйтелмәләрдә *кыскарту* урынында *киметү, ябу, эштән чыгару, бетерү* кебек сүзләр кулланылырга тиеш.

Журналистларның тиешле мәгънәне белдерү өчен татар теленең бай сүзлек хәзинәсеннән лаеклы, кирәкле сүзне эзләп алып файдаланмыйча, механик рәвештә, уйлап тормыйча, рус сүзенең башына беренче килгән тәңгәллеген генә (кайчак ул чын тәңгәллек тә булмый) кулланып эш итүләренә гаҗәпләнергә һәм шул рәвешле телебезне тупас бозуларына гарьләнергә генә кала.

Кайбер язмаларда адым саен сүзгә-сүз, хәрефкә-хәреф тәрҗемәгә юлыгасың.

«Алдагы көннәрдә дә җылы булачак» дип әйтәсе урында *«Җылы һава торышы алдагы тәүлекләрдә дә дәвам итәчәк»* диләр, *«ВТның кайнар линиясенә һәр көнне бик күп кешеләр шалтырата»* дип әйтмичә, «ВТ кайнар линиясе көн саен бик күп шалтыратулар кабул итә» дип мөгез чыгарып язалар, *«Редакциябезгә тагын бер кеше шалтыратты»* дип әйтәсе урында *«Редакциябезгә тагын бер шалтырату алдык»* дип язалар, *«Сәламәт яшиләр», «Дөрес яшиләр»,«Актив яшиләр»* дип әйтмичә *«Сәламәт яшәү рәвеше алып баралар», «Актив яшәү рәвеше алып баралар»* диләр.

Рус теленең *вести* сүзен, гомумән, бик күп очракларда ялгыш *алып бару* дип ялгыш тәрҗемә итәләр. Мәсәлән: *«Алар 30–40 яшьтә барысы да хуҗалык алып бара».* Кая алып баралар алар хуҗалыкны?! *«30–40 яшьтәгеләрнең барысының да үз хуҗалыклары бар»* дип әйтергә ярамыймы икән? *«Тәртипсез тормыш алып барган өчен...»* Чын татарча: *«Тәртипсез яшәгән өчен», «Лев Толстой уку эшчәнлеге дә алып бара». «Нинди була икән ул «уку эшчәнлеге?» «Лев Толстой уку белән дә шөгыльләнә»* дип язарга яки сөйләргә ярамыймы икән әллә?

Безнең каләм ияләренең кайберләре еш кына язганда яки сөйләгәндә төп эш кораллары телләренә шулкадәр җавапсыз карыйлар: теге яки бу сүз, әйтелмә, җөмлә татарча дөресме-юкмы икән дип уйлап та тормау гына түгел, хәтта аларның мәгънәсе аңлашыламы-юкмы икәнлеге турында да уйланмыйлар. Мисаллар:

Работать над чем-то әйтелмәсен хәрефкә-хәреф тәрҗемә итү аркасында телебезгә *фәлән нәрсә өстендә* эшләү рәвешендәге гарип тәгъбирләр кереп урнашты, һәм алар инде дистәләрчә еллар иркен кулланыла. Моның шунысы гаҗәп: беркем дә болай татарча әйтергә ярамый бит дип, аларны төзәтергә теләми.

«Сәламәтләндерү өстендә эшләү?!» «Сәламәтләндерү белән шөгыльләнү» дисәң, чын татарча да, аңлаешлырак та булыр иде.

«...үз өсләрендә нык эшлиләр» («белемнәрен, осталыкларын, һөнәрләрен һ.б.ны күтәрәләр, камилләштерәләр, шомарталар» һ.б. кирәк).

«Конституция өстендә эшләү»» («Конституция проектын төзү», «Конституция текстын камилләштерү, төзәтү» һ.б.).

«Җырларым өстендә эшләдем» («Җырларымны әзерләдем» һ.б.).

«Филолог галимнәр әзерләүдә үземнең тыйнак кына өлеш кертә алуым белән горурланам» дип яза бер фән докторы. Филолог галимнәр әзерләү хокукы алган кешенең татарча *«тыйнак өлеш»* булмаганлыгын, аны «үземнең бернигадәр, аз гына, кечерәк кенә булса да һ.б. өлешемне кертүем» дип әйтергә кирәклеген белмәве – бик аянычлы хәл.

«...урамындагы *тыйнак* йортка сукмакны онытмыйлар». *Йорт тыйнак булмый, кечкенә, зур, уртача зурлыкта, мәһабәт, матур, шыксыз* һ.б. була. *Тыйнак* дип кешегә карата гына әйтәләр.

Тонкий (ая, ое) сүзен шулай ук, уйлап тормыйча гына, күп очракта нечкә дип тәрҗемә итәләр, һәм нәтиҗәдә адәм аңламаслык тәгъбирләр барлыкка килә: *нечкә мәсьәлә* (катлаулы, четерекле мәсьәлә), *нечкә тема* (моны ничек аңларга?), *нечкә эш* (катлаулы, нәзакәтле, четерекле һ.б.эш) , *нечкә дәфтәр* (дөресе – юка дәфтәр).

«Бу бик тә *нечкә сорауны* Сталинга бирергә сакчы полк командирына йөклиләр» («...авыр, катлаулы, четерекле һ.б. сорау бирүне... йөклиләр» кирәк).

«Укытып чыгару *көн тәртибенә менде». «*Көн тәртибенә куелды яки кертелде» дип әйтелә бит татарча.

«Күзгә-күз сөйләшү», «күзгә-күз аралашу» дигән тәгъбирләр дә керттеләр телебезгә безнең калькалаштыручы журналистларыбыз (*с глазу на глаз* әйтелмәсеннән калька). Әмма чын татар ул мәгънәне *икәүдән-икәү* (генә) дип белдерә.

Кайбер журналистлар сәләтләрен татар теленең байлыгыннан, сүзлек хәзинәсеннән, образлылык көченнән тулы, оста файдалануда күрсәтмичә, ялгыш, мәгънәсез, уңышсыз сүзләр, тәгъбирләр, ниндидер, сәер тел чаралары, тузга язмаган сүз-әйтелмәләр уйлап чыгаруда күрсәтеп маташалар.

Соңгы елларда шундый мөгез чыгаруларга *җиткерү* сүзен урынсыз куллану карый. «Татарстан парламенты башлыгы ... докладларын эшләү турында *җиткерде*» («... докладларын эшләү турында сөйләде яки ...*әйтте*» кирәк); «... дигән фикерне *җиткерделәр*» («... фикер *әйттеләр* яки *белдерделәр*»).

«Редакциягә килгән хатларда – тормыш кыйпылчыклары». Нәрсә икән, нинди була икән ул «тормыш кыйпылчыклары»?

«Ак хакыйкать» (мәкалә исеме). Моны ничек аңларга икән? Хакыйкать шулай төсләргә дә бүленәме икән әллә?

«Түбән Кама театры... *хәрәкәт-биюле спектакль чыгара*». Спектакльне ни өчен һәм кая «*чыгаралар*», ни өчен, гадәттәгечә, «*куймыйлар*»? *Хәрәкәт-биюле спектакльне* ничек аңларга икән: хәрәкәтсез бию дә буламы икән әллә?

«...фатирдан чыга алмый яткан арбалы инвалидларга... булыша». Монда сүз коляскалы инвалид турында бара, әлбәттә. Әмма шунысы гаҗәп: журналист булып эшләгән кеше нишләп колясканы арбадан аера белми икән?

«Ләкин бу клубта *милли сорау* күтәрелмәде...» *Милли сорау* булмый, монда сүз милли мәсьәлә турында бара, әлбәттә. «Бу сорау белән җентекләбрәк шөгыльләнергә кирәк». Дөресе – «Бу мәсьәлә белән ... шөгыльләнергә кирәк». Газета чыгаручы һәм газетага язучы кешеләр *сорау* белән *мәсьәләне* бутарга тиеш түгелдер ләбаса.

Кайбер каләм ияләре язганнарын үзләре аңлыйлармы икән дигән сорау туа. Мисал өчен менә бу ике җөмләгә күз салыйк: «Женни йөзендә Маркс авыр тормышының ышанычлы юлдашын, тугрылыклы дустын таба»; «Сезнең йөзегездә... сәламлим». Укучы мондый текстларны ничек аңлый һәм аңлыймы икән? Аңлашылсын һәм татарча дөрес булсын өчен, аларны болайрак итеп төзергә кирәк: «Женни Маркcның ... дусты һәм көрәштәше булды»; «Сезнең аша бөтен Россия халкын сәламлим».

«Шушы хис мине көне буена озатып йөрде»; «Балачак хатирәләре гомер буе озата килде». «Хис озатып йөрде» һәм «хатирәләр озата килде» татарча табигый метафорик әйтелеш түгел. Аларны «Шушы хистән мин көне буе арынып тора алмадым»; «Балачак хатирәләре гомерем буена сакланды (сакланып килде)» рәвешендә төзергә кирәк иде.

Татар теленең үзенә генә хас үзенчәлекләрен, хасиятен тулы белмичә, үз теленә чит тел өлгеләрен механик, автоматик рәвештә күчереп кую методы белән эш итү туган телебезнең табигый төзелешен, хосусиятен җимерә, нигезен какшата, үзенә күрә бер корама, ясалма телгә әверелдерә бара.

Татарлар гомер-гомергә, ниндидер транспортка утырып яки җәяү баруларына карамастан, *фәлән җиргә барам яки фәлән җирдән кайтам* дип, ни рәвешле баруны яки кайтуны тәгаенләп әйтергә кирәк булганда, *машинага (поездга, пароходка, самолётка) утырып барам (бардым, барачакмын)* яки *кайтам (кайттым яки кайтачакмын)* дип сөйлиләр. Транспорт чараларының хәрәкәт итүе мәгънәсендә *машина (пароход, теплоход, поезд, самолёт) килә, китә, бара* дигәннәр. Бу – безнең тел өчен табигый күренеш, аның специфик үзенчәлеге.

Ә хәзер безнең телдә нинди галәмәтләр хөкем сөрә? Рус һәм татар сүзләренең үзенчәлекләрен, мәгънәләрен һәм мәгънә төсмерләрен аңлап бетермичә, рус теленә генә хас формаларны, уйлап

тормыйча гына, татар теленә көчереп кую ысулы эш итү аркасында, телебезнең нигезендә яткан милли үзенчәлекләре чит тел өлгеләре (формалары) белән алмаштырыла бара. Мәсәлән, «*Президент (самолёт белән) Мәскәүгә китте*» диясе урында *«Президент Мәскәүгә очты»* диләр. *«2020 нче елның мартында мин Казаннан Мәскәүгә очтым» (дөресе – «...Казаннан Мәскәүгә киттем»). «Бер төркем татарстанлы Мәккәгә хаҗ кылырга очты» («...Мәккәгә самолёт белән хаҗ кылырга китте»* кирәк).

«Киң Дунай аркылы ашыгып көймәләр йөзә» (дөресе – «Киң Дунай аркылы, ашыгып (тиз-тиз) көймәләр йөри, килә, бара»). Балык йөзеп йөри, йөзеп килә, ә көймә, теплоход, корабль килә, китә, бара гына («Килә-китә, гүләйт итә Усиядә (Устьеда.–*Р.Ю.*) пароход» дип җырлыйлар иде элек).

Мәгълүм булганча, һәр телнең дә сүзләре, нигездә, күп мәгънәле. Һәм төрле телләрнең тәңгәл дип саналган сүзләре үзара барлык мәгънәләрендә дә түгел, бәлки кайбер мәгънәләрендә генә бер-берсенә туры киләләр. Димәк, ике яки берничә тел сүзләренең бер-берсенә туры килүен тәңгәллекләр дип шартлы рәвештә генә аңларга кирәк. Мәсәлән, гомумән үзара тәңгәл саналган *земля* сүзенең С.И.Ожеговның аңлатмалы сүзлегендә 6 мәгънәсе теркәлгән (асылда, алар тагын да күбрәк), ә «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *җир* сүзенең 27 мәгънәсе теркәлгән. Шулай булгач, земля белән җир барлык мәгънәләрендә дә берничек тә тәңгәл була алмыйлар. Шунлыктан бер телдән икенче телгә тәрҗемә иткәндә, ул ике телнең теге яки бу сүзенә үзара тәңгәллекне бары тик билгеле бер (конкрет) контекстта (сөйләмдә) шул текстта (сөйләмдә) белдергән мәгънәсенә карап кына билгеләргә мөмкин. Бу күренеш – тәрҗемә эше өчен иң әһәмиятле принцип. Русчадан татарчага тәрҗемә итү белән шөгыльләнүчеләр еш кына ул принципны исәпкә алмыйлар, һәм шуның аркасында бүгенге татар телендә меңнәрчә хаталар, туган телнең бозылуы күренешләре хөкем сөрә.

Рус телендәге *крупный* сүзе белән татар телендәге төп мәгънәсе буенча аңа туры килә торган *эре* сүзе барлык мәгънәләре буенча да үзара туры килеп бетми. Әмма безнең каләм ияләре, моны исәпкә алмыйча, *крупный* сүзен һәрвакыт диярлек *эре* дип тәрҗемә итәләр. Нәтиҗә, әлбәттә, аяныч булып чыга: татар теленең сөйләм кагыйдәсе тупас бозыла. *Эре,* нигездә, бөртекле, бүлбеле үсемлекләргә, азык-төлеккә карата кулланыла: *эре орлык, эре бәрәңге, эре помидор* һ.б. *Крупный* сүзе еш кына зур күләмле предметларга, әһәмияте, йогынтысы буенча зур нәрсәләргә карата да иркен кулланыла. Мәсәлән, русча *крупное хозяйство, крупный капитал, крупный учёный, крупный писатель* дип әйтелә. Әмма татарча *эре хуҗалык, эре капитал, эре язучы,эре галим* дип әйтү табигый булмый: *зур хуҗалык, зур капитал, зур язучы, зур галим* диләр. Рус теленнән калькалаштырып алынган *эре шәһәрләр, эре предприятиеләр, эре җитәкче, эре районнар, эре ширкәт, эре завод, эре кибет, эре оешма, эре дәүләт, эре ил* һәм башка бик күп эре нәрсәләр тулып ята. Аларның берсе дә саф татарча түгел, барысында да *эре* урынында *зур, олы* һ.б.ш. сүзләр кулланылырга тиеш.

Төп мәгънәләре белән тәңгәллекләр саналган *погибнуть* һәм *һәлак булу* сүзләренә дә әле әйтеп киткән күренеш хас: монда да рус телендәге *погибнуть*ның *(гибнуть)* барлык мәгънәләрен дә *һәлак булу* сүзе ярдәмендә белдерү мөмкин түгел, чөнки рус сүзенең, башка сүзләр белән мәгънә бәйләнешенә кереп, әйтелмәләр төзү сәләте *һәлак булудан* киңрәк. Әмма русчадан татарчага тәрҗемәләрдә бу тәңгәллекләрнең үзенчәлекләре күп очракта исәпкә алынмый. Мәсәлән: «*... терлекләрнең һәм чәчүлекләрнең һәлак булуына китерә» (дөресе – «...терлекләрнең үлүенә һәм чәчүлекләрнең бетүенә (юкка чыгуына, харап булуына) китерә»). «Бактерияләрне һәлак итүче матдәләр» («Бактерияләрне юкка чыгара (юк итә) торган матдәләр»).* Кайбер каләм ияләре *«фәлән кеше больницада һәлак булды»* дип язалар. Дөресе – *«больницада үләләр, ә сугышта* һәм төрле *бәла-казадан һәлак булалар».*

02

УКУЧЫЛАРЫБЫЗНЫ ФИКЕРЛӘРГӘ ӨЙРӘТИК

Гөлгенә НУРМИЕВА,

татар телендә белем бирүче 27 нче гимназиянең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Соңгы елларда балага белем генә түгел, тәрбия бирүнең дә мөһимлеге хакында югары даирәләрдә дә аңлый башладылар. Туган тел һәм әдәбият дәресләре – укучының иҗади фикерләү куәсен арттыру, аның уй-фикерләрен, теләк-омтылышларын белгеләргә ярдәм итә алырлык, шул ук вакытта менә дигән тәрбия чарасы. Үземнең эш тәҗрибәмнән чыгып, әлеге дәресләрдә кулланырга мөмкин булган критик (тәнкыйди) фикерләү технологиясенә, аның кайбер үзенчәлекләренә тукталып китәм.

Критик фикерләүне үстерүгә нигезләнгән технология укучыларны иҗади фикер йөртергә өйрәтә һәм аңа өйрәтү алымнары шактый күптөрле. Әмма шуны истә тотарга кирәк: бер дәрес эчендә бөтен алымнарны бергә кушу дөрес түгел, икедән артык алым куллану кирәкми. Критик фикерләү сәләтен үстерүгә нигезләнгән дәрес түбәндәгеләрне истә тотып төзелергә тиеш: һәр алымнан соң фикер алышу уздыру мөһим. Бер алымнан икенче алымга күчү логик яктан уйланылган булырга тиеш.

Укучыларның кызыксынуларын арттыру максатыннан ситуацияләр тудыру мөһим. Алар үз-үзләренә түбәндәге сорауларны бирерлек булсын: «Әлеге материалны өйрәнү миңа нәрсә бирәчәк?», «Сорауга җавап табар өчен мин нәрсәләргә өйрәнергә тиеш?» Сорауларны укучы фикер йөртеп җавап бирерлек итеп куя белергә кирәк, алар нәтиҗәне үзләре ясасын, үзләренең эшчәнлекләренә үзләре үк бәя бирә алырлык булсын. Балаларны җавап бирергә генә түгел, ә сорау бирергә дә өйрәтү мөһим.

Дәреснең төп герое укытучы түгел, укучы булырга тиеш. Балалар үзләренең фикерләрен һәм идеяләрен кычкырып әйтә белсеннәр, я булмаса, теге яки бу формада язып бирсеннәр. Укучы үзенең идеяләреннән, иҗади фикерләреннән канәгатьләнү хисе алырлык булсын. Андый балаларны вакытында күрә белергә, аларны үстерергә, канат куярга кирәк. Дәрестә бер-ике балага гына түгел, ә теләгән һәр балага сүз бирү мөһим. Гадәттә шулай була: укытучы үзе теләгән, ягъни үзе дөрес дип тапкан җавапны алуга, башка укучыларның фикерен тыңлап торуга вакыт сарыф итүне кирәк дип тапмый. Бер тапкыр үз фикерен җиткерергә теләп тә, көтелгән нәтиҗәгә ирешә алмаган укучының кабат җавап бирергә теләге башка уянмаска да мөмкин. Без үзебезнең фикер белән тәңгәл килмәгән фикерне дә хөрмәт итәргә тиешбез. Бу бигрәк тә әдәбият дәресләренә кагыла. Берьяклы гына фикерләүчеләрне хуплап, иҗади фикер йөртә белүче укучыларны югалтабыз. Безнең гимназиягә ачык дәресләргә килгән укытучылар укучыларымның курыкмыйча үз фикерләрен җиткерә алуларына, бер-берсенең фикерен тулыландыра белүләренә, я булмаса, капма-каршы фикер әйтеп бәхәсләшә алуларына игътибар итәләр. Мин үз укучыларымны «Укучылар, фикер тәнкыйтьләнми»,– дип өйрәтәм. Шуңа күрә дә алар үз фикерләренең укытучы тарафыннан кабул ителәчәгенә шикләнми. Әлбәттә, сөйләшү азагында укытучы, теге яки бу рәвештә, бер якны да кимсетмичә, үзе дөрес дип санаган нәтиҗәне ясарга тиеш. Шул ук вакытта бу зур осталык, компетентлылык таләп итә. Мисал итеп, бишенче сыйныфта өйрәнелүче «Кояштагы тап» әсәрен мисал итеп китерәм. Әсәргә анализ ясау барышында укучылар, нигездә, әнисен тыңламаган малайны гаепләде, әмма бер укучым башкачарак фикер йөртә икән: монда малай гына түгел, әни кеше дә гаепле, чөнки ул аны эшкә өйрәтмәгән, бөтен эшне үзе эшләгән, менә шуңа күрә,үзе авырып киткәч, улының уен турында гына уйлавына бер дә гаҗәпләнәсе юк, диде. Менә әйтеп кара инде, син хаклы түгел дип.

Критик фикерләүгә нигезләнгән дәрес уздырганда, түбәндәге бурычларны билгелибез:

1. Укытучы әлеге дәрес белән нинди нәтиҗәгә ирешергә теләгәнен ачык күзалларга тиеш.

2. Укучылар дәрес ахырында киләсе дәрес белән дә кызыксынып китәрлек булсын.

3. Темадан читкә тайпылмау мөһим.

4. Эшли башлаган эшне (биремне) азагына кадәр эшләп бетерергә, билгеле бер нәтиҗәләр ясарга кирәк.

Яңа алымнар кулланганда, укучыларның элек булган белем һәм күнекмәләренә таяну максатка ярашлы. Мәсәлән, әгәр укучыларыгыз матур итеп үз фикерләрен җиткерә белми икән, критик фикерләү алымын кулланып уздырылган беренче дәресләр үз максатына ирешә алмаска мөмкин. Ни өчен төрле бәйгеләрдә, ачык дәресләрдә укытучыларның, бер үк алым кулланып, төрле нәтиҗәләргә килүен күзәтәбез? Бу – нәкъ менә бая гына мин әйтеп киткән фикер нәтиҗәсе. Укытучы үзе элек беркайчан да әлеге алымнар, технологияләр белән эшләмәгән, шулай ук укучылар да иҗади фикер йөртергә өйрәтелмәгән булсалар, нәтиҗә яхшы булуына шик зур.

Укучы алдына максатлар куймый гына китап яки әсәр укырга кушып, аларны фикер йөртергә өйрәтеп булмый. Дәрестә укучыларны төрле информацион (белешмә) чыганаклардан файдаланып эшли белергә өйрәтү дә мөһим. Аларның эш барышы кызыклы, эзләнүгә корылган, практик якны үз эченә алган булырга тиеш.

Дәреснең рефлексия өлешенә аз игътибар бирелә. Гадәттә, без яңа материал аңлатуны төп максат итеп алып, бу өлешне «Дәрестә без нәрсәләр өйрәндек? Бүгенге дәрес сезгә ошадымы?» кебек сораулар бирүгә кайтарып калдырабыз. Ни кызганыч, моңа укучылар да күнегә. «Әсәрдәге төп фикерне аңлау өчен сез ниләр эшләдегез? Дәреслектәге кайсы мәгълүмат сезгә аеруча кызыклы тоелды?» кебек сорауларга җавап бирергә кыенсыналар. Күп кенә сораулар аерым фактларны, терминнарны ачыклауга кайтып кала, шунлыктан алар укучыларда артык кызыксыну уятмый.

Үземнең тагын бер яратып куллана торган алымым – *тукталышлар ясап уку алымы.* Тукталыш ясап уку юл чатында торган юлчыны хәтерләтә: күпмедер юл үтелгән, әмма алда ни көткәне билгесез. Тукталыш ясау өчен кирәкле урынны таба белү мөһим. Һәр тукталышта төрле дәрәҗәдәге сораулар кую максатка ярашлы. Мәсәлән, алга таба нәрсә булыр һәм ни өчен? Әлеге алымны берничә адымга бүлеп карарга мөмкин. Беренче адым: укучыларда әсәр укуга кызыксыну уяту. Бу очракта әсәрнең исемен һәм авторын нигез итеп алып, «Әсәр ни хакында булыр?» кебек проблемалы сорау куярга мөмкин. Укучыларның фикерләре тактага яки кәгазьләргә язып беркетелеп барыла. Укучылар белән бергәләп аларның дәрес башында ничек фаразлауларын авторның ничек тәмамлавы белән чагыштырып карыйбыз. Икенче адым әсәрнең аерым өлешләрендә тукталыш ясап укуны күздә тота. Өченче адым – рефлексия өлеше. Йомгаклау өчен әңгәмә төрле формада булырга мөмкин: хат язу, иҗади эшләр һәм эссе язарга тәкъдим итәргә мөмкин. Эссе укучыларга үз фикерләрен ирекле формада белдерергә ярдәм итә.

Укучыларда фикер каршылыгы булдыру сорау бирү аша гына түгел, ә практик биремнәр аша да тормышка ашырыла. Дәресләрдә *РАФТ алымын* куллану укучылар күңеленә бик хуш килә.

Р-роль, кем исеменнән язачаксыз.

А-аудитория, кемгә атап язачаксыз.

Ф-форма, нинди формада язачаксыз – хикәя, диалог, монолог, эссе.

Т-тема, төп идея.

Шуны әйтеп китү урынлы булыр: башка кеше исеменнән язганда, укучы үзен иркенрәк хис итә, иҗади фикер йөртү офыгы киңәя төшә. Соңгы елларда татар әдәбиятыннан олимпиадаларда иҗади эш төре буларак әлеге форма бирелә башлады. РАФТ технологиясен кулланып, дәрес уздыру өчен укучының теманы яхшы белүе, фантазиясе бай булу һәм актёрлык сәләтенә ия булу кирәк. Әгәр укучылар рольләрне үзләре сайласа тагы да яхшы. Мәсәлән, Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрен өйрәнгәндә, түбәндәге форманы кулланырга була:

Роль – Акъәби

Аудитория– оныклары, балалары

Форма– хат

Тема– милләт киләчәге һ.б.

Дөрес һәм ялгыш раслаулар алымы язучыларның биографиясенә кагылышлы фактларны истә калдырырга ярдәм итә. Әлеге алымны язучы биографиясен өйрәнер алдыннан да, өйрәнгәннән соң да кулланырга була. Мисал өчен, 7 нче сыйныф укучылары Һ.Такташ биографиясен өйрәнгәндә, түбәндәге сораулардагы дөрес яки ялгыш фаразлауны табалар:

1. Һ.Такташ Татарстан Республикасында туып үскән.

2. Такташ бары шигырьләр генә язган.

3. Шагыйрь «Мокамай» әсәрен үзенең дустына багышлый.

4. Һ.Такташ башка шагыйрьләрнең шигырьләрен дә, үзе иҗат иткәннәрне бик оста итеп яттан сөйли торган була.

Дәрес азагында (рефлексия өлешендә) укытучы белән берлектә укучылар үзләренең җавапларының дөрес яки ялгыш булуын ачыклый. Әлеге алым укучыларны дәрес башында ук уйланырга мәҗбүр итә, дәрес азагына кадәр аларның кызыксыну дәрәҗәсе кимеми, чөнки укучыга «Мин дөрес җавапны таба алдыммы?» дигән сорау тынгы бирми.

«Без сөйләргә өйрәтмибез диярлек» дигән XX гасырның күренекле лингвисты һәм методисты В.И.Чернышёв. Кызганычка каршы, әлеге сүзләр хәзер аеруча да актуаль. Укытучы хезмәтен, нигездә, укучыларның язма эшләре аша бәялиләр. Укучының матур итеп сөйли белүе аның киләчәк тормышы, җәмгыятьтәге сөйләм культурасы аша үзенә урын табуы өчен бик мөһим. Менә шуңа күрә дә дәресләрдә дискуссия, диспут формаларын куллану аеруча максатка ярашлы. Укучылар белән кыска күләмле иншалар язу да шактый үтемле чара. Бу аларның иҗади фикерләвен баета. Әлеге иншаларны үзләре теләгән укучылардан дәрестә укыттыру, уңышлы җөмләләрне, сурәтләү чараларын таптыру бик мөһим. Соңрак сыйныфтагы калган балалар да кызыксынып иҗат итә башлый.

Текст өстендә эшләү, текстка комплекслы анализ ясау да укучыларның тәнкыйди фикерләү сәләтен арттыруга ярдәм итә. Укучылар өчен башта кечкенә күләмле текстлар тәкъдим ителә, тора-бара зуррак күләмле, катлаулырак текстлар белән эшләүгә дә күчәргә була. Бишенче-алтынчы сыйныфларда укучылар текстның темасын, автор идеясен билгели, өзеккә исем куша,

үзләренә таныш булган тел-сурәтләү чараларын таба, шулай итеп, бала текст белән эшләргә өйрәнә.

Проектлар методы шәхескә юнәлтелгән, балаларның акыл эшчәнлеген төрле яклап үстерә, мөстәкыйльлекне арттыра. Проект методы укучының активлыгын, фән белән кызыксынуын, гомумиләштереп әйткәндә, уку-укыту эшчәнлеген җанландырып җибәрә. Бу метод укучыларда аралашу культурасын, фикерне дөрес һәм төгәл итеп формалаштыру, төрле чыганаклардан файдалана белү кебек эшчәнлекне булдыра. Ул– укучыларның белем һәм күнекмәләрен тормышта куллану мөмкинлеге тудыра торган технологияләрнең берсе. Проект методы белән кызыксынып китүемнең дә үз сәбәпләре бар. Дөньяда барган глобальләшү процессы үз дәүләте булган халыкларны да үзенә йоткан чорда, татар милләтенә ничек үзен сакларга, бигрәк тә яшь буынның милли үзаңын ничек үстерергә? Бу сораулар мине, шәһәр укучыларына татар телен һәм әдәбиятын укытучы кешене, инде күп еллар борчый. Үзем укыткан сыйныфларда эшне иң беренче халкыбыз тарихы, аның үткәне белән таныштырудан башлыйм. Үз халкы белән горурлану хисе уятмый торып, нинди генә дәреслек, нинди генә методика белән укытуга карамастан, телне өйрәнүгә омтылыш, милли үзаң уятып булмаячагын мин мәктәптә шактый еллар укыту дәверендә аңладым. Күп уйлана торгач, башта бер идея туды: ничек тә булса укучыларны милли мирасыбыз белән кызыксыну уятырдай, аларның игътибарын җәлеп итәрлек, шул ук вакытта инновацион да булган проект уйлап табу! Менә шулай итеп, «Яңарыш» дип аталган проект дөнья күрде.

Проект барышында, укытучы һәм укучы үзара хезмәттәшлек итәләр, бер-берсе белән аралашалар. Укучылар белән сыйныфтан тыш чаралар уздыру, алар белән формаль булмаган аралашу, уртак эшчәнлек, бер-береңә хөрмәт, башка милләттән, мәдәнияттән булган кешеләргә карата кайгыртучанлык, игътибарлылык тәрбияли. Татар милләтеннән булган бала кече яшьтән үзенең милләте, күп газаплар кичерүгә карамастан, үсеш – үзгәрешкә омтылып, үз юлын булдырган, бөек тарихы булган халкы белән горурлык хисләре, ышаныч тудыру кирәк, алар татар халкы тарихының тере хәзинә, акыл һәм көч чыганагы икәнен аңларга тиешләр. Һичшиксез, проектның нигезендә укучыларыбызга төпле белем һәм тәрбия бирү ята. Шунысы куандыра: «Яңарыш» проекты эшчәнлегендә актив катнашкан балалар югалып калмыйлар, мәктәпне тәмамлап, югары уку йортларына кергәч тә актив эш алып баралар, үз проектларын җәмгыятебезнең төрле өлкәләрендә гамәлгә ашыралар. Укучыларның һәр ел саен диярлек татар теленнән Бердәм республика имтиханын сайлавы да күңелле күренеш.

Милләтебезнең күренекле шәхесләре белән даими очрашулар укучыларны рухи яктан баета, Татарстаныбызга лаеклы шәхесләр формалашуга зур йогынты ясый. Проект гамәлгә ашырыла башлагач, төрле дәрәҗәдәге иҗади бәйгеләрдә катнашырга теләк белдерүче, татар әдәбияты һәм сәнгате белән кызыксынучы балалар саны шактый артты. Нәтиҗәләр дә куандыра: Бөтенроссия һәм Республика күләмендә уздырылучы бәйгеләрдә укучыларыбыз зур җиңүләр яулый, Республика һәм Халыкара олимпиадаларда да зур уңышларга ирешәләр.

Заман укытучы алдына зур бурычлар, югары таләпләр куя. Белемле, кешелекле, эрудицияле, компетентлы остаз булып, җәмгыятебезне игелекле, иҗади фикерләүче, ихлас күңелле, тәрбияле шәхесләргә баета алсак иде.

03

ТУГАН ТЕЛДӘН БИЗДЕРҮ, ЯКИ СЕБЕР МӘКТӘПЛӘРЕНДӘ ТАТАРЛЫК НИ ХӘЛДӘ?

БИШ ЕЛ ЭЛЕК

Себертатар мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбиятын укыту ничек куелган? 2016 елның августында Бөтендөнья Татар конгрессы (БТК) башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров хәер-фатихасы белән, шушы сорауга җавап эзләп, Төмән өлкәсе мәктәпләрен урап кайту насыйп булган иде. Юлга чыгуыбызның төп сәбәбе шунда: Конгресска: «Вагай районындагы 22 мәктәпне берләштереп, 5 төп мәктәп калдырмакчы булалар, татар мәктәпләрен рус мәктәпләре белән берләштерәләр, болай булса, бер генә мөстәкыйль татар мәктәбе дә калмаячак, башка районнарда да шундый ук аянычлы хәл», – дигән хат килгән икән. Шушы хәбәрне урынга барып тикшердек без ул чакта.

Без дигәнем, юлдашларым – «Республика Татарстан» газетасының Зәй төбәгендәге үз хәбәрчесе Гамирә Гаделшина белән БТК хезмәткәре, журналист (хәзерге вакытта Конгресс каршында нәшер ителүче «Туган як» журналының җаваплы сәркатибе) Мөнирә Сәгыйдуллина. Мөнирәнең шушы як кешесе – өлкәнең Вагай районындагы Казанлы авылы кызы булуы безнең эшне шактый нык җиңеләйтте. Гамирә дә күп татар төбәкләрен аркылыга- буйга гизгән, шактый күп милли хәрәкәт җитәкчеләрен, татар эшкуарларын күреп белүче каләмдәш, кызыклы әңгәмәдәш булып истә калды. Дөрес, шунысы гына аптыратты: әлеге сәфәр хакында соңрак «Республика Татарстан» газетасында бер язма да дөнья күрмәде. Бу тема газета редакциясенә кызыклы тоелмадымы, әллә инде өстәгеләр, русча газетада бик җитди мәсьәлә күтәрелә, дип шикләнеп калдымы – белмим.

Әлеге сәфәр нәтиҗәсе буларак, ул вакытта үзем эшләгән «Ватаным Татарстан» газетасында «Этке-төртке мәктәп яки Төмән өлкәсендә татар мәгарифенең киләчәге томанлы» дигән күләмле язма чыкты. Озын сүзнең кыскасы, хатта язылганнар расланды. Чынлап та, мәктәпләрне берләштергәннәр. Рус мәктәпләре белән кушылгач, татар мәктәпләренең юридик мөстәкыйльлеге дә, финанс мөстәкыйльлеге дә калмаган. Әйтик, без күргән, 150 шәр бала укый торган Казанлы һәм Тугыз авыллары мәктәпләре Зареченый рус мәктәбенең (әле ул коррекцияле уку йорты) филиалы булып калган. Бәлкем, аяк терәп каршы торырлар да иде. Тик мәктәп уставында Казанлы да, Тугыз да рус мәктәбе дип теркәлгән булган. Элек язганнарны



искә төшерергә мәҗбүрмен: федераль дәүләт белем бирү стандартында дүрт төрле укыту планы гамәлгә куелган. Болар: а) туган телдә укыта торган, б) туган телне өйрәтә торган, в) рус мәктәпләренең, г) ике чит тел укыта торган рус мәктәпләренең укыту планы. Мәктәп укыту программасын, укыту планын фәкать үзе сайлый.

Ни кызганыч, мәктәп җитәкчелеге, рус (в) мәктәпләре укыту планын сайлап алгач, татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре, татар теле укытучылары белән тәэмин итегез, дип район мәгариф идарәсенә гариза-заявка бирә алмый; татар теле укытучыларын үзе табарга, дәреслекләрне ата-аналар үзләре юнәтергә тиеш була. Мәктәп җитәкчелеге өчен моның «уңай» ягы да бар: татар теле укытучыларының квалификациясен тикшерергә, аттестация ясарга кирәкми. Кыскасы, беренче сыйныфта татар теле укытылмыйча, ул факультатив яки түгәрәк рәвешенә генә калдырылса, әлеге уку йорты рус мәктәбе була. Менә шушы аяныч хәлнең шаһитлары булып кайтырга туры килде ул сәфәрдән.

Киндерле мәктәбе директоры Мөнирә Калиева, авылда клуб булмагач, безгә мәктәп сәхнәсеннән урын бирде.

ТАГЫН ТӨМӘН ТУФРАГЫНДА

Төмән өлкәсе татарлары конгрессы рәисе Ринат Насыйров чакыруы буенча күптән түгел безгә, җанисәп алу уңаеннан, бер төркем артистлар белән бергә әлеге дә баягы Вагай һәм Тубыл, Түбән Тәүде, Уват, Яркәү, Төмән районнарының татар авылларында булып кайтырга туры килде. Концерт-очрашуларга килгән халыкка туган телебезне гаиләдә һәм мәктәптә саклау зарурлыгын җиткерергә, милли горурлык хисләре уятырга тырыштык без.

Татар мәктәпләренең руслаша баруы – беренче чиратта мәктәп җитәкчелегенең туган телдә укыту зарурлыгын аңламавы һәм шуны ата-аналарга аңлатмавы, ата-аналарның бу мәсьәләгә битарафлыгы нәтиҗәсе ул. Югыйсә Россиянең мәгариф турындагы яңа законы ата-аналарга зур мөмкинлекләр бирде. Хәзер, гариза язып, мәктәптә укыту, тәрбия телен әти-әниләр үзләре билгели. Әлбәттә, ата-аналарның милли, тарихи үзаңы югары булса, мәктәп җитәкчелеге татарча укытабыз дип ашкынып тормаса да, туган телдә укытуны саклап калып булыр иде. Әле бит шунысы да бар: уку йортында татарлар белән беррәттән рус балалары да укый икән, бер үк мәктәп берничә укыту планын файдалана ала (себертатар мәктәпләренә күрше рус авылларыннан да балалар китереп укыткан очраклар өчен бик яхшы мөмкинлек бу; әнә Түбән Тәүде районының Киндерле авылына күршедәге өч рус авылыннан укучылар килә). Балаларыма өстәмә мәшәкать-нагрузка була дип, өлкәннәр юкка хафалана. Киресенчә, туган телен дә, русчаны да яхшы белгән баланың IQ югарырак дәрәҗәдә тора, ике телне әйбәт белгәннәр бер телне генә белүчеләрдән уңышлырак, ушлырак була. Менә шуларны сөйләдек без халыкка сәхнә түреннән.

Казанлыга биш ел элек килүебездә биредәге татар теле укытучысы, районның татар теле укытучылары методик берләшмәсе рәисе Асия Зимагулова белән күрешә алмаган идек. Бу юлы рәхәтләнеп гәпләшеп утырырга җай чыкты.

– Мин бу мәктәптә 38 ел эшлим. Әнием Лариса Абдулла кызының эшен дәвам итәм. Ул да биредә татар теле укыткан. XX гасырның алтмышынчы елларына хәтле авылыбызда татар мәктәбе эшләгән. Хрущёв заманында русча укытуга күчкәннәр, – дип бәйнә-бәйнә мәктәптә туган телебезнең ничә сәгать укытылуын, татарлыкка мөнәсәбәтнең нинди булуын бәян итте ул. Үзеннән тыш әле тагын ике татар теле укытучысы булуы да яхшы, билгеле. Асия ханым беренче сыйныфта «Әлифба» түгәрәге алып бара. Гомумән, II сыйныфтан IX сыйныфка кадәр өчәр сәгать татар теле һәм әдәбияты укыталар икән. Башлангыч сыйныфларда татар теленә – ике сәгать, уку дәресенә бер сәгать бирелә. Хәзер балалар аз укый дип, V–IX сыйныфларда, киресенчә, матур әдәбиятка күбрәк игътибар бирә башлаганнар. X–XI сыйныфларда атнасына бер сәгать татар теле, бер сәгать әдәбият дәресе укытыла. Шөкер, мәктәп китапханәсе дә, авыл китапханәсе дә шактый бай. Беренчегә килгән сабыйларны туган тел мохитенә кертә башлау шактый кыен, дигәч гаҗәпләнгән идем. Балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләр, татарчабыз начар, дип тәрбия эшен русча алып баралар икән. Менә бит татарча белгечләр өлкә күләмендә әзерләнмәгәч, авыл балалары нинди аяныч хәлгә эләгә.

– Авылда татар балалар бакчасы, татар мәктәбе оештырып булмыймы соң, – дип кызыксынам.

– Бердән, мультфильмнар карап, Интернетта утырып, балаларыбыз руслашып бара. Икенчедән, авылдан шәһәргә китсәләр, русча аралашуы кыен булыр, татарча аңласа, бераз сөйләшә белсә, шул җиткән, дип исәпли байтак әти-әни. Хәзерге заманда ата-анага аңлатуы кыен, – ди мөгаллимә.

– «Себертатар әлифбасы» нәшер ителгән, бу әлифба буенча укытуны җайга салып булырмы икән? – дип тә кызыксынам.

– Ай-һай! Үзебезнең Вагай районындагы һәр авылда төрле сөйләм ич. Диалектка багышланган дәрес үткәрсәм, балалар аңламыйча утыра. Карагайда – болай, Тугызда – алай, Юрмыда – тегеләй, Усакта шулай әйтәләр. Мондый сүзләрне балалар беренче ишетә. Мондый омтылыш балаларның башын бутау гына булыр. Дөрес, без дәрестә болай да өч телдә – русча, татар әдәби телендә, җирле сөйләмдә шулай-шулай атала дип, төшенчә-терминнарны аңлатып китәбез, – дип сөйләде А. Зимагулова. Сүз ахырында Асия ханым Рөстәм Төхфәтуллин исемле бер укучысының быел КФУга, татар журналистикасы бүлегенә укырга керүен, яшь казанлыларның әледән-әле татар теле буенча өлкә, Россия, бөтендөнья олимпиадаларында катнашып алдынгы урыннар яулавын да язмый калмавыбызны сорады. Әлбәттә, бу балалар – мәктәпнең горурлыгы! Шул ук вакытта әлеге өлкән буын ялга китсә, яшь казанлыларга кем белем бирер дигәй уй да күңелдә кыбырсып торды.

КАЗАН НИГӘ ҮГИСЕТӘ?

Түбән Тәүде районының Киндерле

авылында да өч татар теле укытучысы эшли икән. Башлангычта – бер, өлкән сыйныфларда ике укытучы укыта.

– Бездә 133 укучы бар, шуларның 56 сы татар. Татар теле дәресләренә яратып йөриләр. Атнасына бер сәгать – татар теле, бер сәгать әдәбият дәресе керә. Әүвәл, без укыганда, атнасына 3 әр сәгать татар теле, 3 әр сәгать әдәбият керә иде. Рус балалары, безнең укучылардан күреп, «Абый!», «Апа!» дип дәшә, «Исәнмесез!» дип исәнләшә. Безгә Бохара дигән – татар, Маслянка, Паченка, Тукман дигән рус авылларыннан килеп укыйлар. Мәктәптә бөтен эш ике телдә алып барыла. Балалар бакчасы ике телдә тәрбия бирә, – дип сөйләде үз чиратында Киндерле авылы мәктәбе директоры Мөнирә Калиева.

– Нинди проблемалар бар, – дип кызыксынам.

– Татар телен факультатив итеп калдырмаслармы, дип куркып торам. Чөнки күрше авылда шулай эшләделәр. Чугунайда чактан гына саклап калдылар. Менә Тарман авылында татарлар гына яши. Шунда яшәүче ата-аналар, балам татар теле укымасын дип гариза язсам, ничек булыр икән, дип киңәшләшергә килгән. «Сезнең дә, минем дә маңгайга «татар» дип язылган. Кеше туган телен белергә тиеш», – дип әйттем аларга. Бүген татар телен саклау – беренче проблема. Югыйсә ТНВда карыйбыз, аңлатырга да тырышабыз, тик байтак гаиләләрдә русча сөйләшәләр, – дип борчылуын җиткерде ул.

Сентябрь аенда башкалабыз Казанда уздырылган Милләт Җыенында да катнашкан ул. Шунда тәвәккәләп, күңел түрендә йөрткән дәгъвасын да җиткергән Мөнирә ханым.

– Безнең Түбән Тәүде районында да татарлар яши. Без – Себердә яшәүче казан татарлары! Безгә сирәк, елга бер-ике генә киләсез.Төмәндә дә, Казанда да безне аңласыннар, ярдәм кулы сузсыннар иде, – дип чыгыш ясаган ул анда. Ни гаҗәп, шушындый зур авылда Мәдәният йорты юк. Концерт дигәнебез мәктәптә узды. Төмәннән әллә ни еракта урнашмасалар да, озак еллар асфальт юл күрергә өметләнеп яшәгән киндерлеләр. Ниһаять, боз кузгалган. «Күршедәге Паченкага 7 чакрым яхшы юл түшәлде, тагын 7 чакрым араны асфальтласалар, яхшы юлга тиенәбез. Киләсе елга вәгъдә итәләр», – дип, шатлыкларын уртаклашты концертка килгән авыл агайлары.

ЮЛ КҮРСӘТҮЧЕГӘ ИЯРМӘГӘЧ

Төмәндә яшәүче өлкән журналист Бибинур Сабирова да, Мөнирә Калиева кебек, Конгресс адресына дәгъвасын җиткерде. «Конгресс җитәкчеләре, татарны бүлмибез дисә дә, себер татарлары белән генә эш йөртеп, Себердәге казан татарлары белән хезмәттәшлек итмәде. Себер татарлары белән уйнадылар алар. Нәтиҗәдә милли хәрәкәт таркалды. Аңлап-белеп бетерми торган сәер нәрсәләр бар монда. Казанга баргач, бердәмлек кирәк, дип белдерсәләр дә, биредә астыртын гына таркату эшләре алып баручылар бар, – дип, берничә яхшы мәгълүм затның исемен атады ул. Бибинур ханым – туксанынчы елларда «Татар-информ» агентлыгының Төмәндәге үз хәбәрчесе булып эшләгән, озак еллар үзләрендә «Хикмәт» газетасы чыгарып килгән, ике дистә ел өлкәнең «Ак калфак» оешмасын җитәкләгән мөхтәрәм шәхес. 2011 елдан бүгенгәчә Ak-kalfak.ru электрон журналы чыгаруы да – зур батырлык, минемчә. Милли мәгарифебезнең торышы белән даими кызыксынып

тора, авылларга баргач, мәктәпкә кереп чыкмыйча кайтмый икән тынгы белмәс җан.

– «Хикмәт» газетасын чыгарганда, Яркәү районының Шатан дигән авылына бардым. Каршыма Саз ягындагы Вәчир авылыннан килен булып төшкән, бала арбасы этеп килүче яшь әни очрады. «Исәнмесез!» диюемә русча җавап бирә. «Татарча белмисеңмени», – дим. «Беләм. Безне шулай гадәтләндерделәр инде», – ди. Якын-тирәдәге дүрт татар мәктәбен япканнар. Шатандагысы да ябылган. Менә дигән агач бина югыйсә. Авыл балаларын беренче сыйныфтан рус авылына – Аксаринага йөртеп укыталар. Аның директоры, ата-аналарны җыеп, балаларыгыз белән бишектән русча сөйләшегез; русча белми килсәләр, аларны укытырга алмыйм, дип әйткән. Мин шушы хәлне «Хикмәт»тә язып чыктым. Ник бер милли хәрәкәт лидеры игътибар итсен?! Әнә Яркәү районының Ваңгы авылындагы 70 бала укыта торган мәктәпне ябып, Яңа Александровкага йөртәләр. Югыйсә аларны Яңа Кәешкүлдә, татар мохитендә укытырга була иде, – дип аһ ора Б. Сабирова. Конгресс әһелләре иң элек мәктәп директорлары белән эшләргә тиеш, дип, Тубылда булган бер мәгариф конференциясен искә төшерде ул. Өлкәнең мәгариф һәм фән департаментында милли мәктәпләр буенча баш белгеч булып эшләүче Ольга Гроо: «Күп кенә мәктәпләрдә хәзер татар телен икенче сыйныфтан гына укыталар. Беренче сыйныфтан башлап укыту мөмкинлеге бар. Укыту планында булмаса да, мәктәп компоненты хисабына укытыгыз», – дип тәкъдим иткән шунда. Директорларның ник берсе кызыксынсын?! Бу битарафлыкны күргәч, «Нишләп йөзегез таш кебек? Сезгә барыбермени? Моны иң элек сез кайгыртырга тиеш. Юлын күрсәтәм бит», – дип орышкан ул аларны.

*****

Битарафлык, милли горурлыгыбыз югалу – иң зур чиребездер, мөгаен. Бик йогышлы чир бу. Милли мәгариф өчен җаваплы кешеләргә эләккәндә, ул аеруча куркыныч.

Рәшит Минһаҗ

Фотолар шәхси архивыннан

04

МӘКТӘПТӘ МИЛЛИ КИЕМ ҺӘМ МИЛЛИ БИЗӘК

Түгәрәк өстәл

Расиха ФАИЗОВА

Мәшһүр сынчы Рада Нигъмәтуллинаның: «Без, кызлар, урамда композитор Сара Садыйкованы күрсәк, үзенә сиздермәскә тырышып, аның артыннан бер тотам калмыйча йөри торган идек. Аның ул чакта без күреп ияләшмәгән энҗеле калфагына, милли киемнәренә гаҗәпләнүебез көчле иде», – дип сөйләгәннәре бүгенгедәй истә. Юкка гына халкыбыз калфакны татар хатын-кызларының таҗы дип, ә күпләргә үрнәк булган Сара Садыйкованы калфаклы сандугач дип атамый бит инде.

Мәктәпләрдә татар милли киеменә ничегрәк карыйлар? Ул көндәлеккә кердеме, әллә бары тик сәхнә атрибуты буларак кына кабул ителәме? Мәктәпләрдә, гомумән, милли бизәкләргә мөнәсәбәт ничек? Без – «Гаилә һәм мәктәп» журналы баш мөхәррире **Расиха Исмәгыйлова,** «Мәгариф» журналының җаваплы сәркатибе **Альберт Сабиров,** бүлек мөхәррире **Таһир Сабирҗанов** – «Авыл укытучысы» бәйгесе җиңүчеләре белән әнә шул хакта гәпләшеп алырга булдык.

Расиха Исмәгыйлова. Казан шәһәренең Ф.Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче кызлар гимназиясендә 1 нче сыйныфка аяк баскан һәр гимназист, Фатиха Аитованың үзе кебек, энҗеле-мәрҗәнле калфактан йөрүен беләбез. Елның-елында башлангычларны гимназистлыкка багышлау бәйрәмендә аларга милли дизайнлы калфаклар тапшырыла. Биредә һәр сыйныф үзенә генә хас калфаклары, чулпылары, курайлары белән аерылып тора. Моннан берничә ел элек Кайбыч районының Иске Чәчкаб мәктәбендә, бөтенесе бер булып, кызларның калфактан, егетләрнең түбәтәйдән йөрүен күреп тә сокланып кайткан идек. Болар кунаклар киләсен белеп кенә шулай киенергә булгандыр дигән шик тумады түгел. «Юк, көннең-көнендә шулай йөрибез. Беркемне дә мәҗбүриләмибез, берсеннән күреп икенчесе кия, көз-яз айларында мәктәптә шундый баш киемнәре белән йөрү модада», – дигән иде безгә мәктәп директоры. Аның үзе турында да, өч дистә елдан артык түбәтәен салмый, диделәр.

Ләйсән ВӘЛИЕВА, Арча районы Иске Чүриле мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Без 1–4 нче сыйныф укучылары белән милли бизәкле каптырмалар эшләдек. Укучылар аны ел буе үзләренең мәктәп формасына тагып йөрделәр. Ошаттылар. Моны алга таба урта, югары сыйныфларга да кертсәк, мәктәптә миллилеккә бер адым булачак. Туган тел атналыгы, Туган телләр көне, Тукай атналыгы уңаеннан узган чаралар барышында егетләребез, кызларыбыз зур горурлык белән түбәтәйдән һәм калфактан йөриләр. Һәр ел саен укучыларыбыз татар теле буенча халыкара олимпиадада катнаша. Анда аларга милли бизәкле камзуллар бүләк ителә. Укучыларыбыз аны шулай ук бик яратып кия. Укытучылар исә – униформада. Без, күрәсең, көндәлек тормышта милли киемнән йөрүгә бик үк әзер түгелдер. Милли кием әлегә күбрәк сәхнәдә.

Расиха Исмәгыйлова: Униформага заказ биргәндә, төсен, фасонын сайлыйсыздыр. Шул вакытта арагыздан берәү, әйдәгез, шуңа нинди дә булса зәвыклы гына милли бизәк кертеп җибәрик әле, дисә, каршы булыр идегезме?

Ләйсән Вәлиева. Алай эшләгәндә, чыннан да матур булачак. Яңасына заказ биргәндә уйларга кирәк булыр. Безнең мәктәптә рус милләтеннән булган балалар да, бәйрәм була калса, түбәтәйләрен киеп киләләр.

Лилия Гатиатуллина, Питрәчтәге 2 нче урта мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Монда миңа калса, шәхси үрнәк мөһим. Мин Питрәч районының «Ак калфак» оешмасын җитәклим. Үземә килгәндә, төрле киемнәргә яраштырып алган берничә төрле энҗеле калфагым, изүләрем бар. Мин аларны төрле чараларда бик яратып киям. Район күләмендә «Татар кызчыгы», «Татар малае», милли йолаларыбыздан «Каз өмәсе» кебек күп кенә чаралар оештырабыз. Мәктәптә дә тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булгач, мондый эшләрнең үзәгендә кайнарга туры килә. Татар теле укытучыларыбыз да милли җанлылар. Барыбыз да кулдан эшләнгән милли бизәкле каптырмалардан йөрибез. Аларны эшләүнең әллә ни кыенлыгы юк. Осталык дәресләре уздырып, шуларны мәктәп киеменә кертеп җибәргәндә бик шәп булыр иде. Беренчедән – милли; икенчедән, бала үз кулы белән эшләгәч, ул аңа кадерле дә булачак. Без, татар теле укытучылары, «Әдәби марафон»да катнашучыларда да калфак, изү кебек милли бизәкләрне еш күрәбез, һәм бу бик килешле. Хәзер бит зәвык белән эшләнгән милли алкаларның даниндиләре генә юк.

Расиха Исмәгыйлова. Милли теманы үзәккә алып эшләүче һөнәрчеләр шактый. Эшләре күңелегезгә хуш килгән осталарны мәктәпкә чакырып, мастер- класслар уздырсагыз, укытучылар өчен дә, укучылар өчен дә кызыклы һәм файдалы булыр, дип уйлыйм.

Таһир Сабирҗанов. Ул бизәнү әйберләре дәрес барышында баланың дикъкатен алмыймы соң?

Айгөл ХӘБИБУЛЛИНА, Әлмәт районы Түбән Мактама 1 нче урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Һич юк. Мин үзем дә миллилеккә тартылам, милли төсмерләр, милли бизәкле кием-салым миңа бик якын. Балаларның да күңеленә салынган ул, алар да кызыга моңа. 2019 елда, «Ел укытучысы» бәйгесендә катнашканда, Оренбург кызы, һөнәрче Гөлфия Билалова белән эшләргә, Казанда аның остаханәсендә булырга туры килде. Хәзерге Интернет заманында мондый осталарны табуы җайлы. Дөрес, мәктәптә униформадан йөрү яхшы – бөтенең бер төрле, әмма шул ук вакытта укытучының үзенчәлеге, үз йөзе, үз стиле югалмасын иде. Әйтик менә, төгәл фәннәр укытучылары бер төрлерәк киемнәрдән булсалар, туган тел, тарих укытучыларының киемнәрендә миллилек чагылу бер дә артык булмас. Мин, үзем туган тел һәм әдәбият укытучысы буларак, милли төсмерләргә һәм бизәкләргә өстенлек бирәм. Укучыларым беравыздан «бик матур» диләр. Балада укытучыга охшарга тырышу омтылышы бар. Кайчагында бу мәсьәләдә синең белән каршылыкка килгән укучылар да, апа, каян алдыгыз, карыйк әле, дип кызыксыналар. Дөрес, беренче күргәндә, бәлкем, ул әлеге бизәккә күзе төшеп, дәрестә шуны карап та утырырга мөмкиндер, әмма икенче көнне ияләшә ул аңа. Хәтта әлеге милли бизәкләр аша без татарның орнаментын өйрәнүгә, тарихка, мәдәнияткә юл ачабыз. Билгеле, бөтен укытучылар һәм укучыларны да җәлеп итеп булмаячак. Әгәр артыбыздан бер-икесен генә булса да ияртә алабыз икән, бу – укытучының уңышы. Бала алдына чыгып баскан укытучы, белем генә бирми, бер үк вакытта ул үзенең кыяфәте белән зәвык та тәрбияли бит әле.

Гүзәл Хәсәнова, Биектау районы Олы Кавал мәктәбенең математика укытучысы. Мин математика укытучысы булсам да, әдәбиятны, тарихыбызны яратам. Милли мирасны, милли төсләрне саклауны хуплыйм. Бездә тугызъеллык мәктәп кенә булгач, сәгатьләр әзрәк, шуңа күрә бер үк вакытта күрше Әлдермеш урта мәктәбендә дә ике сыйныфта укытам. Анда тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Гөлүсә Рафаэль кызы Насруллина хезмәт дәресе – технология фәнен алып бара. Ул кызларны калфак чигәргә өйрәтә. Шулкадәр матур килеп чыга. Үз киемендә дә һәрвакыт нindидер милли бизәк булыр, алкамы ул, каптырма яки изүме. Шуның кадәр килешле итеп киеп куя ул аларны, карап кына торасы килә. Моннан тыш, курчакларны милли киемнәргә киендерә. Күргәзмәләр ясый. Укучылары да аннан калышмый. Минемчә, шундый технология укытучылары, балаларны өйрәтеп кенә калмыйча, укытучыларны да киендерә, я булмаса, киемнәренә милли бизәк өстәүдә ярдәм итә алырлар иде.

Лениза ГАРИФУЛЛИНА, Азнакай районы Кәкре Елга мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучысы. Диплом буенча мин үзем татар теле укытучысы. Мәктәбебез ел саен зур грантлар да алуда катнаша. Былтыр тәрбия эшләре буенча 200 мең сумга лаек булдык. Шуның күпмедер өлешенә кызларга һәм егетләргә милли киемнәр һәм, шуларга иш итеп, күргәзмәләрдә файдалану өчен милли бизәкле ашъяулыклар тектердек. Мәктәпнең бер үзенчәлеге бар. Без алты еллап инде агрокласс проектына нигезләнеп эшлибез. Азнакай кебек, милли төбәктә дә балаларны милли йолалар, мавыгулар аша милли рухта тәрбияләү көн үзәгендә тора. Авылда ат спорты мәктәбе, хоккей мәйданчыгы бар, тирә-якта бер таш мәчет эшли. Өлкән сыйныф укучылары турында «ат җене кагылган егетләр» дип әйтергә була.

Расиха Исмәгыйлова. Алар, мөгаен, төрле ярышларда катнашалардыр. Боларга ярыш вакытында кию өчен милли рухтагы киемнәр булдыру турында уйлану мөмкинлегегез бар икән.

Лилия Гатиатуллина. Безнең мәктәп рус мәктәбе санала. Шуңа да карамастан 20 еллап татар театры эшләп килә. Балалар анда бик теләп йөриләр. Әдәби телне саклау өчен бу – зур стимул. Театрны татар теле укытучысы Елена Николаевна Галәветдинова җитәкли. Коллектив, бик күп бәйгеләрдә катнашып, Гран-при алды. Быел исә мәктәбебез ТР Мәгариф министрлыгы Туган телләр һәм халыклар дуслыгы елы уңаеннан игълан иткән 500 меңлек грант бәйгесендә катнашты. Бу акчага без кыз һәм егетләребезне баштанаяк киендерерлек итеп сәхнә киемнәре тектерергә заказ бирдек. Кызларга бала итәкле күлмәк, алъяпкыч, күкрәкчә, яулык, читек, ә егетләргә күлмәк, җилән, түбәтәй, читек булачак. Милли сәнгатьне үз иткән балаларыбыз, Сабада уза торган Шәүкәт Биктимеров исемендәге фестивальдә катнашып, ике тапкыр Гран-прига лаек булдылар. Сәйяр бәйгесендә, К. Тинчурин исемендәге фестивальдә дә Гран-при бездә иде.

Таһир Сабирҗанов. Рус мәктәбендә миллилеккә, милли киемнәргә мөнәсәбәт ничегрәк соң?

Лилия Гатиатуллина. Быелгы кебек туган телгә һәм халыклар дуслыгына хөкүмәт дәрәҗәсендә игътибар булганда, миллилек күз уңына менә. Менә шул биеклектән төшермәскә иде аны. Ләйсән әйтеп киткәнчә, бездә дә Туган телләр елы уңаеннан һәр сыйныф махсус чыгыш әзерләде. Анда хәтта рус балалары да түбәтәй киеп килгән иделәр. Быел үземнең ике укучым татар теле буенча халыкара олимпиадада катнашты. Аларга, матур итеп киеп йөрегез, дип, үземнең калфаклардан өлеш чыгардым. Аннан безнекеләр дә матур милли бизәкле камзул киеп кайттылар.

Әле электрон почтама күз салган идем, Энҗе Габдуллаҗановна Мостафина безнең сөйләшүнең темасын белгән кебек, менә шундыйрак хат язып җибәргән. Районда «Купшы каптырмалар килешә татар кызына» исемле бәйге игълан иткәннәр. Халкыбызның милли үзенчәлекләрен өйрәнүдә, укучыларның иҗади эшчәнлеген арттыруда, үсеп килүче буында милли үзаң тәрбияләүдә, буыннар бәйләнешен тәэмин итүдә әһәмиятле чара буларак, 2–4, 5–8 нче сыйныфлар арасында барачак икән ул. Бәлкем, әле менә шушы сөйләшүдән, менә шундый бәйгеләрдән соң без моның тәмен тагын да ныграк тоя башларбыз. Тукаебыз әйткәнчә, халык күңелләрен кузгатып җибәрербез.

Альберт САБИРОВ. Мәктәпләрдә һәм аннан читтә укытучылар һәм кыз балаларның яулык бәйләвенә мөнәсәбәт ничек?

Асия ЗАКИРОВА, Яшел Үзән районы Татар Танае мәктәбенең химия-биология укытучысы. Беләсезме, шәхсән мин үзем шуның кадәр яратам яулык бәйләргә. Шул ук вакытта мин аны чит-ят илләрдәгечә итеп түгел, үзебезчә, чын татарча итеп бәйләү ягындамын. Үзебезнең, ак әбиләр кебек, ап-ак яки башка ачык төстәге яулыкларны күз уңында тотам. Өлкән яшьтәгеләрнең аны аркага җәеп салып, яшьрәкләрнең чөеп бәйләве бик килешле бит. Безнең әбиләребез шулай йөргән. Эшли башлаган елларда яшь тә идем, вакытым да күп иде – ыргак белән дә, энә белән дә челтәр бәйли идем. Дәрестән соң калып, укучыларга ыргак белән яка, манжет бәйләргә өйрәтә башладым. Кызыксыну шулкадәр зур булып чыкты, кызлар гына түгел, малайлар да кушылды бу эшкә.

Мин үзем сәхнә кешесе: сөйлим дә, җырлыйм да, концертлар да алып барам, фольклор кичәләрендә катнашам. Бәйрәмнәр җитә башласа, спектакльләрдән өзекләр күрсәтәбез. Бу – бала чагым хыялы, мин артист булырга хыялланган кеше. Артист тормышы тормышмыни, дип әби белән бабай укытучы булырга киңәш иткәнгә генә мәктәпкә килеп кергәнмендер. Ләкин монда да сәнгать тормышы белән яшәргә була. Быел мин 5 нче сыйныфның класс җитәкчесе. Алар белән татар халык биюен өйрәндек. Арадагы бер рус баласы: «Мин бии белмим», – дип торган иде, үзе дә уйламаганда тыпырдатып биеп китте. Әкренләп татарча сөйләшергә дә өйрәнә. «Милли кием тектерергә акча булмаса, аны гади генә итеп үзебез эшләп була, – дим балаларга. – Малайлар кара чалбар, ак күлмәк, кәләпүш кия, кызлар, алъяпкыч белән форма киеп, яулык бәйлисез дә рәхәтләнеп биибез», – дим. Әбиләребезнең элеккеге киемнәрен табып, шулар белән чыгыш ясаган чаклар да була. Алай да бүген инде милли киемнәрнең сандыктагысын гына киеп йөрмибез, ул стильләшкән, заманчалашкан булырга тиеш.

Индира ӘХМӘТВӘЛИЕВА, Норлат районы Киекле урта мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучысы. Мәктәпнең география, биология-химия укытучысы Галәветдинова Розалия Мөхәммәтсалих кызының кулыннан килмәгән эше юк. Башлангычтан алып бөтен югары сыйныф укучыларына кадәр стильләшкән, заманча милли киемнәр тегә ул. Без – укытучылар да аның бу осталыгыннан файдаланабыз. Мин үзем башлангыч сыйныф укытучысы буларак, шуны әйтә алам: кечкенә балалар укытучының тышкы кыяфәтенә аеруча игътибарлы. Бүген беләзек киеп килсәң, алар да икенче көнне шундыйны киеп килә. Алка тагасың икән, икенче көнне шундый алка тагып килергә мөмкиннәр. Шуңа күрә дә балалар янына кергәндә, укытучы үзенә бик игътибарлы булырга тиеш. Әтиемнең апасы (авылда аны ак әби дип йөртәбез) Ратифә Насретдинова кул эшләренә бик хирыс. Ул милли бизәкләр белән калфаклар, түбәтәйләр тегә, чигә. Мин элеккеге елларда аны еш кына мәктәпкә чакыра идем. Ул, үзенең кул эшләрен күрсәтеп, сөйләп, балаларда милли киемгә, кул эшләренә кызыксыну уятырдай осталык дәресләре бирде. Һәр авылда бар андый кешеләр, аларны җәлеп итә белергә генә кирәк.

***

Сөйләшүне Фатиха Аитова исемендәге 12 нче гимназиядән башлаган идек, шулар белән төгәллик тә. Алар өчен яңа бина төзетүне башлап йөргән мөхтәрәм язучыбыз Туфан Миңнуллин үзе исән чакта һәр ел «Соңгы кыңгырау» бәйрәмендә 11 нче сыйныфны тәмамлаган уку алдынгысына көмеш беләзек тапшыру кебек күркәм гадәт булдырган иде. Ул хәзер дә дәвам итә. Әлеге сөйләшүдән соң мәктәпләрдә шуңа охшаган яки бик үк охшамаган милли традицияләр барлыкка килсә, ни гаҗәп!

05

ОНЫТЫЛГАН СҮЗЛӘР

Әлфия ЙОСЫПОВА,

КФУ укытучысы

Сүзлекләрдә, үзөйрәткечләрдә, сөйләүлекләрдә теркәлеп калган, ләкин хәзер инде бик сирәк кулланыла торган, онытылган сүзләребез байтак. Без аларны өйрәнүгә кереште. Шул турыдагы язмалар татар теле укытучылары өчен дә кызыклы булыр.

Татар теленең беренче сүзлекләреннән берсе – Иосиф Гиганов сүзлегендә теркәлгән, әмма хәзер онытыла язган яисә инде онытылган сүзләр турында бер язма тәкъдим итәбез.

Бу сүзләрнең кайберләрен, бәлки, сөйләмебездә куллана башларга да мөмкиндер.

Мәктәп программасында тарихи һәм искергән сүзләрне өйрәнүгә бик аз вакыт бирелә. Бу темалар 5 нче сыйныфта үтелә һәм 9 нчы сыйныфта кабатлана. Әлеге язманы шул дәресләрдә файдалану өчен тәкъдим итәбез.

Телебез гасырлар буе төрле үзгәрешләр кичереп яшәгән. Күп кенә әйберләр кулланылмый башлаган һәм аларның атамалары да юкка чыккан. Ул сүзләр урынына яңа лексик берәмлекләр барлыкка килгән һәм актив кулланылышка кереп киткән.

Бу мәкаләдә без И. Гигановның «Слова коренные, нужнейшие к сведению для обучения татарскому языку, собранные в Тобольской главной школе учителем татарского языка И. Гигановым и Юртовскими муллами свидетельствованные» (СПб. 1801) дигән сүзлеген өйрәнеп, анда теркәлеп тә, хәзерге татар телендә онытылган, телдән төшеп калган берәмлекләргә тукталып үтәбез.

Сүзлек тематик принцип буенча төзелгән. Шуңа күрә без дә күзәтүебезне шул бүленешкә нигезләнеп алып барабыз. Беренче бүлектә дәүләт төзелешенә караган сүзләр бирелгән. Алар арасында теге яки бу сәбәпләр аркасында онытылган, мәгънәләре үзгәргән сүзләр шактый күп. Мәсәлән:

Вилаять сүзе сүзлектә **страна** (ил) мәгънәсендә бирелгән. Бу сүз хәзерге телебездә очрамый, ул пассивлашкан. Бары тарихи романнарда гына чагылыш таба. **Вилаять** – гарәп алынмасы, ул **өлкә, губерна** дигән мәгънә белдерә. (ГТРАС, 53.)

Йорт сүзенең хәзерге телдә мәгънәсе шактый тарайган. Сүзлектә ул **владение** (биләмә, җир) дип бирелә. Шулай ук бу сүзнең иске татар телендә **ил, дәүләт** мәгънәсендә йөрүе дә мәгълүм. Йорт – төрки сүз.

Ил сүзе **селение** (авыл) мәгънәсендә теркәлгән. Хәзерге телдә аның мәгънәсе, киресенчә, киңәйгән. **Авыл** дигән мәгънәдә ул кайбер авыл исемнәрендә генә сакланып калган. Мәсәлән, **Кариле, Казиле.**

Дарваза сүзе **городские ворота** дип бирелә. Ул ике өлештән тора. **Дар** сүзенең гарәп телендә **зур йорт, зур торак** дигән мәгънәләре бар, ә **ваза** сүзенең мәгънәсе сүзлекләрдә очрамады.

Чаршу сүзе безнең телдә бөтенләй кулланылмый. Сүзлектә ул **базар** сүзенең синонимы итеп бирелә. Бу сүз төрек телендә актив кулланылышта. Мәсәлән, Төркиядә Капалы чаршы, Мисыр чаршысы дигән базарлар бар.

Дөкян сүзе **кибет** сүзе белән бергә бер синонимик рәт тәшкил итә. Бу сүз гарәп теленнән алынган. (ГТРАС, 120.) Хәзерге казах телендә **кибет** мәгънәсендә сакланган.

Мәнзилханә сүзенең беренче өлеше безнең өчен бөтенләй таныш түгел. Сүзлектә ул **почта йорты** дигән мәгънәдә бирелгән. Сингармонизм законына буйсынмавы аның гарәп алынмасы булуын күрсәтә. Гарәп телендә ул **юлчылар туктый торган йорт, мөсафирханә** дигән мәгънә

белдерә. (ГТРАС, 315.)

Ханә компоненты ярдәмендә ясалган тагын бер сүз – **рәкысханә.** Хәзер бу сүз дә кулланылмый. И. Гиганов сүзлегендә ул **театр** дигән сүзнең тәрҗемәсе буларак теркәлгән. Сүзнең беренче өлеше **рәкыс бию** дигән мәгънә белдерә. (ГТРАС, 486.) Димәк, **рәкысханә биюләр үткәрелә торган өй, йорт** дигәнне аңлата.

Сүзлектә урын алган икенче тематик төркем «Йорт-җир» дип исемләнгән. Монда теркәлгән сүзләрнең күбесе безнең телебездә бик сирәк әйтелә, я бөтенләй кулланылмый. Бу төркемдәге гарәп алынмалары: **гыймарәт – строение** (ГТРАС, 99), **дивар – стена** (ГТРАС, 109) соңгы вакытларда телебезгә кире кайту процессын кичерәләр, сирәк кенә булса да, матбугат битләрендә күренә башладылар.

Мирәлек – труба, чуал – камин, китак – курятник, итлек – анбар, аткура – конюшня, сандала – скамья, иләйтакта – лавка, ястыгач – подушечка, кибирән – наволочка нижняя, айнә – зеркало, айнәк – очки, шәмкайчы – шипцы, суфа – стол, дәстәрхан – скатерть, аяк, тигәч – чашка, чәмбер – обруч, алап – **коробка** кебек сүзләргә килгәндә, алар арасында төрки-татар сүзләре, гарәп-фарсы алынмалары, диалекталь сүзләр бар. **Итлек, аткура, аяк** сүзләре хәзерге татар телендә кулланылмый. Алар онытылган, башка сүзләр белән алмашынган. Ләкин аларның мәгънәләрен аңлап була. Мәсәлән, **итлек** – **ит саклана торган урын, аткура – атлар яши торган урын** һәм **кура** сүзе **абзар-кура** дигән парлы сүз составында бар, ә **аяк** – **савыт** дигән мәгънә белдерә. **Сандала, айнә, айнәк, шәмкайчы, суфра, дәстәрхан** сүзләре – алынмалар. **Сандала** сүзе **сандалия** дигән фарсы сүзеннән килеп чыккан. Ул – **тумбочка сыман өстәл** дигән мәгънә белдерә. (ГТРАС, 500.) Ә И. Гиганов сүзлегендә, күргәнебезчә, ул **урындык** дип бирелә һәм бу сүз шул ук мәгънәдә төрек телендә сакланган **sandalye – стул, кресло** (Scerbinin, 358). **Айнә** сүзе дә фарсы теленнән алынган, **көзге** дигән мәгънә белдерә. (ГТРАС, 17.) Татар телендә хатын-кыз исеме буларак очрый. Төрек телендә **көзге** мәгънәсендә сакланган. (Scerbinin, 152.)

Шәмкайчы сүзе ике тамырдан тора. Беренче тамыр **шәм, шәмгъ** дигән гарәп теленнән килеп чыккан (ГТРАС, 710), ә икенче тамыр – **кайчы** төрки чыгышлы һәм ул, билгеле булганча, хәзерге татар телендә актив кулланыла. Мишәр диалектының байкыбаш сөйләшендә **шәмкайчы – шипцы** мәгънәсен **шәм** сүзе белдерә һәм диалектологик сүзлектә аңа **чыра кыстыру өчен эшләнгән өч япьле тимер** дигән аңлатма бирелә. (ТТДС, 1993, 380.) Бу берәмлекләр, элек кулланылышта булсалар да, хәзерге татар телендә сирәк очрыйлар.

Мирәлек, чуал, китак, иләйтакта, ястыгач, чәмбер, алап, кибирән кебек сүзләр себер татарлары диалектларында кулланыла. Мәсәлән, **алап** сүзе тобол сөйләшендә **кайрыдан ясалган зур кәрҗин** дигән мәгънәне; **ястыгач – колак мендәре, кечкенә мендәрчек** дигәнне; **чуал** (цуал) – **алды ачык мич** дигән мәгънәне белдерәләр (Тумашева, 21, 72, 241). Ә **китак** сүзе татар телендәге **кетәк** сүзенә сингармоник параллель булып тора. Бу тамырдан ясалган **кетәклек** сүзе татар теленең төрле сөйләшләрендә кулланыла, һәм алар барысы да, **йорт кош-кортларын асрау өчен, махсус корылма** дигән мәгънә белдерә. (ТТАС, 2, 88.)

Сүзлекнең «Ашамлыклар» дигән төркеменә тупланган сүзләр дә кызыклы. Хәзерге татар телендә актив кулланылышта булган сүзләр белән беррәттән, телдән төшеп калган, диалектларда гына сакланган,

алынма берәмлек булган сүзләр дә бар. Мәсәлән, **сәртә** дигән сүз. Аның аңлатмасын И. Гиганов **отвар, суп** дип бирә. Ә Д.Тумашева төзегән «Словарь диалектов сибирских татар» (Казань, 1992) дигән сүзлектә ул **кыздырып аш өстенә салынган май** дигән мәгънәдә теркәлгән. **Шешбәрә** сүзе **пилмән** дип бирелә. Себер татарлары сөйләшләреннән тыш, бу сүз каргалы, шарлык сөйләшләрендә бар. Сүзнең башка фонетик вариантлары кайбер төрки телләрдә дә очрый. Мәсәлән, **сүсбәрә** – башкорт телендә, **дюшбере** – кумык телендә, **чүпчара** – кыргыз телендә һ. б. (Хайрутдинова, 109 – 110) И. Гиганов сүзлегендә **ак ипи, шәнгә** мәгънәсендә **нан** дигән сүз бирелә. **Нан** – фарсы сүзе. (ГТРАС, 443.) Бу сүз хәзерге татар телендә юк, ә кайбер төрки телләрдә актив кулланылышта йөри.

Сүзлекнең «Киемнәр» дип аталган тематик төркеменә шактый күп сүз теркәлгән. Шуңа күрә безнең телебездә булмаган берәмлекләр дә чагыштырмача күп. Кайбер сүзләргә тукталып үтик. Мәсәлән, **китән** сүзе хәзерге татар телендә кулланылмый, ә иске татар телендә ул яхшы сыйфатлы **җитен сүсеннән сугылган ак киндер тукыма** дигән мәгънә белдергән. (ТТАС, 2, 113.) Сүзләр арасында тагын **биш бармак** дигән сүз дә бар. Ул татар теленең диалектларында **перчатки** мәгънәсендә кулланыла. Себер татарлары сөйләшләреннән тыш, татар теленең мишәр диалектында актив. (ТТДС, 89.) **Пайпак** сүзе себер татарлары сөйләшләрендә **мех яки йон оек** мәгънәсендә кулланыла. (Тумашева, 167.) Әлеге сүз татар телендәге **байбак** сүзенә туры килә. Димәк, бу оек байбак тиресеннән эшләнгән булган һәм шул җәнлек исеме белән аталган. Татар халкында мондый төр оек булмаган, ә себер татарларында ул һава шартлары белән бәйле рәвештә барлыкка килгәндер.

Сүзлектә урын алган тукыма исемнәре дә кызыклы. Мәсәлән, **бахта – хлопчатобумажная ткань, кытат – китайка, буяк – зендель, алача – александрейка, макмал – бархат, зярбаф – парча.** Бу сүзләр хәзерге татар телендә бөтенләй очрамый. Аларның кайберләре хәтта сүзлекләргә дә теркәлмәгән. Ә кайберләре турында түбәндәгеләрне әйтергә була. Мәсәлән, **кытат – үзеннән чыккан бизәкле, парча сыман ефәк тукыма.** Ул Кытайдан килгән. Соңрак Россиядә, шул исәптән Казанда да, аңа охшатып тукылган мамык тукыманы **кытат** дип йөрткәннәр. (Рәхимова, 41.) **Алача** – күбесенчә юллы-юллы яки шакмаклы итеп кулдан төрле төстәге буй һәм аркау җепләрдән сугылган тукыма исеме. (Рәхимова, 42.) **Зярбаф** сүзе ике өлештән тора. **Зәр фарсы** телендә алтын дигән мәгънә белдерә (ГТРАС, 138), ә **баф** сүзе ф, *w* кучешләре кичергән һәм хәзерге татар телендә **бау** формасында кулланыла. Ләкин ике компонентның кушылуы нәтиҗәсендә сүзнең сүзлеккә теркәлгән мәгънәсе килеп чыкмый. Бәлки автор алтын җепләрдән торган тукыма дип әйтергә теләгәндер.

Сүзлектә бирелгән тагын бер тематик төркемгә тукталып үтик. Бу төркем мәктәп һәм уку әсбапларын белдергән сүзләрне берләштерә. Тематик төркемдәге сүзләр, нигездә, гарәп-фарсы алынмалары. Хәзерге татар телендә кулланылмый торган сүзләрдән бу сүзлектә **кяп – слово, тават – чернильница, сияһ – чернила, сәмых – камедь** кебек берәмлекләр бирелгән. **Кяп** сүзе фарсы теленнән кергән, татар әдәби телендә мөстәкыйль рәвештә кулланылмый. **Гәп кору, гәп сату, гәпләшү** формаларында гына очрый, ә кайбер төрки телләрдә актив кулланылышта йөри. Ә себер татарлары сөйләшләрендә яңгырау тартыкларның саңгыраулашуы – фәндә билгеле факт. Шул ук күренешкә мисал итеп **тават** сүзен

күрсәтергә мөмкин. Бу сүз безнең телебезгә кайчандыр гарәп теленнән кереп, хәзер инде онытылган сүзләр рәтенә күчкән. Аның беренчел варианты – **дәват,** һәм ул кара савыты дигән мәгънә белдерә. (ГТРАС, 113.) И. Гиганов сүзлегендә, югарыда күрсәтелгәнчә, ул нәкъ шул мәгънәдә теркәлгән. **Тават** сүзе белән янәшә килгән **сияһ** сүзе фарсы телендә **кара** дигән мәгънә белдерә. (ГТРАС, 508.) Бу сүз Г. Тукайның «Китмибез!» шигырендә дә шул мәгънәдә кулланылган.

Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт – хөр Русия! Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруһе русияһ!

(Тукай, 186.)

Бу төркемдә урын алган **сәмых** сүзе шулай ук гарәп теленнән алынган. Ул **агач чәере** дигән мәгънә белдерә һәм хәзерге телдә очрамый. (ГТРС, 521.) Татар телендә озак вакытлар **циркуль** дип кулланылып, соңгы чорларда **җәзбә** варианты телебезгә кире кайткан сүзнең синонимы итеп **каләмдаирә** дигән сүз бирелгән. Сүз ике тамырдан тора. Һәр тамырның мөстәкыйль мәгънәләре безгә аңлашыла, ә кушма сүзнең мәгънәсен, әлбәттә, логик яктан аңлатып була. **Пәке, пычак** сүзләре **перочинный нож** дип тәрҗемә ителгән. Шул сүзләр янына тагын **каләмтараш** дигән бер сүз өстәлгән. Бу сүз дә телебездән төшеп калган. Шунысы сәер: без **точилка** дигән рус сүзен кулланабыз, ә үз сүзебезне оныткανбыз.

Һава торышы, табигать күренешләренә караган сүзләр дә кызыклы. **Шөгълә –** гарәп алынмасы. Ул **ялкын** дигән мәгънә белдерә. (ГТРАС, 716.) Ләкин И. Гиганов сүзлегендә аның мәгънәсе тарайган һәм **луч** дип тәрҗемә ителгән. **Гром** сүзенең татарча тәрҗемәләре итеп **күкүрт, йылдырым** дигән сүзләр бирелә, Бу ике сүз дә себер татарлары сөйләшләрендә бар, алар **күк күкрәү** дигән мәгънәдә кулланылалар. (Тумашева, 90, 103.) Әлеге төркемдәге сүзләр арасында бик борынгы төрки сүзләр дә очрый. Мәсәлән, **болак** сүзе **чишмә** дип бирелгән. **Болак** иске татар телендә **инеш** мәгънәсендә кулланылган, ә хәзер исә елга исемендә генә сакланган.

И. Гиганов сүзлегендә **уймур – заводь – әкрен ага торган елга култыгы** дип күрсәтелә. Татар теленең диалектологик сүзлегендә **уймур** сүзе казан арты сөйләшләрендә кулланыла торган лексик берәмлек итеп күрсәтелә һәм ул **уеп казылган урын** дигәнне белдерә. (ГТРАС, 453.)

Тагын бер тематик төркемгә тукталыйк. Монда телебездән төшеп калган, онытылган сүзләр шактый күп. Мәсәлән, **мәнсаб** дигән сүз хәзер кулланылышта юк. Ул гарәп теленнән алынган һәм **дәүләт хезмәте, хезмәт урыны** дигән мәгънә белдерә. (ГТРАС, 316. Сүзлектә **чин – дәрәҗә** дигән мәгънәдә теркәлгән. **Диван –** сенат сүзе дә хәзер кулланылмый. Без **диван** сүзен бары **йомшак урындык** мәгънәсендә генә кулланабыз. Ә бит Казан ханлыгында дәүләт киңәше – **диван** дип, ә **скипер диван башы** дип аталган. Сүз фарсы теленнән алынган, ләкин тамырында **дәүүана** (язу) дигән гарәп сүзе ята. (Әхмәтьянов, 84.) Бу төркемдә тагын түбәндәге сүзләр бар: **яу – война, яучы – воин, ләшкәр, чәрик – войска, би – князь, базаркян – купец, баккал – прасол, асламчы – ростовщик, йомыш** – **служба.** Бу сүзләрнең телебез тарихында кулланылышына тукталып үтик. **Чәрик** – **чирү** сүзенең иң борынгы формасы. Соңга таба бу сүз фонетик үзгәрешләр кичереп, чирүгә әйләнә. Чирү сүзе XVIII йөздә бик актив кулланылышта була, ә XIX йөздә кулланылыштан төшә һәм гаскәр сүзе белән алмашына. (Ногман, 103.) **Асламчы** – **асигъ** сүзеннән алынган. Хәзер ул онытылган,

элек файдалы эш дигән мәгънәне белдергән. (Ногман, 90.) **Би** сүзенең дә этимологиясе кызыклы. Бу сүз һуннар заманыннан ук билгеле. Ул төрки телләрдән күп кенә башка телләргә, шул исәптән гарәп теленә дә үтеп кергән. Сүзнең мәгънәсе – үзеннән дә дәрәҗәлерәк, көчлерәк хөкемдарга буйсынучы башка бер хөкемдарны белдерә, (Әхмәтьянов, 99.) **Базаркян** сүзе, күп еллар буе онытылып торып, соңгы елларда телебезгә кире кайту процессын кичерә, газета-журнал битләрендә бу сүз күренгәли башлады. Ул – фарсы алынмасы, **алыш-биреш итүче, сатучы** дигән мәгънәләр белдерә. (ГТРАС, 22.) Сүзлектә **баккал** – **прасол** дип бирелгән сүз **бәкъкаль** дигән сүздән килеп чыккан. Гарәп телендә бу сүз **ашамлык әйберләре кибете; яшелчә кибете тотучы** дигән ике мәгънә белдерә. (ГТРАС, 40.) Рус телендә аның мәгънәсе киңрәк «Прасол – оптовый скупщик скота и разных припасов для перепродажи». (Ожегов, 499.) Бу очракта сүздә мәгънә күчеше күзәтелә.

И. Гиганов сүзлегендә урын алган «Хайваннар», «Үсемлекләр», «Бөҗәкләр», «Ташлар», «Сыйфатлар» кебек төркемнәрдә теркәлгән сүзләрнең күбесе хәзерге татар телендәге кебек.

И. Гиганов 75 биттән торган сүзлегендә, күргәнебезчә, бүгенге көндә онытылган, телдән төшеп калган сүзләр шактый күп. Ә бит татар теленең әлегәчә өйрәнелмәгән бихисап сүзлекләре бар. Аларда күпме сүз, күпме байлык! Шул сүзлекләрдә теркәлеп, хәзерге телебездә яшәмәгән, төрле-төрле алынмалар белән кысрыклап чыгарылган сүзләребезне яңадан терелтү, телгә кайтару телчегалимнәр алдында торган иң мөһим бурычларның берсе булып тора.

Кыскартмалар.

ГТРАС – Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге.– Казан, 1965. – 853.

ТТДС – Татар теленең диалектологик сүзлеге. – Казан, 1969. – 642; 1993. – 458.

ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 2 том. – Казан, 1979. – 726.

Файдаланылган хезмәтләр

Гиганов И. Слова коренные, нужнейшие к сведению для обучения татарскому языку, собранные в Тобольской главной школе учителем татарского языка И. Гигановым и Юртовскими муллами свидетельствованные. – СПб., Имп. АН, 1801. – 75 с.

Ногман М. XVII – XVIII йөзләрдәге русча-татарча кулъязма сүзлекләр. – Казан: КДУ нәшр., 1969. – 110 б.

Ожегов С. И. Словарь русского языка. — М.: Русский язык, 1986. – 795 с.

Рәхимова Р. К. Татар теленең һөнәрчелек лексикасы. – Казан, 1983. – 159 б.

Тукай Г. Әсәрләр. 1 том. – Казан, 1985. – 405 б.

Тумашева Д. Г. Словарь диалектов сибирских татар. – Казань: изд-во КГУ, 1992. – 255 с.

Хайрутдинова Т. Х. Названия пищи в татарском языке. – Казань, 1993. – 140 с.

Әхмәтьянов Р. Татарлар – дәүләт коручылар токымы//Татарстан, № 11 – 12, 1995. – 79 – 86 б., №9 – 10, 1995. 90–99 б.

Scerbinin V. G. Turkçe okunuslu rusçe – turkçe cep sozlugu. – М.: Русский язык, 1995. – 512 с.

06

ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕН БАЕТУЧЫ ЧИШМӘЛӘР

Музейларга кергән саен, милләттәшләребезнең, кайда яшәүләренә карап, борынгы заманнарда нинди киемнәрдә сурәтләнгән фотоларга юлыгабыз. Экспозицияләргә куелганнарына карап, ул киемнәр белән якыннан танышу мөмкинлеге дә бар. Татарстанның Милли музеенда борынгыдан әстерхан, себер, касыйм, казан арты татарларының көнкүреш һәм бәйрәм өчен тегелгән төрледән-төрле киемнәрен күреп сокланабыз да гаҗәпләнәбез дә.Никадәр төрлелек! Милләттәшләребезнең кайда яшәүләренә карап, киемнәре генә түгел, сөйләмнәре дә үзгә бит. Күптән түгел «Татмедиа»ның киңәшмәләр залында журналистларны Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин җитәкчелегендәге галимнәр менә шул фән, ягъни диалектологиягә багышланган яңа хезмәтләре белән таныштырдылар.

Фото *http://shahrikazan.ru/news/yazmalar/kim-minullin-bashkort-telene-tnyak-knbatysh-dialekty-turynda-bary-blogerlar-gyna-syli*

Белгәнебезчә, диалектология фәне аерым бер төбәкләрдә тупланып яшәүчеләрнең сөйләм телен өйрәнә. Мәгълүм ки, татарлар, көнбатышта Рязань һәм Тамбов өлкәләреннән башлап, көнчыгышта Кемерово өлкәсенә һәм Красноярск краена, төньякта Вилюй елгасына, көньякта Әстерхан өлкәсенә хәтле сузылган гаять зур территориягә таралып утырганнар.

Татар халкының иң зур күпчелеге Татарстан һәм Башкортстан республикаларында гомер кичерә. Милләтебезнең яшәү үзәген тәшкил итүче бу республикалардан тыш, татарлар Россиянең күп кенә өлкәләрендә һәм милли республикаларында төпләнеп яшиләр.

Әлеге киңлекләрдә таралган татар теле өч диалектка – урта (казан татарлары), көнбатыш (мишәр) һәм көнчыгыш (себер татарлары) диалектларына бүленә.Татар шивәләрен төркемләүгә омтылыш беренче тапкыр 1881 елда тел белгеч һәм фольклорчы А. Бессонов тарафыннан ясала. Хәзер яшәп килгән классификациянең нигезен татар галимнәре Җ. Вәлиди, Л. Җәләй фикерләре тәшкил итә. Татар диалектларын, сөйләшләрен лингвогеографик юл белән өйрәнү һәм «Татар теле диалектологик атласы»н төзү сөйләшләр һәм диалектларның гамәлдәге классификацияләренә мөһим өстәмәләр һәм аныклыклар кертү мөмкинлеге тудыра.

Урта диалектка түбәндәге сөйләшләр керә: казан арты сөйләшләре төркеме (дөбьяз, мамадыш, лаеш, балтач –Татарстан), бәрәңге сөйләше (Мари), тау ягы сөйләшләре төркеме (норлат – Татарстан, Чувашия; кама тамагы, тархан – Татарстан), керәшен сөйләшләре төркеме (казан арты керәшеннәре сөйләше – Татарстан; түбән кама керәшеннәре сөйләше – Татарстан, Башкортстан; нагайбәк сөйләше – Чиләбе өлкәсе), минзәлә (Татарстан, Башкортстан), бөре (Башкортстан), касыйм (Рязань өлкәсе), бастан (Рязань өлкәсе), нократ (Удмуртия, Киров өлкәсе), пермь (Пермь өлкәсе), златоуст (Башкортстан), красноуфимск (Урал федераль округы), эчкен (Курган өлкәсе), каргалы, богырыслан (Оренбург), камышлы (Самара өлкәсе), әстерхан (Әстерхан, Волгоград өлкәләре, Ставрополь крае), татар-калпаклар (Волгоград, Саратов өлкәләре), турбаслы, тепекәй, учалы, сафакүл, кормантау (Башкортстан). Бу сөйләшләр зур территорияләргә таралуга карамастан, аларның төп үзенчәлекләре уртак. Урта диалект сөйләшләренең зур күпчелеге әдәби телгә аеруча якын тора.

Көнбатыш диалект вәкилләренең бер өлеше, ягъни мишәрләр, болгарлар Урта Идел, Түбән Кама җиренә күчеп килгәнче үк, Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы чорында акрынлап якын-тирә төбәкләргә үтеп кергән кыпчакларның варислары булып саналалар. Мишәр диалекты терминын беренче тапкыр Л.Җәләй үзенең «Татар телендә диалектлар» (1938) дип аталган фәнни хезмәтендә куллана. Система буларак, диалект Л.Мәхмүтова тарафыннан тасвирлана. Көнбатыш диалектның таралышын күрсәткән диалектологик карталарның системалы җыелмасы Урта Идел һәм Урал буе татар халкы сөйләшләре атласында урын ала.

Көнбатыш диалект ике зур сөйләш төркеменә бүленә: ч-лаштыручы һәм ц-лаштыручы сөйләшләр. Бу сөйләшләр телнең барлык өлкәләрендә дә бер-берсенә бик якын.

Ц-лаштыручылар төркеменә – сергач (Түбән Новгород өлкәсе), чүпрәле (Татарстан, Чувашия), байкыбаш (Башкортстан) сөйләшләре; ч-лаштыручылар төркеменә исә темников, ләмбрә (Мордовия), кузнецк (Пенза өлкәсе), хвалын, мәләкәс, карсун (Ульян өлкәсе),

тау ягы керәшеннәре, чистай керәшеннәре (Татарстан), эстәрлетамак (Башкортстан), шарлык (Оренбург өлкәсе), куршин (Тамбов өлкәсе), волгоград (Әстерхан һәм Волгоград өлкәләре, Ставрополь крае) сөйләшләре керә.

Ч-лаштыручылар арасында катнаш сөйләшләр дә бар. Болар – кузнецк (Пенза өлкәсенең көньяк-көнчыгыш өлешендә) һәм хвалын (Ульян өлкәсенең көньягында) сөйләшләре. Аларның чиген билгеләү шактый кыен, чөнки акрынлап бер-берсенә күчү процессы бара.

Көнбатыш Себер татарлары диалекты көнчыгыш диалект дип йөртелә. Бу термин беренче мәртәбә Л. Җәләй тарафыннан кертелгән һәм, көнчыгыш диалект дигәндә, Төмән, Омск, Томск, Новосибирск өлкәләрендә яшәүче себер татарларының теле күздә тотылган. Себер татарлары гаять зур территориягә таралып яшиләр. Бу исә төрле төркемнәр арасында аермалыкларның саклануына, аерым төбәкләр эчендә яңа күренешләр барлыкка килүгә китерә. Тубыл-иртыш диалекты зур территорияне үз эченә ала, һәм биш сөйләшкә: төмән, тубыл (Тубыл, Вагай, Яркәү районнары), саз ягы (Тубыл, Уват районнары), тәвриз (Омск өлкәсенең тәвриз, Усть-Ишим, Знаменское районнары), тара (Омск өлкәсенең Тара, Большеречье, Колосовка районнары) сөйләшләренә бүленә. Том диалекты – яүшә-чат (Томск өлкәсенең Томск районы) һәм калмак (Кемерово өлкәсенең Юрга районы) сөйләшләренә. Бараба (Новосибирск өлкәсенең Бараба, Куйбышев, Кыштау, Венгерово, Уба, Чан районнары) диалекты бер компакт төркемнең сөйләшен тәшкил итә.

Соңгы елларда башкарылган фәнни тикшеренүләр татар әдәби теленең формалашуында һәр диалектның ролен төгәлрәк билгеләргә мөмкинлек бирде. Татар диалектологлары барлык татар диалектларының да (урта – казан татарлары, көнбатыш – мишәрләр, көнчыгыш – себер татарлары (тубыл-иртыш, бараба, том диалектлары) нигезен борынгы кыпчак теле тәшкил итә, дигән нәтиҗәгә килделәр.

Әңгәмәнең шушы урынына килеп җиткәч, галимнәребезгә журналистлар тарафыннан Россиядә уздырылган җанисәп вакытларында Башкортстан Республикасында татарлар яшәгән районнарны һаман да «башкортларның төньяк-көнбатыш диалекты» дип, анда яшәүче татар халкын башкорт дип язу күренешләре күзәтелүе турында бирелгән сорауларын берләштереп, Ким Мөгаллим улы болай дип җавап бирде:

– Татар теленең диалектологик атласын төзегәндә, Россиянең татарлар яшәгән һәр төбәгендә, шул исәптән Башкортстанда да, халык сөйләшендә барокамералы акустик тикшеренүләр уздырылды, халык сөйләшендәге сүзләргә һәм җөмләләргә фонетик һәм синтаксик анализлар ясалды. Шуның нәтиҗәсендә, Башкортстандагы 54 районның 47сен, нигездә, татар милләте тәшкил итүе ачыкланды. Татарны башкорт дип язып кына, татарны үзгәртеп булмый. Мондый ямьсез уеннарда башкорт галимнәре катнашмый, бу– блогерлар һәм политтехнологлар эше.

Шулай итеп, татар теле диалектлары уртак системалы элементлар нигезендә милли телебезнең бер өлешен тәшкил итәләр.

Диалектлар һәм әдәби тел арасында үзенчәлекле аерма булу белән бергә, үзара тыгыз мөнәсәбәт тә яшәп килә. Җирле диалектлар, сөйләшләр хәзерге татар әдәби телен баетуда төп чыганак булып тора.

Ирек НИГЪМӘТИ

07

«БЕЗ БЕТӘ ТОРГАН КАВЕМ ТҮГЕЛ...»

ТАТАР МИЛЛӘТЕН САКЛАУДА РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН МИРАСЫНЫҢ ӘҺӘМИЯТЕ

Күптән түгел Болгар каласында «Россия мөселманнарының илаһият мирасы» исеме астында III Халыкара форум уздырылды. Шул Форум кысаларында «V Болгар укулары» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе дә үтте. Анда халкыбызның бөек мәгърифәтчесе һәм фикер иясе, язучы һәм журналист, күренекле педагог һәм тарихчы, гадел казый һәм атаклы мөфти Ризаэддин Фәхреддиннең (1859–1936) милләтне алгарышка илтү юлындагы күптөрле эшчәнлегенә яктыртылды.

1922 елда Ризаэддин Фәхреддинне (1859–1936) Мәскәү Кремлендә милләтләр эшләре буенча халык комиссары, соңрак «халыклар атасы» дип йөртелгән Иосиф Виссарионович Сталин кабул итә. Мөфти хәзрәтләре Россиядә, төгәлрәге Идел буе Болгар дәүләтендә, ислам динен рәсми кабул итүгә 1000 ел тулу уңаеннан, аңардан Казанда мәчет салу өчен рөхсәт сорый. Алдан күрүчән һәм хәйләкәр Сталин ризалык бирә. Мәчет бинасы халык акчасына дүрт ел төзелә һәм 1926 елда рухи мәркәзебездә зур дини тантана була – Кабан арты мәчете ачыла. Әмма яңа мәчеттә мөселман татарлар беренче һәм соңгы тапкыр җәмәгать намазы укыгач та, ОГПУ хезмәткәрләре шул ук көнне мәчет ишегенә ат башы кадәр йозак элеп куялар.

Уфада Россия империясенең, аннары СССР мөселманнары Диния нәзарәтенең архивын туплау һәм мөселман мәхәлләләреннән метрика кенәгәләрен бер җиргә җыю, тәртипкә салу кызыл террор һәм Сталин репрессияләре елларында Р.Фәхреддиннең зур батырлыгы иде, чөнки хәзер бу архив документлары татарга да үзенең нәсел шәҗәрәсен – ким дигәндә җиде буының белергә нык ярдәм итә.

Чын мөселман-мөэмин һәм дин галиме буларак, Ризаэддин Фәхреддин үз хезмәтләрендә «халык исламы»н, ягъни мәҗүсилек – күпаллалык чоры калдыкларын каты тәнкыйтьләгән һәм изгеләргә, изгеләр чишмәләренә, тау хуҗаларына табынуга каршы чыккан, һәм, берсүзсез, дөрес эшләгән, дип саныйм. Уйлап карасак, бүген дә безгә мондый беркатлылыкларга каршы Фәхреддинчә көрәшергә кирәк. Хәзер дә татарларның шактый өлеше им-томнарга, күрәзәчеләргә ышана, ләкин Аллаһы Тәгаләгә иман китерми, намаз укымый, ураза тотмый, ислам дине тарихын һәм фәлсәфәсен өйрәнми.

Шанлы тарихыбыз битләренә күз салсак, татар халкында җәдитчелек хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе саналучы Р.Фәхреддиннең татарларда XIX йөз ахыры – XX йөз башы дини мәгариф системасын тамырдан үзгәртеп кору турындагы фикерләре бүген дә әһәмиятен югалтмады, чөнки безнең чынбарлык шуны ачык күрсәтә, Россия Федерациясендә, гомумән алганда, милли мәгариф мәсьәләсе, хәзерге этапта әле һаман да уңай хәл ителеп бетми.

Дини реформатор Р.Фәхреддин патшабикә Екатерина Икенче фәрманы белән оешкан Оренбург Мөхәммәд Җыенын (ягъни Диния нәзарәтен) Россия империясенең самодержавие хакимияте мәнфәгатьләрен артык яклаганы өчен нык тәнкыйтьли. Бу структураны оештыруның максаты ул булмавын күрсәтеп, аның төп өч бурычын язып калдыра:

«1. Көнчыгыштагы ислам динен тотучылар тарафыннан Россиягә карата хөрмәт уятырга;

2. Россия җирендә рәсми статусы булмаган галимнәрне танымаска;

3. Идел һәм Җаек (Урал) елгалары буенда исламны рәсми дингә әйләндерергә һәм бөтен җирдә мәктәпләр, мәдрәсәләр ачарга».

Күп еллар мөселманнар өчен казый, ягъни судья булып торган Р.Фәхреддин Россия империясендә халык мәгарифе өчен патша билгеләгән мөфтиләр һичнәрсә эшләми һәм мөселманнарның белем бирү системасын үзгәртү, яхшырту өчен аларның статусы (мөфти император указы белән билгеләнгән) мөмкинлек бирми, дигән. Ләкин мондый катлаулы хәлдән чыгу юлы булганмы соң? Р.Фәхреддин туры юлны тапкан – ислам диненең дөньяда тоткан урының белергә кирәк, дип әйткән ул. Аның фикеренчә, ислам фәни дөньяның да, бакыйлыкның да барлык сорауларына җавап табарга тиеш. Ул, дини гыйлем белән беррәттән, дөньяви белем алуны да бик кирәк санаган. Безнең хәзерге чор олуг галимнең уй-фикере дөресләгән тагын бер тапкыр раслады. Бүген Болгар шәһәрендә төпле дини гыйлем бирә торган Болгар ислам академиясе, Казан каласында Россия ислам институты (РИИ), Казан ислам университеты (КИУ), атаклы «Мөхәммәдия», ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге югары мөселман мәдрәсәләре эшли. Моннан тыш, башкалабызның «Мәрҗани», «Сөләйман», «Гадел», «Рамазан», «Иман нуры» һ.б. мәчетләре каршында ачылган башлангыч мәдрәсәләр дә бар. Ата-бабайларыбызның гасырлар буе туплаган тормыш тәҗрибәсен истә тотып, акыл хәзинәсен үзләштерү, авыр язмышыннан гыйбрәт алу безне алда сагалап торган хаталардан саклап калырга булышачак, иманыбызны ныгыту юлында булган хыял-омтылышыбызны сүндермәячәк!

Белем һәм тәрбия бирү өлкәсендә Ризаэддин Фәхреддиннең мирасы аерым урын алып тора. Бүген тәрбия һәм әдәп-әхлак мәсьәләләре күбебезне нык борчый. Кая барабыз? Урлашу, алдашу, үтерү гадәти күренешкә әверелде. Тир түкми генә байлык туплау төп кәсепкә әйләнде, наркомания, җинаятьчелек, эшсезлек чәчәк ата. Яшьләрнең күбесе ак белән караны аера алмый, күңеле белән акчага, шул исәптән хәрәм малга табынып яши. Гасырлар буена буыннан-буынга күчеп килгән намуслылык, шәфкатьлелек, бер-береңә ярдәм итү, эчкерсезлек, саф мәхәббәт, үз ихтыяҗыңны башкаларныкыннан өстен куймау кебек әхлакый хәзинәләр аяк астына салып тапталды, онытылды.

Татар халкы тарихында тирән эз калдырган галимнәребез хезмәтләренә соңгы утыз елда зур игътибар итәбез. Бүген Р.Фәхреддиннең мирасы – белем һәм тәрбия өлкәсендә алыштыргысыз ярдәмче. Бөек мәгърифәтченең әсәрләре халыкка кире кайтты. Аның иҗатына багышланган фәнни-гамәли конференцияләр, педагогик укулар даими оештырыла.

Тәрбия темасына багышланган дәреслекләрендә Р.Фәхреддин: «Яшь буынны тәрбияләү эше ул – бик мөһим социаль мәсьәлә һәм үзенә укучыларның вә ата-аналарның даими игътибарын таләп итә», – дигән фикер әйтә. Ул чын күңелдән шуларны аңлатырга тырышып яши, мәгърифәт һәм белем тарата, әдәби һәм библиографик хезмәтләрендә тормышны реалистик карашлардан чыгып бәян итә. Аңа акыл һәм белемнең чикләнмәгән көченә ышану, мәгърифәтне ялкынлы пропагандалау, үстерү нәтиҗәсендә үз халкын бәхетле итәргә омтылу хас. Мәшһүр галимнең язган китапларын бергә тупласаң, зур күләмле энциклопедия килеп чыгар иде.

Педагог Р.Фәхреддин яшь буынның милли аңын һәм культура дәрәҗәсен үстерүне алгы рәткә куя. Аның хезмәтләре балаларны кешелекле, инсафлы, әдәпле, әхлаклы булырга өйрәтә. Хәзерге мәктәп-гимназияләрдә татар әдәбияты дәресләренең дә төп максаты шул.

Киң карашлы мәгърифәтченең һәрбер әсәре әхлак кануннарына, миллилеккә, мәгърифәткә мәхәббәт тәрбияләүдә алыштыргысыз мирас булып тора. «Балаларны изге итү юлы ничек? Аның юлы исә яшь вакытлардан башлап, яхшы тәрбия бирүдер. Бу эш – ата һәм ана өстендә иң олы бурыч», – дигән ул. Чынлап та, тәрбияле әти-әни генә тәрбияле бала үстерергә мөмкин. Бала иң беренче тәрбияне ата-ана үрнәгендә ала. «Тәрбияле аналар балаларны үзләре тәрбия итәрләр, мөмкин кадәр икенче кешегә тапшырмаслар. Чөнки баланы үз анасы кадәр һичкем тәрбия итә алмас».

Тагын ул болай әйткән: «Гыйлем вә тәрбия орлыкларын хәзер ихлас вә мәхәббәт илә чәчсәгез, киләчәктә файдалы җимешләрне дә үзегез җыярсыз».

Р.Фәхреддиннең әдәби әсәрләрендә дә, милләтне аң-белемле һәм һөнәрле итү белән бергә, әдәп-әхлак ягыннан тәрбияләүгә зур игътибар бирелә. Мисал өчен, язучының «Сәлимә, яки Гыйффәт», «Әсма, яки Гамәл вә җәза» романнарын күрсәтергә мөмкин. Бу кызлар яшьлегендә ата-анадан яхшы тәрбия алган, тормыш пычракларыннан кер дә кундырмыйча саф килеш калып, бәхеткә ирешәләр, дигән дөрес фикер уздыра автор. Әдипнең «Тәрбияле бала», «Тәрбияле ата», «Нәсыйхәт» китаплары – ата-ана һәм укытучылар өчен хәзинә!

Өметебез – хәзерге яшьләрдә. Максатыбыз – татар яшьләренең тотрыклы, иманлы булуы. Бер-беребезгә әдәпле, ихтирамлы, шәфкатьле булыйк! Шул вакытта гына үзебезгә әдәпле, милли үзаңлы, яхшы алмашчылар әзерли алырбыз. «Без бетә торган кавем түгел, бәлки дөньяда мәңге торыр вә башка милләтләр бергә берлектә җир йөзеннән файдаланыр өчен килгән милләтебез», – дип язды мәгърифәтче галим.

Йомгаклап әйткәндә, милләтне яшәтерлек яшь буын тәрбияләү –һәрберебезнең изге бурычы. Бөек шәхесне без генә түгел, киләчәк буын да онытмасын, аны өйрәнсен, аның хезмәтләрен куллансын һәм аның белән горурлансын иде! «Дөньяда яшәргә һәм башкалар рәтендә гомер сөрергә теләгән милләт үткән көннәрен белсен һәм үз тарихы белән дус булсын иде», – дип, Р.Фәхреддин милләтебезгә үз васыятен җиткергән.

Илһам ФӘТТАХОВ,

филология фәннәре кандидаты

08

ПРЕДМЕТНЫҢ УРЫНЫ. КАЙДА?

(Рус төркемендә татар теле дәресе. 1 нче сыйныф)

Рәсүлә АКИРОВА,

Казандагы 33 нче гимназиянең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Максат: предмет һәм затларның урынын, булу-булмавын әйтә алу күнекмәләрен үстерү; өйрәнгән лексиканы кабатлау, җөмлә төзү күнекмәләрен камилләштерү, диалогик сөйләмне ныгыту; әңгәмәдәшкә ихтирамлы һәм игътибарлы булу сыйфатларын тәрбияләү.

Дәреслек: «Сәлам» уку-укыту әсбабы. Р.Ф.Бәхтиев, Гаппасова Р.Ч., Карпухина Н.И., Кашафутдинова Г.В., Маркова Э.М., Якупов Р.Н. «Татар теле – илем теле» уку-укыту әсбабы. В.Н.Мещерякова.

Дәрес тибы: белем һәм күнекмәләрне комплекслы куллану дәресе (ныгыту дәресе).

Җиһазлау: флешкарталар, фломастерлар, А4 кәгазе, сәгать, йомшак уенчык (эт).

Ресурслар: «Сәлам» дәреслеге, «Сәлам» сайты.

Планлаштырылган нәтиҗә	Предмет буенча белем, күнекмәләр	Универсаль уку күнекмәләре
Предмет: предметның урынын әйтә белү, кайда? соравына җавап бирүче сүзләрне кулланылышка кертү. **Шәхси:**уку эшчәнлегендә үз-үзеңә дөрес бәя бирә алу, үзара дуслык хисен тәрбияләү. **Метапредмет:** **Регулятив:** дәреснең максатын таба һәм формалаштыра алу, үзеңнең эшчәнлегеңне куелган максатка нигезләнеп төзи алу. **Коммуникатив:** җибәрелгән хаталарны булган белемнәргә нигезләнеп төзәтә алу, башкаларның сөйләмен тыңлый, аңлый алу. **Танып белү:** укучыларның укытучы һәм сыйныфташлары белән эшчәнлеккә йогынты ясау; проблемалы биремнәр ярдәмендә укучыларда телне өйрәнүгә кызыксыну уяту.	***Тел күнекмәләре***: – Сүзләрнең мәгънәсен белү; – татар сүзләрен дөрес әйтү; – җөмләдә сүз тәртибен белү; – сүзләр белән сүзтезмәләр, җөмләләр төзи белү; – сорау формаларын куллана белү.	**Шәхескә кагылышлы УУГ:** – дөрес сөйләм булдыруга омтылыш; – үз фикереңне әйтә белү; – төркемнәрдә килешеп эшли белү; – иптәшеңә рухи ярдәм күрсәтә белү; – фикереңне дәлилли белү. **Регулятив:** – уку мәсьәләсен кабул итү һәм дәрес дәвамында шуның буенча эшләү; – куелган мәсьәлә нигезендә үз эшчәнлегеңне планлаштыру; – барлыкка килгән ситуациядә ориентлаша белү. **Танып белү:** – телдән сөйләмдә үз фикерләреңне формалаштыра белү; – тиешле мәгълүматны табу һәм аерып алу; – өлешләрдән бербөтенне төзи белү; – гомумиләштерү. **Коммуникатив:** – сөйләмнең диалогик формасы белән эш итә белү; – хезмәттәшлектә башкаларның фикерләрен исәптә тоту һәм карашыңны яклый белү; – үз фикереңне һәм карашыңны формалаштыру; – бердәм эшчәнлектә уртак нәтиҗәгә килү.

Оештыру		
Предметара бәйләнеш	**Эш формалары**	**Ресурслар**
Татар теле, уку, җыр	Индивидуаль, фронталь, парлап эшләү, төркемнәрдә эшләү	Флешкарталар, фломастерлар, А4 форматындагы кәгазь, сәгать, йомшак эт уенчыгы, «Сәлам» дәреслеге, «Сәлам» сайты.
Укытучы эшчәнлеге	**Көтелгән нәтиҗәләргә ирешү өчен укучылар өчен биремнәр**	**Укучыларның эшчәнлеге**
Уку эшчәнлегенә мотивация булдыру Уңай психологик халәт тудыру, дәрестәге эшчәнлеккә әзерләү. Тыңлап аңлау, кабул итү һәм анализлау өчен бирем формалаштыру.	**Оештыру моменты**. 1. Укытучы сыйныфка укучыларны матур сүзләр әйтеп каршы ала: – Әйдәгез, матур кызлар! Әйдәгез, яхшы малайлар! 2. Исәнләшү. – Исәнмесез,укучылар! Хәлләр ничек? – Кояшлы көн кебек, татар телен, Тукай телен өйрәнергә дип килдек. 3. Уңай психологик халәт тудыру. 4. Бер-берегезне дә сәламләгез әле, укучылар. *(Укучылар хәрәкәтләр белән бер-берсен сәламлиләр).* – Сәлам, дустым! – Хәлләр ничек? – Кайларда булдың? – Мин сине сагындым, син килдең, мин бик шат. «Сәлам!» җырын җырлау. *Сәлам, сәлам! Хәерле иртә!* *Сәлам, сәлам! Хәерле иртә!* *Хәлләр ничек? Бик шәп, рәхмәт!* *Сау бул, дустым! Хәерле көн!* – Рәхмәт,укучылар! Кызлар утыралар, малайлар да утыралар. – Сәгать кайда? *(Укучылар сәгатьнең урынын **анда, тегендә, монда, партада, тактада, стенада** сүзләрен кулланып әйтәләр.)* – Хәзер сәгать ничә? Әйдәгез, саныйбыз. *(Балалар кычкырып саныйлар.)* – Әйе, сәгать тугыз, татар теле дәресен башлыйбыз.	Укытучыны тыңлыйлар, сорауларга җавап бирәләр, сәламлиләр.
I. Актуальләштерү. **Уку мәсьәләсен кую** Укучылар белән диалог үткәрү, үтелгән тема буенча аңлашылмаган урыннарны билгеләү.	– Монда нәрсә бар? *(Сумка.)* – Әйе, сумка. Сумка нинди? *(Зур, кара.)* – Сумкада нәрсәләр бар? *(Дәфтәр, китап, пенал, каләм...)* – Әйдәгез, «Мәктәп-мәктәп» уйныйбыз. – Уйныйбызмы? – Мин – укытучы. Син укытучымы? Син укучымы? *(Һәркемнән сорап чыга.)* – Әйдәгез, басыгыз! *(«Укучы» сүзен хәрәкәтләр белән тиз-тиз кабатлыйлар.)* У- (куллар тезгә куела); КУ- (куллар билгә куела); ЧЫ- (куллар җилкәгә куела).	Сүзләрне кабатлыйлар, сорауга җавап бирәләр.

	(«Укытучы» сүзен хәрәкәтләр белән тиз-тиз кабатлыйлар). У- куллар тезгә, КЫ- куллар билгә, ТУ- куллар җилкәгә, ЧЫ- куллар башка. – Утырыгыз! **Флешкарталар белән эш.** – Бу нәрсә? Бу кем? Ул кайда? Мин укытучы түгел, син укытучы! *(2–3 укучы укытучы ролендә.)* – Бик яхшы! Рәхмәт!	
II. Уку мәсьәләсен чишү.	**1. «Сәлам» сайты белән эш. 1–2 уен уйнату.** **2. -мы/-ме кисәкчәләрен кабатлау.** *(Әйе, түгел сүзләрен куллану.)* – Бу китапмы? Бу дәфтәрме?.. **3.** Сайтта эш. Кайда? соравы. 4 нче дәрес, 1нче күнегү. Дәфтәр кайда? Китап кайда? Пенал кайда? **4. Ял минуты**. «Бас-утыр», «Әверелеш» уеннары уйналына. **5. Ишек шакыган тавыш.** – Анда кем бар? Әйдәгез, сорыйбыз. – Син кем? Син Мыраумы? Син аюмы? – Мин Акбай. Исәнме, Акбай. Балалар, исәнләшегез Акбай белән! – Сәлам, мин Акбай! Син кем? *(Укучыларны йөреп чыга.)* – Мин дә мәктәп уйныйм. Минем дәфтәр, китап, каләмем юк. – Миңа дәфтәр бирегез әле? – Мә, дәфтәр! – Рәхмәт! **6**. Парларда эш. «Бир әле» төзелмәсе белән диалог. **7. Сайтта эш. 5 нче дәрес. 1 нче күнегү.** **8.** Әйдәгез, җырлыйбыз. «Мәктәп» җыры. **9.** «Җавап бир». «Бар/Юк» сүзләрен куллану. – Мәктәптә сыйныф бармы? – Өстәлдә бетергеч бармы? – Пеналда карандаш бармы?	Компьютерда 2, 3 укучы уйный, калганнар уенның дөреслеген тикшерәләр. Диалог төзиләр. Диалогны тыңлыйлар, кабатлыйлар. Укучылар сорау бирәләр. Укучылар Акбайның сорауларына җавап бирәләр. Парларда диалог төзиләр.
III. Модель-ләштерү	Постер эшләү. Уртада кайда? соравы язылган. Укучылар рәсемнәрне «Мәктәптә», «Өйдә» сүзләре астына ябыштырып чыгалар.	Төркемдә эшлиләр, такта янына чыгып яклыйлар.
IV.Рефлексия	– Без бүген нишләдек? – Уйнадык, сөйләдек, тыңладык. – Сезгә дәрес ошадымы? Бәяләгез. Бер-берегезне бәяләгез. Бер-берегезне мактагыз. – Хәзер сәгать ничә? Әйдәгез, саныйбыз. *(Балалар кычкырып санийлар.)* – Әйе, сәгать 10, татар теле дәресен тәмамлыйбыз. Сау булыгыз!	Нәтиҗә ясыйлар.

09

ИСЕМ СҮЗ ТӨРКЕМЕН КАБАТЛАУ

(4 нче татар сыйныфында татар теле дәресе)

Ләйсән ГАЙНЕТДИНОВА,

Казандагы 57 нче урта мәктәпнең
I квалификация категорияле
татар теле укытучысы

Максат: исем турында белемнәрне тирәнәйтү, гомумиләштерү һәм исемне куллана белүләрен тикшерү; алган белемнәрне төрле ситуацияләрдә куллана белү, төркемнәрдә эшләү күнекмәләрен үстерү; укучыларда бер-берсенә дуслык хисләре, табигатькә сакчыл караш тәрбияләү.

Көтелгән нәтиҗәләр:

Предмет: исемнең мәгънәсе, сораулары, формалары, ясалышы, җөмләдәге ролен кабатлау, текстны дөрес төзүгә ирешү.

Метапредмет: эш төрләреннән кирәкле мәгълүматны таба белү, уку эшчәнлеге өчен нәтиҗәле алымнарны куллану, нәтиҗә чыгара, фикер йөртә, анализлый белү.

Шәхси: укучының башкаларны аңлавы, алар белән хезмәттәшлек итүе, төркемдә эшләү күнекмәсен үстерү, фикерне язма һәм телдән җиткерә алу, дәлилли алу; башкаларны тыңлый белү.

Дәреснең тибы: алган белемнәрне ныгыту.

Төп төшенчәләр: исем, предмет, кем? нәрсә?, килеш, ялгызлык һәм уртаклык исемнәр, берлек һәм күплек сан төшенчәләре.

Предметара бәйләнеш: әйләнә-тирә дөнья, рәсем сәнгате, рус теле, әдәбият.

Чыганаклар: дәреслек, Интернет, слайдлар, рәсемнәр.

Дәрес барышы

Оештыру-мотивлаштыру.

Укытучы. Хәерле иртә, укучылар! Бер-беребез белән исәнләшәбез.

Кулларга без тотындык,

Бер-беребезгә елмайдык.

Җылы күчте кулларга,

Рәхәт булды дусларга.

Укытучы. Утырдык, укучылар.

Һәр җир карланган,

Сулар бозланган,

Уйный җил-буран,

Бу кайчак, туган? **(1 нче слайд)** *(Кыш көне.)*

– Кыш турында. Кыш матур ел фасылымы?

– Димәк, без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшәчәкбез? **(2 нче слайд)** *(Кыш турында.)*

– Кыш нинди сүз төркеменә керә? *(Исем сүз төркеменә керә.)* Нинди сорауга җавап бирә? *(Нәрсә? соравына җавап бирә.)*

Укытучы. Укучылар, әйе, без бүген исем сүз төркемен кабатларбыз. **(3 нче слайд)**

Дәресебез үзенчәлекле булыр. Сезнең һәр төркемнең исеме бар: «Кышкы табигать», «Кышкы уеннар», «Яңа ел!», «Кышын кошлар».

Пазл төзегәнегез бармы? *(Әйе,бар.)* Без сезнең белән пазл төзербез. Әмма ул гадәти түгел. Мин серле капчыгыбыздан биремнәр алам, ә сез кайсы төркемгә каравын әйтергә тиеш буласыз, кемнең пазлы тизрәк төзелә карарбыз. Башладык.

Беренче төркем өчен: «Кышкы табигать»

1. Шигырь язып карагыз диелгән биремдә.

Шы-шы-шы

Ян тәрәзәгә каршы

Үсеп утыра ... *(чыршы)*.

Чыршы нинди сорауга җавап бирә? *(Нәрсә? соравына җавап бирә.)*

2. Ә.Бикчәнтәева шигыре бирелгән. Шигырьнең исемен кем әйтә? («Буранда»)

Тышта ыжгырып,

Җил-буран дулый,

Күзеңне ачып

Карап та булмый. **(4 нче слайд)**

Укытучы. *Буранда* сүзе нәрсә белән төрләнгән? *(Килеш белән төрләнгән.)*

– Кайсы килештә? *(Урын-вакыт килешендә.)*

– Күплек санда ничек була? *(Бураннарда.)*

– Ни өчен *-нар* кушымчасы ялгыйбыз? *(Чөнки сүз [н] авазына тәмамлана.)*

3. **Сынамыш.** Кыш кар күп булса, җәй яңгырлы булыр.

Капма-каршы исемнәрне, антонимнарны әйтегез әле. *(Кыш – җәй.)* **(5 нче слайд)**

4. **Табышмак.**

Ишегалды таш була,

Өйгә керсә, су була. *(Боз.)* **(6 нчы слайд)**

Күплек санда ничек була? *(Күплек санда бозлар була.)*

Икенче төркем өчен: «Кышкы уеннар»

1. Биремдә табышмак бирелгән. **(7 нче слайд)**

Шома табанлы чана

Атсыз да алга чаба –

Җитез булса аяклар,

Кулда була таяклар.

Бар бер чана,

Утырасы юк,

Бассаң – үзе чаба.

Нәрсә ул? *(Чаңгы.)* Әйе, чаңгы. *(Балаларны активлаштыру.)* Кемнәр чаңгыда шуарга ярата икән, кая күрим әле?

2. **«Кар атыш» сорау-җавабы**

Һәр төркем исеме белән бәйле кыш турында сорау бирә һәм кар йомарламын икенче төркемгә ата.

Бу бирем кайсы төркемнеке?

3. «Шуабыз» (Н. Мадьяров) шигырен кайсы төркемгә кертәбез? **(8 нче слайд)**

Чанада да шуабыз,

Чаңгыда да шуабыз.

Тимераякта очабыз,

Чыжлап тора шома боз.

– Ничә исем кулланылган? *(4 исем кулланылган.)*

– Исемнәрне санагыз. *(Чанада, чаңгыда, тимераякта, боз.)*

4. **Укытучы.** «Кыш рәхәт чанага, җәй рәхәт арбага» дигән татар халык мәкалендә билгеләнгән сүзләр нинди килештә? **(9 нчы слайд)** (Юнәлеш килешендә.)

Бу бирем кайсы төркемгә карый? *(3 нче төркем өчен: «Яңа ел!»)*

1) Төсен үзгәртми бер дә,

Гел яшел күлмәк кия.

Матур бизәнеп, һәр елны

Безгә кунакка килә.

Нәрсә ул? **(10 нчы слайд)**

Балалар, *чыршы* сүзенә тамырдаш сүзләр әйтегез әле. *(Чыршыкай.)*

2) Без бүген чыршы янында

әйлән-бәйлән уйнарбыз.

Кыш бабайны каршыларбыз,

яңа җырлар җырларбыз.

3) **Сорау.** Календарьның соңгы битендә нинди дата торырга тиеш? *(31 декабрь.)*

– 31 декабрь нинди көн? *(Елның соңгы көне.)*

Анда теләк тә язылган.

Котлыйбыз барчагызны

Яңа ел бәйрәме белән.

Каршы алыйк Яңа елны

Бәхет шатлыклар белән.

4) Безгә Кыш бабай килгән,

Яңа ел алып килгән.

Капчыгына күп итеп

Бүләкләр салып килгән. **(11 нче слайд)**

Ялгызлык һәм уртаклык исемнәргә бүлегез. *(Кыш бабай, Яңа ел, капчыгына, бүләкләр.)*

Дүртенче төркем өчен: «Кышын кошлар»

1) **Сорау-табышмак.** Нинди кош көне буе үзенең исемен кычкыра? *(Карга.)*

– Кышын нинди каргаларны күреп була? *(Ала каргаларны күреп була.)*

2) **Табышмак.**

Җәй тукылдый бу чүкеч,

Кыш тукылдый бу чүкеч,

Ничек чыдый бу чүкеч? *(Тукран.)* **(12 нче слайд)**

Табышмакта нинди сүзләр кабатлана? *(Тукылдый, чүкеч сүзләре кабатлана.)*

Кайсысы исем сүз төркеменә карый? *(Чүкеч сүзе исем сүз төркеменә карый.)*

3) – Бу нәрсә? (**13 нче слайд**) *(Җимлек.)*

– Сүзнең тамырын табыгыз.

4) Сынамыш бирелгән.

Кыш көне ала карга агач башына кунса – яз тиз, җиңел килер; җиргә кунса – озак килер.

Бирем: һәр төркем үз пазлын җыеп бетерде. Килеп чыккан рәсемнәрегез буенча исемнәрне кулланып, 7–8 җөмләдән торган хикәя төзегез. 5 минут вакыт бирелә.

Музыка. Кышкы табигать. Укыту.

Укытучы. Дәфтәрләрне ачабыз, числоны, сыйныф эшен язабыз. **(14 нче слайд)** Ике кеше такта янына чыга, ә калганнар дәфтәрдә пөхтә итеп язасыз. Иҗекләрдән сүзләр төзү. Кичәге буран, безнең сүзләрне туздырып, кар өеме ясап куйган. Әйдәгез, сүзләр килеп чыксын өчен, иҗекләрне урыннарына куйыйк:

1) чаң – … да

ча – … да

ти – … – … – та

на, мер , аяк, гы

Нинди җөмлә төзедегез? *(Балалар кышын чаңгыда, чанада, тимераякта шуалар.)*

2) шу –… – …

кә – … – …

ба – ... – ...

ла, лар , лак, шә, кә, га

Җөмлә төзегез. *(Балалар шугалакта кәшәкә белән хоккей уйныйлар.)*

Яхшы. Балалар, сез ничек уйлыйсыз, җөмләләр, сүзләр дөресме? Сездә дә шундый җөмләләрме?

Укытучы. Балалар, бүген дәрестә нәрсә кабатладык? *(Исем сүз төркемен кабатладык.)*

– Ул нинди сорауларга җавап бирә? *(Исемнәр кем? нәрсә? сорауларына җавап бирә.)*

– Исем нәрсә белән төрләнә? *(Исемнәр килеш белән төрләнә.)* Нинди санда килә? *(Берлек һәм күплек санда килә.)*

– Нинди исемнәр була? *(Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр.)*

Дәрестә нәрсәләр истә калды? Кыш турында нәрсәләр ишеттегез? *(Шигырьләр, сынамышлар, табышмаклар.)*

Яхшы, дәресне дәвам итәбез. Тиздән нинди бәйрәм җитә? Шушы бәйрәм белән бәйле «Әйе, юк» уенын уйныйбыз. Мин сезгә сорау бирәм, ә сез я «юк», я «әйе» диярсез. Башладык.

Кыш бабайны барлык кеше дә беләме? *(Әйе.)*

Ул нәкъ сәгать 7.00 дә киләме? *(Юк.)*

Кыш бабай бик әйбәт бабаймы? *(Әйе.)*

Ул башына эшләпә, аягына галош киеп йөриме? *(Юк.)*

Кыш бабай салкыннан куркамы? *(Юк.)*

Кар кызы белән Кыш бабай дуслармы? *(Әйе.)*

Ул тиздән килеп җитәме? *(Әйе.)*

Кыш бабай бүләкләр алып киләме? *(Әйе.)*

Бүген ул сезгә бүләкләр җибәрде, кайсы төркемнең кар бөртекләре күбрәк – «5» билгесе куябыз, сез ризамы? Ә менә монысы – Кыш бабайдан бүләк.

Икенче төркемгә «4» куябыз һәм бүләк тапшырабыз.

Өченче төркемгә киләчәктә тагы да тырышырга кирәк, ә Кыш бабай сезне дә бүләксез калдырмас.

Өй эшен һәркем үз мөмкинлегенә карап сайлап ала. **(15 нче слайд)**

Дәресебезне сезгә теләкләрем белән тәмамлыйсы килә:

Котлыйм сезне киләчәк бәйрәм белән,

Чынга ашсын теләкләрегез,

Бәхетле булыгыз, дусларым!

Күңелле үтсен каникулларыгыз!

Сау булыгыз!

10

СИНОНИМНАР

(5 нче сыйныфта татар теле дәресе)

Рәмзия ХӨСӘЕНОВА,

Әтнә районы Сибгат Хәким исемендәге Күлле Киме төп гомуми белем мәктәбенең I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Дәрес тибы: яңа теманы өйрәнү.

Максатлар:

1. Белем бирү максаты
– синонимның мәгънәсен аңлату;
– синонимнарның ни өчен кулланууларын билгеләү;
– сөйләмдә синонимнарны файдаланырга өйрәтү.

2. Үстерү максаты
– төркемнәрдә һәм парларда эшли белү күнекмәсен үстерү;
– сорауларга төгәл җавап бирү күнекмәсен камилләштерү.

3. Тәрбияви максат
– туган телгә ихтирам тәрбияләүгә этәргеч ясау;
– якташ шагыйрьләребез иҗатына мәхәббәт тәрбияләү.

Җиһазлау: компьютер, проектор, «Татар теленең синонимнар сүзлеге», татар кызы рәсеме, кластер төзү өчен карточкалар, сүзләр язылган карточкалар, тест биремнәре, серле тартма.

Дәрес барышы

I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

1. Уңай психологик халәт тудыру.

Укытучы. Исәнмесез, укучылар!

Укучылар. Хәерле көн, укытучым!

Укытучы. Кәефләрегез ничек?

Укучылар. Кояшлы иртә кебек *(1 нче бала)*

Анам теле – татар теле. *(2 нче бала)*

Милләтемнең бердәнбере *(3 нче бала)*

Син булганга без дә тере. *(4 нче бала)*

Укытучы. Укучылар, әйтегез әле, 2021 ел нинди ел буларак билгеләп үтелә?

Укучылар. 2021 ел – Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы, дип игълан ителде.

Укытучы. Димәк, без туган телебезгә тагын да якынаерга, аны тагын да күбрәк өйрәнергә тиешбез.

II. Белемнәрне актуальләштерү

1. Кластер төзү.

Укытучы. Укучылар, без тел белеменең нинди бүлеген өйрәнәбез?

Укучылар. Лексика.

Укытучы. Ә нәрсә соң ул лексика?

Укучылар. Билгеле бер телдәге сүзләр һәм әйтелмәләр җыелмасы.

Укытучы. Без нинди темаларны өйрәндек?

Укучылар. Бер һәм күпмәгънәле сүзләр, туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләр, антонимнар.

Укытучы. Балалар, минем кулымда серле тартма. Аның эчендә сүзләр җыелмасы. Шул сүзләрне алып, аларны кластерга үз урыннарына урнаштырыйк әле. Иптәшегез дөрес җавап бирсә, кул чәбәкләрсез. Ялгышса, аңа ярдәм итәрсез.

Тамыр, җил елый, чәчәк, татлы йокы, китап, кыек–туры, тел, саран кыз һ.б.

Укытучы. Рәхмәт, укучылар.

III. Уку мәсьәләсен кую

Укытучы. Ә хәзер экрандагы текстны укыйк әле . *(Балалар эчтән укыйлар.)*

Бу кыз бик матур булып, матур йөзеннән нур бөркелә. Матур гәүдәсенә кигән киемнәре килешеп тора. Озын матур толымлап үрелгән чәчләреннән аның чын татар кызы икәне күренә. Үз-үзен тотышы аның эчке дөньясының да матур икәнлеген күрсәтеп тора.

Укытучы. Сезгә текст ошадымы?

Укучылар. Ошады, ошамады.

Укытучы. Ни өчен?

Укучылар. Кызның тышкы матурлыгын сурәтли.

Матур сүзе кабатланып килә.

Укытучы. Әйе шул, балалар, *матур* сүзе кабатланып килгәч, текст матур яңгырамый. Әйдәгез әле, *матур* сүзен башка төрле сүзләр белән алыштырып булмас микән? Бергәләп уйлап карагыз әле.

Укытучы. Балалар, матур сүзен нинди сүзләр белән алмаштырдыгыз? *(Балалар тактадагы татар кызы рәсеме янына сүзләрне эләләр.)*

Чибәр, нәфис, сөйкемле, күркәм, гүзәл, сылу, зифа, нурлы. *(Калган сүзләрне укытучы үзе әйтеп бетерә.)*

Укытучы. Балалар, карагыз әле,

Менә нинди икән бит ул татар кызы,

Үз милләтен чын күңелдән яратучы.

Укытучы. Сез әйткән сүзләр арасында нинди уртаклык бар, укучылар?

Укучылар. Мәгънәләре охшаган. *Матур* сүзенә охшаганнар һ.б

Укытучы. Мәгънәләре охшаган сүзләр ничек дип атала?

Укучылар. Синонимнар.

Укытучы. Дөрес, балалар. Димәк, безнең бүгенге дәресебезнең темасы ничек була?

Укучылар. Синонимнар.

IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү

1.Синонимик рәт һәм доминанта сүз белән таныштыру.

Укытучы. Дәфтәрләрне ачып, бүгенге числоны, сыйныф эше, **Синонимнар** дип язабыз. Димәк, балалар, синонимнар дип охшаш мәгънәле яки мәгънәдәш сүзләрне атыйбыз икән. *(Дәреслектәге кагыйдәне укыйлар.)*

Укытучы. *Матур* сүзенә тапкан сүзләр төркемен синонимик рәт яки синонимик оя диләр. Сөйләмдә бу сүзләрнең кайсысы еш кулланыла?

Укучылар. Матур.

Укытучы. Шуңа күрә *матур* сүзен доминанта сүз дип атыйлар.

2. Сүзлек диктанты.

Укытучы. Хәзер, балалар, мин сезгә

сүзләр әйтәм, ә сез аларны дәфтәрләрегезгә язып барырсыз.

Укытучы, белем, укучы, көндәлек, мөгаллим, гыйлем, шәкерт, каләм, билге, фән, татар теле, остаз.

Укытучы. Хәзер дәфтәрләрегезне күршегез белән алмаштырасыз, экраннан карап тикшерәсез һәм билге куясыз.

Укытучы. Укучылар, бу сүзләр арасында якын мәгънәле сүзләр бармы? Эзләп карыйк әле.

Укытучы, мөгаллим, остаз.

Укучы, шәкерт.

Белем, гыйлем.

Укытучы. Без мәгънәләре буенча бер-берсенә якын сүзләр төркемен күрсәттек. Беренче рәттә доминанта сүз кайсы?

Укучылар. Укытучы.

Укытучы. Икенче юлда? Өченче юлда? *(Укучы, белем.)*

3. Синонимнар сүзлеге белән эшләү.

Укытучы. Менә минем кулымда «Синонимнар» сүзлеге. Бу сүзлектә сүзләрнең синонимнары бирелгән. Әйдәгез әле, балалар, туган тел сүзенең синонимнарын эзләп карагыз әле.

Укучылар. Туган тел, ана теле, үз телең.

Укытучы. Укучылар, сүзтезмәләр белән җөмләләр төзеп карыйк әле.

V. Ял минуты

З.Минһаҗева башкаруындагы «Туган тел» җырына татарча бию хәрәкәтләре ясау.

VI. Модельләштерү

1.Шигырь юлларыннан синонимнар табу.

Укытучы. Укучылар, безнең шагыйрьләребез үзләренең шигырьләрендә синонимнарны бик еш кулланганнар. Менә бер шигырьне укып карыйк әле.

Укучылар. Үсте, зурайды дүрт яран,

Һәркайсы өчен янам.

Укытучы. Укучылар, бу шигырьне кем язган? *(Экранда С.Хәким фотосы.)*

Укучылар. Сибгат Хәким.

Укытучы. Әйе, укучылар, бу – С.Хәкимнең «Дүрт яран» шигыреннән. Кем ул С.Хәким?

Укучылар. Ул – безнең авылдашыбыз. Күренекле шагыйрь. Мәктәбебез дә аның исемен йөртә. Безнең мәктәптә аның музее бар. Җитәкчесе – Гөлсинә Габдулхак кызы. С.Хәкимнең тууына быел 110 ел тула.

Укытучы. Әйе, укучылар. Әйдәгез, шигырь юлларына тагын бер кат игътибар итик әле: монда синонимнар бармы?

Укучылар. Бар: *үсте, зурайды.*

Укытучы. Афәрин! Хәзер икенче шигырьне укып карыйк.

Укучылар. Мөлдерәмә тулы чиләкләрне

Иңнәремә хәтле сагынган.

Укытучы. Ә бу шигырь юлларын кем язган, беләсезме (таныйсызмы)? *(Экранда Л.Шагыйрьҗан фотосы.)*

Укучылар. Л.Шагыйрьҗан.

Укытучы. Әйе, дөрес. Лена Шагыйрьҗанның «Чишмә эзлим» шигыреннән. Әлеге шагыйрә турында нәрсә беләсез?

Укучылар. Л.Шагыйрьҗан – шагыйрә. Безнең авылда тумаса да, Күлле Кимедә яшәгән. Тик шулай да Күлле Кимене ул туган авылыдай якын күргән.

Укытучы. Ә бу юлларда синонимнар бармы?

Укучылар. Әйе. Мөлдерәмә, тулы.

Укытучы. Кайсы сүз доминанта була?

Укучылар. Тулы.

2.Синонимик рәт төзү.

Укытучы. Безнең авылыбыздан нинди атаклы, күренекле язучылар чыккан,

балалар. Без алар белән горурлана алабыз. Әйдәгез әле, *атаклы* сүзе белән синонимик рәт төзеп карыйк әле. *(Сүзлектән карарга була.)* Бу сүзләр белән җөмләләр дә төзеп карыйк.

Атаклы, күренекле, танылган, атказанган, мәшһүр, данлыклы, шөһрәт казанган.

Укытучы. Бу сүзләр белән җөмләләр төзеп, дәфтәрләргә язып куйыйк.

Укытучы. Доминанта сүзләрне табып карыйк әле, балалар. Кайбер доминанта сүзләр берничә дә булырга мөмкин.

Күренекле, танылган – доминанта.

Укытучы. Балалар, синонимнар ни өчен кирәк икән?

Укучылар. Сөйләм теле бай булсын өчен, сөйләмебез төгәл булсын өчен һ.б.

3. Дәреслектәге күнегүне эшләү.

Укытучы. Хәзер 466 нчы күнегүне эшлибез. Монда сүзләрнең синоним парларын табарга кирәк. Әгәр дә үзегез таба алмыйсыз икән, сүзлеккә мөрәҗәгать итәргә дә була.

4. Тест эшләү.

Укытучы. Мин хәзер сезнең белемегезне тикшереп карыйсым килә. Аның өчен тест эшләп алабыз. *(Җавапларны үзләре экраннан тикшерәләр һәм билге куялар.)*

1. Синонимнар дип нинди сүзләрне атыйлар?
1. Охшаш мәгънәле сүзләр.
2. Капма-каршы мәгънәле сүзләр.
3. Мәгънәсез сүзләр.

2. Доминанта дип нинди сүзне атыйлар?
1. Зур сүз.
2. Кечкенә сүз.
3. Төп сүз.

3. *Өй* сүзенең синонимын билгеләгез.
1. Фатир.
2. Бина.
3. Йорт.

4. Без туган телебезне яратабыз, ... җөмләсенә синоним сүз өстәгез.
1. Сөябез.
2. Сөйлибез.
3. Мактыйбыз.

5. Синоним сүзе кайсы телдән кергән?
1. Гарәп.
2. Фарсы.
3. Грек.

6. Синонимнарны кайсы сүзлектән карап була?
1. Антонимнар сүзлеге.
2. Синонимнар сүзлеге.
3. Орфографик сүзлек.

VII. Рефлексия, бәяләү

Укытучы. Балалар, кайсыгыз бүген теманы аңладым, сорауларым юк дип уйлый, менә болай итеп кулларны, өскә күтәреп, кырыйга җәябез.

Кемнәр әле сорауларым калды дип уйлый, бер генә кулны күтәрә.

Кем берни аңламадым дип әйтә, кулларны парта өстенә куеп утыра.

VIII. Йомгаклау

Укытучы. Укучылар, бүгенге дәрес өчен сезгә бик зур рәхмәт. Туган телегезне беркайчан да онытмагыз.

IX. Өй эше

1. Сибгат Хәкимнең шигырьләреннән синонимнар кергән юлларны күчереп язарга (2 мисал).
2. Синонимнар кертеп, туган тел турында шигырь язарга.

КИТАПЧЫ ГАЛИМ

(5 нче сыйныфта Әбрар Кәримуллинга багышланган сыйныфтан тыш уку дәресе)

Гөлнара ҺАДИЕВА,

Саба районы Эзмә урта мәктәбенең
I квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Дәрес тибы: сыйныфтан тыш уку.

Максат: ***эчтәлек ягыннан:*** Әбрар Кәримуллинның тормыш юлы, иҗаты буенча күзаллау булдыру, татар китабына багышланган эшчәнлеге белән таныштыру, кеше тормышында китапның зур әһәмияткә ия булуын ачыклау; ***эшчәнлек ягыннан:*** күзәтү аша эшчәнлекне анализлау күнекмәләре формалаштыру, рәсемнәр белән тест эшләү алымнарын камилләштерү.

Бурычлар: укучыларның белемендә эзлекле бер система булдыру; сөйләм күнекмәләрен үстерү; укучыларны фикер йөртергә күнектерү.

Планлаштырылган нәтиҗә:

Шәхси нәтиҗәләр: белем алуның кирәклеген аңлау; үз-үзеңне әдәп кагыйдәләренә туры килерлек итеп тоту.

Метапредмет нәтиҗәләр:

Регулятив УУГ: дәрескә куелган максатны аңлау, үз нәтиҗәләреңне бәяли белү, укучылар уку мәсьәләсен чишү өчен кирәкле эшчәнлек алып бару мөмкинлеге алачак.

Танып белү УУГ: дәреслек белән эшләү, укытучының сорауларына җавап бирү, гомумиләштерү, нәтиҗәләр ясау.

Коммуникатив УУГ: диалог алып баруга әзерлек, коллективта үз фикеренә анализ ясау мөмкинлеге алачак, бирелгән мәсьәләләрне чишү юлларын табачак; җиткерә белү, укучы башка укучыларның фикерләрен тыңлау, аларга карата үз фикерен белдерә алу мөмкинлеген алачак, фикерен телдән төгәл һәм дөрес итеп әйтү турында уйлаячак.

Предмет нәтиҗәләре: Әбрар Кәримуллинның тормыш юлы хакында күзаллау булдыру һәм аның татар китабы тарихына керткән эшчәнлеге турында белү, тикшерү биремнәрен үтәү.

Предметара бәйләнеш: рус әдәбияты, тарих.

Эшчәнлекне оештыру формалары: әңгәмә, акросүз төзү, кроссенс алымы, тест эшләү, парларда һәм төркемнәрдә эш, фронталь һәм индивидуаль эш, уен технологиясе, компьютер технологиясе.

Төп ресурслар: Әбрар Кәримуллин портреты, китаплар күргәзмәсе.

Өстәмә ресурслар: компьютер, проектор, видео (https://youtu.be/vDpt6Slrv2E), презентация, LearningApps – интерактив күнегүләр конструкторы (https://learningapps.org/display?v=pq8ivu8ka21), ZipGrade – мобиль приложениесе, кроссенс өчен рәсемнәр, дәрескә керү билетлары, үзбәя өчен «Уңышлар карточкасы».

Дәрес барышы

Дәрескә кадәр укытучының әзерлек эше: кабинет ишегенә «Дәрескә керү билеты» ябыштырыла. Дәрескә кергәндә, һәрбер укучы 1 билет ала, аны укый.

I. Оештыру өлеше. Уңай эмоциональ халәт тудыру

Укытучы.Хәерле көн, исәнмесез, укучылар! Көнне яхшы сүз белән башласаң, бөтен көнең яхшы үтәр, диләр. Әйдәгез, бер-беребезне яңа көн белән котлап, матур сүзләр әйтик әле.

(Хәерле көн! Яңа көн тынычлык алып килсен! Көннәр имин булсын! Яңа көн күп бишлеләр алып килсен! һ.б.)

Укытучы. Иртә таңнан балкып чыккан кояш та сезгә бары шатлык китерсен, йөзегездәге елмаюлар беркайчан да сүрелмәсен. Экрандагы кояш төсле күңел күтәренкелеге теләп калам. **(Слайд)** Бүгенге көннең тууына шатланып, исән-сау булуыбызга сөенеп, әдәбият дәресен башлыйбыз.

Дәресебезне күпкырлы шәхес, педагог, олпат дин әһеле Р. Фәхреддиннең гыйбрәтле сүзләре белән дәвам итәсем килә. «Кешеләрне шатландыруың – үзеңне шатландыруыңдыр». Димәк, бүген сез үзегезнең ныклы белемнәрегез белән куандырырсыз, ә мин сезне яхшы билгеләрем белән шатландырырмын.

II. Проблемалы ситуация булдыру

Укытучы. Ә бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләшәчәгебезне белү өчен, сезгә дәрескә кергәндә, алган билетларны кулланырбыз. *(Укучылар берәм-берәм билетка язылганнарны сәнгатьле итеп укыйлар.)*

1 нче билет.

Һич тә күңлем ачылмаслык эчем пошса,

Үз-үземне куәлмичә, рухым төшсә,

Җәфа чиксәм, йөдәп бетсәм, бу башымны

Куялмыйча җанга җылы һичбер төшкә;

Шул вакытта мин кулыма китап алам... (Г.Тукай. «Китап» шигыре)

2 нче билет. Китап дигән дөнья бар. Китап дигән галәм бар. Уйлана башласак, алай гына микән? Ай-һай зур мәгънә ята китап сүзендә. Тормышта бүгенге дәрәҗәсенә килеп җиткәнче, китап үз тарихында гыйбрәтле юл узган, күптөрле язмышларга очраган. Халыкны котыртучы, юлдан яздыручы дигән әллә нинди нигезсез гаепләүләр, нахак бәлаләр тагып, учакларда яндыру, таш бәйләп суга салулар дисеңме, терелә җиргә күмү дисеңме… Зинданнарга ябылуларны, башка золым-золмәтне дә еш күрергә туры килгән аңа. Берәүләр аны, иң яман дошманы күреп, туктаусыз эзәрлекләсәләр, икенчеләре изге санап, аны иң кадерле хәзинә итеп сакларга, буыннан-буынга тапшырырга, аның гомерен озайтырга тырышканнар. Изге Коръән-Кәрим – мөселманнарның әнә шундый китабы.

3 нче билет.

Адаштырмый әйдәп барасың син,

«Нәрсә бар соң сиңа тиң тагын», – дим.

Башым иеп, сиңа табынамын –

«Рәхмәт сиңа, Татар китабы!» – дим.

4 нче билет.

И китабым, и китабым,

Миңа ачык кыл хитап;

Син генә башымдагы чүп-

Чарны алырсың утап.

(Шәехзадә Бабич. «И китап!»)

5 нче билет. Китап исемле дөнья бар. Китап дигән галәм бар. Бу галәмне үзенә сыйдырган галим, олуг зат бар. Ул – татар китабы тарихы буенча армый-талмый эшләгән галим Әбрар Кәримуллин. Райондашыбыз, дөньякүләм танылган китап тарихы белгече, академик, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе иясе, сугыш ветераны, милләтебез бәйсезлеге өчен көрәшкән, татар тарихы буенча йөзләгән хезмәт язган танылган галимебез Әбрар ага Кәримуллинның тууына быел май аенда 96 ел тулды.

Укытучы. Сез укыганнардан чыгып, ни әйтә аласыз? Уртак һәм аермалы яклар бармы? Нинди уртак сыйфатлар бар? Дәреснең темасы нинди булачак инде? Нинди фикергә килдегез? *(Китап, китапчы галим Әбрар Кәримуллин эшчәнлеге турында.)*

III. Уку мәсьәләсен кую һәм чишү юлларын эзләү

Укучылар, дәреснең темасын ачыкладык. Ә бүгенге дәрестә без нишләрбез икән? Әйдәгез, ачыклап үтик. Үзегезгә нинди максатлар куярсыз ? *(Әбрар Кәримуллинның тормыш юлын, иҗатын өйрәнергә. Аның иҗади эшчәнлеге турында белергә. Татар китабы тарихы турында күзаллау булдырырга.)*

Укытучы. Сезнең һәрберегезгә «Уңышлар карточкасы» бирәм. Анда үзегезнең исем, фамилиягезне язып куегыз һәм, һәр эш төрен үтәгәннән соң, эшегезне бәяләп барырга онытмагыз.

Укытучы. Әдәбият дәфтәрләренә бүгенге числоны, теманы язып куйыйк.

IV. Уку мәсьәләсен чишү

Укытучы. Укучылар, сез галим турында нәрсәләр беләсез? Ул кайда туган? Нинди хезмәтләр башкарган? Әлеге сорауларга җавап табу өчен, видео карап алабыз. *(https://youtu.be/vDpt6Slrv2E)*

Укытучы. Видео буенча алган белемнәребезне дә кулланып, карточкалар аша эзләнү эше оештырабыз. Төсле карандашлар белән мөһим урыннарны билгеләп барыгыз. Башладык.

1925 елның 29 маенда районыбызның Чәбия Чурчи дигән гади татар авылында дөньяга килә. Яшьләй әнисез кала. Ике Басу Арташ, Татар Икшермәсе мәктәпләрендә укый. Урта белемне 1941 елда Саба урта мәктәбендә алып чыга. Сугыш башлану аның бөтен хыялларын юкка чыгара. Яшь егеткә фронт буйлап сугышчан юл узарга туры килә. Шәхси батырлыгы өчен I дәрәҗә Ватан сугышы ордены, ике тапкыр «Батырлык өчен» медале һ.б. белән бүләкләнә.

1948 елда Ә.Кәримуллин белемен күтәрү теләге белән Казан дәүләт университетының татар бүлегенә укырга керә. Укуын тәмамлагач, университетның фәнни китапханәсендә эшли башлый. Китапханәдә эшләү дәверендә татар халкының тарихын, мәдәниятен, әдәбиятын, дөнья тарихында тоткан урынын аңлатуда берьяклы эш алып барылуына ачык төшенә.

Беренче эш итеп ул иске китапларның каталогын төзи башлый, биш-алты ел эчендә аларның исемлеген киң катлау укучыга тәкъдим итә. Ә.Кәримуллин татар теле һәм тел белеме, фольклор, Татарстан тарихына караган фән тармакларында аерым күрсәткечләр төзүгә ирешә. Шул ук вакытта бу елларда китапханә фондын иске кульязма китаплар белән тулыландыру да җайга салына; экспедицияләр оештырыла башлый, чит илләрнең фәнни оешмалары белән китап алмашу яңартыла. Нәтиҗәдә Европа, Азия, Америка, Австралия илләренең уку йортлары, фәнни оешмалары белән тыгыз бәйләнеш урнаша.

Әбрар Кәримуллин, күпкырлы галим булса да, гомере буе китап тарихы, библиография мәсьәләләрен үзәккә куеп эшли. Халык хәтере булган китап язмышы Ә. Кәримуллинның үз язмышына әверелеп яши. Китапка багышланган хезмәтләре аша ул татарның үзаңын үстерүгә сөйләп бетергесез зур өлеш кертә. Шулай да халкыбыз язмышына кагылышлы бер генә мәсьәлә дә читтә калмый. Ул – татарның чын тарихын торгызу эшендә дә үзеннән зур өлеш керткән галим.

Халкыбызның күренекле татар галиме, китап белгече, библиограф, филология фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Кол Гали исемендәге халыкара бүләк лауреаты, академик Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин 75 яшендә – 2000 елның 18 сентябрендә вафат була.

Укытучы. Әлеге карточкалар сездә кала, шуңа күрә әдипнең биографиясен дәфтәргә язып тормыйбыз. *(Дәфтәр эченә кую.)*

Укытучы. Бүген безнең дәресебездә кунак бар. Ул – Әбрар Кәримуллин исемендәге Саба үзәк китапханәсе директоры, безнең бик яраткан, озак еллар мәгариф өлкәсендә мактаулы хезмәт куйган Ләйсән Рәкыйп кызы Билалова. Хөрмәтле Ләйсән Рәкыйп кызы, сүз Сезгә. Рәхим итегез.

Ләйсән Рәкыйп кызы. Китап… Ике катыргы арасына тыгызлап тутырылган чуар кәгазь. Бары шул гына, ә яхшылап уйлап баксаң, китап ул – адәм балалары уйлап чыгара алган сирәк могҗизаларның могҗизасы. Әлбәттә, укый белгән кеше өчен.

Китап ул – бүгенге яшәешебез, киләчәгебез, ул – дога да, изге сүз дә…Татар халкы гомер-гомергә укымышлылыгы, гыйлемле булуы белән дан тоткан. Татар халкының күренекле фикер иясе, бөек мәгърифәтче, мәшһүр тарихчы һәм педагог Ризаэддин Фәхреддин дә: «Гүзәл китаплар — гаҗәеп әйберләр күренәчәк көзге, аулакта сердәш, ялгызлыкта иптәш, гаҗизлек вакытларда ярдәмче, хәсрәтләрдә шатлык китерүче, фикерләрне нурландыручы, үткән заманнар хәлләрен сөйләп торучы, өметләр, вакыйгаларны хикәят итүче, гакыллы кешеләрнең гакылларын күзләргә күрсәтүче аз хаклы, күп файдалы нәрсәләрдер. Шуның өчен китап алуда саранлык итмәгез, китаплардан аерылмагыз! Китап уку кешеләрнең йөзенә нур, күңелләренә шатлык китерер», – дип, үз фикерен җиткергән.

Китап! Гасырлар илчесе, тормыш көзгесе, белем чишмәсе, зирәк юлдаш, акыллы киңәшче һәм ышанычлы сердәш. Китап укыган кешенең фикере тирәнәя, зиһене арта. Китап, гомумән, әдәплелеккә, әти-әнине хөрмәт итәргә, Туган илне яратырга өйрәтә. Дөрес, күбегез инде үзегезгә кирәк материалны компьютердан гына укый. Ә кулыңа китап алып уку – үзе бер рәхәтлек.

Китап – белем чишмәсе, диләр. Укырга яраткан һәм укыганыннан акыл ала белгән кешене китап акны карадан аера белергә, тормышта югалып калмаска, хаталар ясамаска өйрәтә. Сез 2017 елдан башлап даими үткәрелә торган онлайн-проект – бүгенге көндә дөньякүләм «Әдәби марафон» бәйгесендә актив катнашып барасыз. Район күләмендә «Иң күп татарча китап укучы мәктәп» исеменә лаек булып, кубок һәм Саба үзәкләштерелгән китапханәсенең Рәхмәт хаты белән бүләкләндегез. Алга таба да һәр ел фасылының әдәби марафонында актив катнашып, татар милләтенең, туган телебезнең, туган җиребезнең хөрмәтле кешеләре булып яшәргә язсын!

Ләйсән Рәкыйп кызы. Әгәр китап сөйләшә белсә, ул сезгә нинди үтенеч белән мөрәҗәгать итәр иде икән? Китапның теләкләрен барлап, кагыйдәләр җыелмасы ясыйк әле. Эш парларда башкарыла.

(1. Караңгы урында укыма: күзләреңне бозарсың. Укыганда, яктылык күзләреңә түгел, китабыңа төшсен. 2. Китап битләрен ачканда, бармагыңны төкеректәмә, битләрне өстән, почмактан ача башла. 3. Тукталып калган урында карандаш яки тырнак белән эз ясама, кыстыргыч куй. 4. Китапны юешләтмә, кояшка куйма, югыйсә тышы кибеп кубар, битләре саргаер. 5. Рәсемнәрен буяма, ертылган битләрен ябыштыр. 6. Өстәлгә куйганчы, өстәл өстен кара: юеш түгелме, икмәк валчыклары юкмы? 7. Әгәр китаптагы әсәрне ошатып укыгансың икән, башка иптәшләреңә дә тәкъдим ит!)

V. Беренчел ныгыту этабы

Укытучы. Ә хәзер, укучылар, кроссенс (яңа буын башваткычы, «мәгънәләр кисеше») алымы ярдәмендә, әлеге рәсемнәрне билгеле бер тәртипкә куеп, галимнең тормыш юлын, эшчәнлеге буенча белемнәребезне ныгытып алыйк әле. Әлеге рәсемнәр әдипнең тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлеге белән ничек бәйле?





(Әбрар Кәримуллин 1925 елның 29 маенда Саба районы Чәбия Чурчи дигән гади татар авылында дөньяга килә. 1948 елда белемен күтәрү теләге белән Казан дәүләт университетының татар бүлегенә укырга керә. Укуын тәмамлагач, университетның фәнни китапханәсендә эшли, иске китапларның каталогын төзи башлый. Китапка багышланган хезмәтләре аша ул татарның үзаңын үстерүгә сөйләп бетергесез зур өлеш кертә. Аңа быел май аенда 96 ел тулды.)

Укытучы. Укучылар, ә сез китап турында ниләр белдегез? Ягез әле, сынап карыйк.

Ә хәзер эшебезне төркемнәрдә дәвам итәбез. LearningApps – интерактив күнегүләр конструкторы *(https://learningapps.org/display?v=pq8ivu8ka21)* ярдәмендә уен уйнап, белемнәребезне ныгытып алыйк. Китап турында мәкальләрнең бер өлеше бирелгән, дәвамын эзләп табып куярга кирәк. Төркемдәге һәр уенчыга актив булырга телим.

(Уен барышында түбәндәге мәкальләр бирелә.)

Китап *– белем чишмәсе.*

Китап *– тормыш көзгесе.*

Китап *– якын сердәш.*

Китапның *белмәгәне юк.*

Китапсыз өй *– тәрәзәсез бүлмә.*

Китап галим *– телсез мөгаллим.*

Күп укыган *күп белер.*

Күп йөргән күп белмәс *– күп укыган күп белер.*

Гыйлем акчага килми *– тырышлык белән килә.*

Уку каты булса да, *җимеше татлы.*

VI. Динамик пауза (ял минуты)

VII. Икенчел ныгыту этабы

Укытучы. Әйдәгез, материалны ничек үзләштерүебезнең дәрәҗәсен тикшереп карыйк. Белемнәребезне тест сораулары ярдәмендә тикшерәбез. Бирелгән бланкларга дөрес җавапларны билгеләп куярга кирәк. (Телефондагы ZipGrade – мобиль приложениесе белән тикшерү.)



1. Әбрар Кәримуллинга быел ничә яшь тулган булыр иде?

а) 90; **б) 96;** с) 95.

2. Университет тәмамлагач, кем булып эшли башлый?

а) укытучы; б) язучы; **с) китапханәче.**

3. Татар китабы тарихында ул иң беренче нинди эш башкара?

а) иске китапларның каталогын төзи;

б) халык авыз иҗаты белән шөгыльләнә;

с) әкиятләр иҗат итә.

4. Нинди Дәүләт бүләгенә ия була?

а) академик; **б) Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге;** с) галим.

5. Әбрар Кәримуллинны без кем буларак өйрәндек?

а) китапчы галим; б) язучы; с) укытучы.

VIII. Рефлексия этабы

Укытучы. Бүгенге дәрескә куелган максатыгыз үтәлдеме? Нәрсәләргә өйрәндегез? Кем турында сөйләштек? *(Укучыларның җаваплары тыңланыла.)*

Укытучы. Укучылар, әйдәгез, дәрес темасы буенча акросүз (бирелгән сүзнең мәгънәсенә яшерелгән аңлатма бирү алымы, ассоциация, туры килүче сүзтезмәләр) төзеп, бүгенге дәресебезгә нәтиҗә ясыйк әле.

Укучылар:

К – кабатланмас шәхес

И – ихтирамга лаек

Т – татар китабы фәненең аксакалы

А – академик дәрәҗәсенә күтәрелгән галим

П – парлы гомер кичергән

Ч – Чәбия Чурчи авылында туган

Ы – ышаныч яулаган

Г – гадел

А – абруйлы

Л – лаеклы

И – иске кульязма китаплар белән эш итә

М – милләтебезнең асыл бөртеге

Укытучы. Укучылар, сез барыгыз да яхшы эшләдегез. Дәрес башында эшчәнлекләрегезгә үзбәя бирергә тәкъдим иткән идем. Үзегезнең «Уңышлар карточкасы»н шушы тартмага салыгыз. Ә мин сезнең бу теманы ничек үзләштергәнегезне белермен һәм дәрестәге активлыкларыгызны да исәпкә алып билгеләр куярмын.

IX. Өй эше бирү

Укытучы. Киләсе дәрескә өй эше: сайлап эшләргә.

1. «Китап академигы» дип исемләнгән видео карарга *(https://yandex.ru/video/preview/?text=әбрар%20Кәримуллин%20видео&path=wizard&parent-reqid=1628274286780851-3055987053829035617-vla1-2477-vla-l7-balancer-prod-8080-BAL-3117&wiz_type=vital&filmId=14649367908121665334)* .
2. Китап турында шигырьләр укырга.
3. Әбрар Кәримуллинга багышлап, шигырь иҗат итәргә.

Укытучы. Саба ягында туып үскән Әбрар Кәримуллин могҗизаларның могҗизасы булган татар китабы фәненең аксакалы булып тарихыбызга кереп калды. Татар китабы яшәгәндә, аның исеме, эшләре дә онытылмас, буыннан-буынга, гасырдан-гасырга тапшырылыр. Ә сез, укучылар – халыкара исемнәргә, дәрәҗәләргә ия булган галимебезнең варислары. Милләтне, аның телен саклап калу өчен, сезнең арагыздан, һичшиксез, Әбрар Кәримуллинның эшен дәвам итүчеләр чыгарга тиеш. Туган телен яраткан, китапка хөрмәт белән караган бала белемле, аңлы, әдәпле, тәрбияле, күркәм кеше булып үсә. Мин сезнең шундый кеше булып үсүегезгә ышанам.

Тырышлык булса, уңышлар да булыр! Сау булыгыз, укучылар!

СЫЙФАТ ТУРЫНДА ТӨШЕНЧӘ

(6 нчы сыйныфта татар теле дәресе)

Елена АНДРЕЕВА,

Казандагы 68 нче урта мәктәпнең
I квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Максат:

– укучыларның сыйфат сүз төркеме турындагы белемнәрен гомумиләштерү;

– предметларның төрле билгеләрен белдергән сыйфатларны аера белү;

– сыйфатларның сөйләмдәге роле белән таныштыру.

Методлар: тәнкыйди фикерләү технологиясе алымнары буларак «Фишбоун», «Акыл штурмы» кулланыла, эвристик-өлешчә эзләнү, анализ, синтез.

Дәрес тибы: катнаш дәрес.

Төп төшенчәләр: сыйфат, фишбоун, сыйфатланмыш.

Предметара бәйләнеш: сәнгать, рус теле.

Эшне оештыру: фронталь, төркемнәрдә.

Дәреснең технологик картасы

Дәрес этаплары	Укытучы эшчәнлеге	Укучы эшчәнлеге	Универсаль уку гамәлләре
I. Ориентлашу-мотивлаштыру	Уңай психологик халәт булдыру. – Исәнмесез, укучылар. Хәерле көн! – Хәерле көн! – Кәефләрегез ничек? – Кояшлы көн кебек!	Сыйныф эшкә әзерләнә: укытучыны сәламлиләр, сорауларга җавап бирәләр, сөйләм эшчәнлегенә кушылалар.	**ШУУГ:** дустанә мөнәсәбәт, укучыга, укытучыга хөрмәт. **КУУГ:** сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү.

II. Актуальләштерү. Уку мәсьәләсен кую «Акыл штурмы» алымы	Ак яулыклы, көләч йөзле, Шат күңелле, әйбәт тә; Кем ул, диеп сорыйсызмы? Дәү әнием, әлбәттә! – Укучылар, шигырь кем турында? – Ә шигырь матурмы? – Ничек уйлыйсыз? Ни өчен матур? – Шигырь матур булсын өчен, шагыйрь нәрсәләр кулланган? – Бүген без төркемнәрдә эшләрбез. Һәр төркемнең алдында төрле биремнәр язылган конвертлар ята. «Хәрефләр» дигән конвертны ачабыз. Сез шул хәрефләрдән нинди сүз төзер идегез икән? Төркемнәрдә бергәләп эшлибез. – Димәк, бүген без акыллы, тырыш, бәхетле балалар белән сыйфат дигән серле, матур, нәзакәтле, чибәр, аллы-гөлле сүз төркемен өйрәнә башларбыз. Дәфтәрләрне ачып, бүгенге числоны һәм теманы язып куябыз. – Укучылар, бүген безнең дәресебездә сыйфатлар күп яңгырарга тиеш. Онытмагыз.	– Дәү әни. – Матур. – Сыйфатлар. – Акыллы, тырыш, бәхетле.	**ШУУГ:** үз уңышларының / уңышсызлыкларының сәбәпләре турында фикер йөртү. **РУУГ:** үз җавапларын телдән матур, дөрес итеп әйтә белү; дәреснең темасын, максатын формалаштыру. **КУУГ:** сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү.
III. Яңа белемнәрне формалаштыру. Проблемалы ситуация булдыру	– Укучылар, һәр төркемнең өстәлендә фишбоун рәсеме ята. Кем белә, фиш сүзе инглиз теленнән ничек тәрҗемә ителә? fish – балык, bone – сөяк – балык кылчыгы дип тәрҗемә ителә. Бу алымның авторы – менеджмент өлкәсендә эшләүче япон галиме. Алымның нигезендә балык кылчыгы формасында төзелгән диаграмма ята. «Балык кылчыгы» схемасы төрле авыр ситуацияләрдән, проблемалардан чыгу юлын күрсәтергә ярдәм итә. – Хәзер сезнең максат сыйфат турында нәрсәләр беләсез, шуны искә төшерергә һәм «балык кылчыгы» схемасына яза барырга кирәк. Балыкның башы бүгенге дәреснең темасы – «Сыйфат». – Әйдәгез, иң мөһименнән башлыйк. Сыйфат нәрсәне белдерә? – Укучылар, аңлатманы без балыкның өске ягына язабыз. Ә аскы ягына дәлилләр язабыз. Предметның билгесен белдергәнен ничек беләсез? – Сыйфат нәрсәне ачыклап килә? Ул ачыклап килгән исем ничек атала? Дәлил китерик. – Укучылар, без сезнең белән фишбоунның өчтән бер өлешен генә тутырдык әле. Алдагы сыйныфларда үтелгәннәрне искә төшерү өчен төркемнәрдә эзләнү эшләре алып барыйк. – «Биремнәр» дигән конвертны ачабыз.	– Предметның билгесен белдерә (фишбоун өске ягы). – *Нинди, кайсы?* сорауларын куеп (фишбоун аскы ягы). – Исемне. Сыйфатланмыш. – Кызыл калфак, яшел алма.	**ШУУГ:** әйләнә-тирәдәгеләрнең хисләрен, халәтләрен аңлап хезмәттәшлек итүгә әзер булу. **ТБУУГ:** үзеңнең белем системасында ориентлаша белү; текстны кабул итү, аның эчтәлегендә ориентлаша белү. **КУУГ:** үз фикереңне төгәл итеп җиткерә белү.

<table>
<tr>
<td>IV. Анализ, синтез, өлешчә эзләнү</td>
<td>– 1 нче төркем, сезгә бирем. Сүзтезмәләрне укыгыз, предметның билгесе кайсы яктан ачыклануын күрсәтегез, сорау куегыз. Фишбоунга язып куегыз.
Баллы чәкчәк, кызыл калфак, түгәрәк түбәтәй, ягымлы әни, кышкы итек, яңгырлы көн.
Нәтиҗә:
– Дәлиллибез.

2 нче төркем. Сүзтезмәләрне укыгыз, тәрҗемә итегез, нәтиҗә ясагыз.
Акыллы бала, акыллы балалар, акыллы баланың.
Нәтиҗә.
Дәлиллибез:
3 нче төркем. Җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерегез һәм нәтиҗә ясагыз.
Әни миңа алтын алка алды. Зәлия апаның алкасы алтын.
Нәтиҗә.
Дәлиллибез:

– Яхшы, укучылар. Булдырдыгыз. Укучылар, ә без сыйфатларны кайчан күп кулланабыз?

– Яхшы. Укучылар, ә менә бу чәчәк сезгә ошыймы? Ни өчен?
– Димәк, үзегез тутырган «балык кылчыгы» схемасына, шушы чәчәккә карап, алда әйтелгәннәргә таянып, сыйфат турында нәрсә әйтә аласыз? Ул безгә ни өчен кирәк? Нәтиҗәгезне балыкның койрыгына язып куегыз.
Нәтиҗә: димәк, укучылар, сыйфат предметның төрле билгеләрен белдерә һәм сөйләмне матурлый.</td>
<td>– Сыйфатлар төсне, тәмне, форманы, холыкны, вакытны, табигать күренешләрен белдерә.

– Сыйфат предметның төрле билгесен белдерә.

– Форма, төс, холык...

– Татар телендә сыйфат төрләнми.
– Акыллы баланың – у умного ребёнка.
– Сыйфат җөмләдә аергыч, хәбәр булып килә.
– Алтын алка – алка алтын.

– Әдәби әсәрләрдә, кешенең тышкы кыяфәтен, холкын, эчке кичерешләрен, табигатьне сурәтләгәндә.
– Матур булганга.

– Сыйфатлар да шушы матур чәчәк кебек безнең сөйләмебезне бизи.</td>
<td>ТБУУГ: төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру; яңа белемнәр табу, чагыштыру (рус-тат.).

РУУГ: хаталарны табу һәм төзәтү.</td>
</tr>
<tr>
<td colspan="4">Ял минуты. Укучылар, әйдәгез, уен уйнап, ял итеп алыйк. Сезнең алда – баскыч рәсеме. Ике төркемгә бүленәбез. Беренче төркем – шагыйрьләр, икенче төркем артистлар була. Баскычның өстендә картина куелган. Сез, шушы картинага туры килгән сыйфатлар кулланып, өскә таба менәргә тиеш. Кайсы төркем тизрәк булыр икән. Башладык!</td>
</tr>
</table>

V. Белем һәм күнекмәләрне камилләштерү	– Ә хәзер, укучылар, мин сезгә табышмаклар язылган карточкалар таратам. Сез шулардан сыйфатларны табасыз һәм предметның кайсы билгесен белдерә, шуны әйтәсез. Табышмакның җавабын да уйлагыз. Төркемнәрдә тиз генә эшләп алабыз. – «Мозаика уены»н уйнап алабыз. Бу уенны беләсезме? Безнең уенда төсле мозаиканы сыйфатлар үтәячәк. Аларның барысы да төрле-төрле. Дәреслекнең 47 нче битен ачабыз. 73 нче күнегү. Текст бирелгән, әмма анда сыйфатлар юк. Бу буш урыннарны сез мозаикадагы сыйфатлар белән тутыра аласыз. Сыйфатлар тактада бирелгән. – Укучылар, күргәнсездер инде бу сандык гади түгел, ә әбием сандыгы. Анда ниләр генә сакланмаган. Безнең татар халкы элек-электән гел шундый чиста, матур, пөхтә, чигүле киемнәр киярге яраткан. – Ә сезнең мондый матур киемнәрне күргәнегез бармы?	Төркемнәрдә эшлиләр. – Текстны укыйлар, тиешле сыйфатларны куялар. – Әйе. Минем әбиемдә бар. – Минем музейда күргәнем бар.	**РУУГ:** башкаларның сөйләмен тыңлый белү, аңлау, уңышлысын сайлау. **ШУУГ:** үзеңнең ни өчен эшләвеңне белеп эшләү; белем алу процессына уңай караш белдерү. **ТБУУГ:** фикерне аңлы һәм ирекле рәвештә телдән әйтеп бирү. **КУУГ:** төркемдә хезмәттәшлек. **РУУГ:** башкаларның сөйләмен тыңлый белү, аңлау, уку мәсьәләсен дөрес аңлау, үз эшчәнлекләрен планлаштыру.
VI. Нәтиҗә	– Укучылар, ә хәзер әйдәгез «балык кылчыгы» схемасына әйләнеп кайтыйк. Нәтиҗә ясыйк. Схемада әле урыннар калды. Димәк, алдагы дәресләрдә без сыйфат темасын өйрәнүне дәвам итәрбез.		

VII. Йомгаклау. Рефлексив кабатлау	– Яхшы, укучылар, дәрестә бик яхшы эшләдегез. Белемнәрегезне тикшереп карыйсыгыз киләме? Мин сезгә «Дулкын» дигән тест эшләргә тәкъдим итәм. Мин дәрес темасы буенча кагыйдәләр укырмын, ә сез дөрес булса дулкынны өскә ясыйсыз, дөрес булмаса аска ясыйсыз. 1. Сыйфат предметның билгесен белдерә. (+) 2. Сыйфат *ничек?, ни рәвешле?* сорауларына җавап бирә. (–) 3. Сыйфат ачыклап килгән исем сыйфатланмыш дип атала. (+) 4. Җөмләдә сыйфат тәмамлык булып килә. (–) 5. Татар телендә сыйфатлар төрләнми. (+) – Ә хәзер дәфтәрдәге дулкыныгызны безнең бүгенге дәреснең алтын балыгы йөзә торган дулкын белән чагыштырыгыз. Хатасыз – «5»ле 1 – 2 хата – «4»ле 3 – 4 хата – «3» ле	Һәр укучы мөстәкыйль рәвештә тестны башкара.	**РУУГ:** бәяләү, хаталарны табып төзәтү. **ШУУГ:** үз уңышларың /уңышсызлыкларың турында фикер йөртү. **КУУГ:** телнең сәнгати чараларын кулланып, үз фикереңне әйтә белү, тормыш тәҗрибәсен куллану. **ТБУУГ:** фикер йөртүнең логик чылбырын төзү.
VIII. Индивидуаль рефлексия	Тактага «Иҗат агачы» эленә. Укучыларның алларында чәчәк, яшел яфрак, сары яфрак рәсемнәре ята. *Чәчәк* – дәрес яхшы узды. *Яшел яфрак* – дәрес файдалы булды. *Сары яфрак* – дәрес начар узды.	«Иҗат агачы»на һәркем үзе сайлаганны чыгып беркетә.	
IX. Өй эше	**Чәчәк** билгесен сайлаучыларга *(экранда күрсәтелә):* Сыйфатларны кулланып, «Әбием калфагы» дигән кечкенә хикәя язарга. **Яшел яфрак** билгесен сайлаучыларга: Сыйфат кергән мәкальләр язарга. **Сары яфрак** билгесен сайлаучыларга: 76 нчы күнегү (язмача).		**ТБУУГ:** белем дәрәҗәсеннән чыгып, өй эшен сайлап алу.

13

БӘЙЛЕК СҮЗЛӘР

(6 нчы сыйныфта татар теле дәресе)

Рушания ГАППАСОВА,

Казандагы 39 нчы урта белем бирү мәктәбенең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Максатлар:

Белем бирү – бәйлек сүзләр белән таныштыру, сөйләмдә дөрес кулլануны ныгыту.

Фикер сәләтен үстерү – кара-каршы сөйләшү нигезендә укучыларның сөйләм осталыкларын арттыру, чагыштыра, нәтиҗә ясый белү, дәлилли белү күнекмәләрен үстерү.

Тәрбияви – укуда тырышлык һәм теләк күрсәтүнең әһәмиятенә басым ясау, булышырга, ярдәм итәргә теләк белдерү формасын өйрәнү.

Көтелгән нәтиҗәләр:

Предмет буенча: бәйлекләр турында алган белемнәрен системалаштыру.

Шәхси: яңа материалны өйрәнүгә, танып белүгә кызыксыну күрсәтү; уку эшчәнлегендә уңышка ирешүнең сәбәпләрен аңлау (дисциплиналы булу, игътибарлы, җаваплы булу, хезмәт сөючән, үз көчеңә ышану).

Универсаль уку күнекмәләре:

Регулятив: дәрестәге эшнең максатын укытучы ярдәмендә ачыклау.

Танып белү: укучыларның һәм укытучының уртак эше буенча нәтиҗәләр ясау.

Коммуникатив: башкаларның сөйләмен тыңлау һәм аңлау; бергә эшләү процессында, фикерләр каршылыгы булганда да, сыйныфташлар белән уртак фикергә килергә кирәклеген аңлау.

Планлаштырылган нәтиҗә:

Предмет буенча: «Бәйлекләр» темасына караган сүзләрне практикада куллана белү.

Метапредмет: лексик-грамматик күнекмәләрне системалаштыру; ишетеп аңлау күнекмәләрен ныгыту; мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерү;

укытучы ярдәмендә дәреснең максатын куя, эшчәнлекнең планын билгели һәм коллективта эшли белү.

Җиһазлау: проектор, ноутбук, презентация, татар халык бию көйләре, татарча-русча сүзлекләр.

Дәрес тибы: яңа белемнәрне формалаштыру.

Ресурслар: «Сәлам» дәреслеге, Фәтхуллова К.С. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту: укытучылар өчен методик кулланма. 6 нчы сыйныф .

Өстәмә: үз-үзеңне бәяләү алгоритмы.

Эшчәнлекне оештыру: фронталь, группаара, индивидуаль.

I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

Оештыру өлеше.

– Исәнмесез! Хәлләрегез ничек? Авырмыйсызмы? Сәламәт булу өчен нишләргә кирәк?

«Сәлам» УМКсыннан 3 нче сыйныф «Спорт» модуле (1 нче дәрес, 1 нче бирем), «Сәламәт бул» модуле (1 нче дәрес, 2 нче бирем) аудио тыңлыйлар.

– Бер-беребезгә сәламәтлек телибез!

II. Уку мәсьәләсен кую

Актуальләштерү.

(2 нче слайд)

Укытучы. Укучылар, тактага карагыз. Тактада бәйлек сүзләр язылган. Җөмләләрдә урын мәгънәсен белдерә торган кайбер исемнәр бәйлек ролендә килергә мөмкин. Бу бәйлек сүзләр төрле килеш формасында булалар.

– Бәйлекләрнең мөстәкыйль мәгънәләре бармы? *(Юк, алар җөмләдә сүзләрне бәйләү өчен генә хезмәт итәләр.)*

Укытучы. Мисалларга карагыз, бүген дәрестә кайсы бәйлекләр турында сөйләшәбез?

III. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү

– Дөрес, укучылар, бүген дәрестә без сезнең белән бәйлек сүзләр белән танышабыз.

– Дәреслекләрегезнең 28 нче битен ачыгыз, 5 нче күнегү.

Игътибар белән укып чыгыгыз. Бәйлек сүзләрнең тәрҗемәсен истә калдырыгыз.

IV. Яңа материалны аңлату

1. (3 нче слайд)

(Тактада таблица)

Укытучы. Бәйлек сүзләр кайсы килешләрнең формасында булалар? (Юнәлеш к., ур.-вакыт к., чыгыш к.) Бәйлек сүзләр үзләреннән алда килгән сүзнең билгеле бер килештә торуын таләп итәме? *(Юк.)*

Дәреслекләрегезнең 28 нче битен ачыгыз, 6 нчы күнегү.

(4 нче слайд) Тикшерү:

1) уйныйлар

2) кайта

3) очалар

4) үсә

5) чык

6) утыртты

7) уза

8) ява

9) билгеләделәр

2. Ял минуты

V. Яңа материалны ныгыту

1. (5 нче слайд)

– Тактада бирелгән җөмләләрдә төшеп калган бәйлек сүзләрне языгыз. Җөмләләрне тәрҗемә итегез. (*Эш дәфтәрендә.)*

1. Бакча … кып-кызыл җиләкләр пешеп утыра.
2. Урман … кошлар тавышы ишетелә.
3. Каникуллар ай … башлана.
4. Төлке ….. … йөгереп китте.
5. Сабантуйны … … киң болында үткәрәләр.
6. Яңа журналны … … тутыра башлыйлар.

2. (6 нчы слайд)

Ситуатив биремнәр эшләү. (Телдән)

Посоветуйте другу:

1. Одному не ходить в сторону леса.
2. С начала месяца запланировать свои дела.
3. В середине сада посадить красивые цветы.

3. (7 нче слайд)

Дәреслек буенча эш.

28 нче бит №7 (дәфтәрдә)

29 нчы бит №8 (телдән)

4. (8 нче слайд)

Тестны эшлә. Пройди тест.

1. Найди словосочетание с ошибкой.

а) бакчага уртасына, в) бакча уртасында, б) бакча ягында, г) бакча артында.

2. Укажи лишнее слово.

а) өс, ә) иң, б) ас, в) арт, г) ал, д) урта, е) ян, ж) як, з) эч.

3. Найди слово, противоположное по значению алдында.

а) өстендә в) артында

б) янында г) эчендә

4. Поставь подходящее по смыслу слово.

Тау ... бик күп еланнар һәм аларның патшасы – Зилант яшәгән.

а) уртасында в) астында

б) башында г) янында

5. Сүзләрнең тәрҗемәсен тап. Найди перевод слов.

Урман ягына с начала месяца

Бакча уртасына в сторону леса

Ай башында в начале месяца

Бакча уртасында на середину сада

Урман ягыннан в середине сада

Ай башыннан со стороны леса

6. Җөмләләрне язып бетер. Допиши предложения.

1) Балалар тау өстеннән ... .

2) 6 нчы сыйныф башында ... .

3) Тартма эчендә ... .

VI. Рефлексия

– Без бүген нәрсә турында сөйләштек? Дәрестә нәрсәләр өйрәндек, нишләдек? Димәк, үзебез өчен нинди нәтиҗә ясыйбыз.

VII. Йомгаклау: үз-үзеңне бәяләү алгоритмы

Оцениваем сами себя. Если вы на сегодняшнем уроке: поняли всё – 100%, то подпишите зелёный кружочек; поняли половину, не всё – 50%, то подпишите жёлтый кружочек; если не поняли вообще ничего 0%, то красный кружочек.

VIII. Өй эше. **(9 нчы слайд)**

1. 28 нче бит, №5 өйрәнергә.
2. Бәйлек сүзләр белән 3 җөмлә язарга.

14

ЭНДӘШ СҮЗЛӘР

(6 нчы сыйныфның рус төркемендә татар теле дәресе)

Лилия ТИМЕРГАЛИЕВА,

Казандагы 57 нче урта мәктәпнең
I квалификация категорияле
татар теле укытучысы

Максат:

Фәнни максат: эндәш сүзләр турында гомуми мәгълүмат бирү.

Коммуникатив максат: фикерле белү сәләтен үстерү; укучыларның сөйләм байлыгын үстерү.

Тәрбияви максат: тел матурлыгы кешенең иң зур байлыкларының берсе икәнлеген аңлату.

Дәрес тибы: яңа теманы өйрәнү.

Җиһазлау: экран, проектор, ноутбук, мөстәкыйль эш өчен карточкалар, дәреслек.

Дәрес барышы

1.Оештыру моменты.

– Исәнмесез, укучылар!

– Исәнмесез!

– Хәлләрегез ничек, балалар?

– Яхшы. Ә сезнең хәлләрегез ничек?

– Минем дә хәлләрем бик яхшы.

– Хәлләрегез турында сөйләшеп алыйк әле.

– ...

– Ты у кого это спрашиваешь?

– У Камиля.

– Ребята, как называются слова, с помощью которых мы можем к кому-то или к чему-то обратиться?

– Обращение.

– Правильно. Обращение – это лицо или предмет, к которому обращается говорящий.

– А в татарском языке они называются ***эндәш сүзләр*. (1 нче слайд)**

Димәк, без сезнең белән бүгенге дәрестә нинди теманы өйрәнәбез?

– Эндәш сүзләр.

2. Яңа белемнәр бирү.

– Мәктәптә нинди эндәш сүзләр әйтәбез?

– Дус, иптәш, сыйныфташ, укытучы, укучы, балалар... *(Телдән җөмләләр төзү.)*

– Мәктәптән без өйгә, гаиләбезгә кайтабыз. Гаиләдә нинди эндәш сүзләр кулланып сөйләшәбез?

– Әти, әни, бабай, апа... А к дочке или к сыну как обращаются?

– Сынок или доченька. **(2–3 нче слайдлар)**

– Дөрес. Правильно. Ә татарча ничек була? Ишеткәнегез бармы?

– Улым, кызым була**. (4 нче слайд)**

– Әйдәгез, укучылар, гаиләдә нинди эндәш сүзләр кулланасыз. Телдән җөмләләр төзибез.

– ...

– Ә хәзер диалогларны тулыландырабыз. **(5 нче слайд)**

– Ура, ..., мин бүген математикадан контроль эштән «5»ле алдым!

– ...! Мин бик шат!

– ...! Мин бик бәхетле бүген!

– Ә мин ничек бәхетле, ...!

(Кадерле әнием, акыллым, алтыным минем, әнием.)

– Укажите в диалоге обращения.

– ...

– Как выделяют обращения на письме?

– Обращения выделяются запятыми и восклицательным знаком.

– Скажите, укучылар, где могут находиться обращения в предложении?

– ...

– Да, правильно. Если обращение находится в середине предложения, то оно выделяется двумя запятыми.

– А дома как к вам обращаются? Родители используют ласковые слова? А вы?

– ...

– Татар телендә дә мондый сүзләр бар. Менә алар: алтыным – золотце моё, акыллым – умница мой (умница моя), кояшым (солнышко

моё), матурым (красотуля), кадерлем (дорогой(ая) мой(моя), сөеклем (любовь моя), җаным (душа моя). **(6 нчы слайд)**

Ял минуты

(Музыка астында, физик хәрәкәтләр ясау.)

Камыш кебек үсәбез,

Тал кебек бөгеләбез.

Уңга карап елмаябыз,

Сулга карап елмаябыз,

Артка карап алабыз да

Алга таба барабыз.

(Рәхмәт, урыннарга утырабыз.)

– Кадерле укучыларым, утырыгыз. Мин сезгә ничек эндәштем?

– ...

– Кадерле – какая часть речи? Мы можем рядом с обращениями прилагательные поставить. А какие? Эндәш сүзләр янында нинди сыйфатлар куеп була?

– Дорогой, любимый, уважаемый, милый, единственный…

– Татар телендә слайдтагы сүзләр еш кулланыла.

Ә хәзер слайдтагы сүзләр белән эшлибез.

Сүзлек өстендә эш **(6 нчы слайд)**

Кадерле

Сөекле

Яраткан

Хөрмәтле

Бердәнбер *(Слайдтагы сүзләрне сүзлек дәфтәрләренә язабыз.)*

Дәфтәрдә шул сүзләр белән сүзтезмәләр төзибез.

– ...

– Эндәш сүзләрне ныгытабыз. Китапларны ачтык: 152 бит 2 күнегү **(7нче слайд)**

– ...

– Эндәш сүзләр темасы белән таныштык, һәм без сезнең белән кызыклы һәм иҗади эш эшлибез. Аны сез төркемнәрдә эшлисез. Шушы ватманга котлау открыткасы язып карыйсыз (поздравительную открытку с днём рождения). А поздравительную открытку мы с вами сделаем знаете кому?

– ...

– Вашей однокласснице, которая учится в другой группе. И это ей будет сюрприз. Из каких частей состоит поздравление? **(8 нче слайд)**

– Котлау открыткасын язабыз. Сезгә терәк сүзләр бирелә. Шуларны кулланыгыз. **(9 нчы слайд)**

– Молодцы! Бик матур открытка килеп чыкты!

– Ә нинди мөһим әйбер җитми бу открыткада?

– Эндәш сүз.

– Ә бу открытка кемнәрдән?

– Сыйныфташларыңнан.

– Димәк, тормышта эндәш сүзләр кирәкме?

– Кирәк. Ә ни өчен? Для чего?

– ...

– Әйе, бик дөрес.

Йомгаклау

Дәрес буенча сораулар бирү.

– Без нәрсә турында сөйләштек?

– ...

Кто доволен своей работой на уроке? (красные смайлики) **(10 нчы слайд**)

А кто не очень доволен своей работой? (синие смайлики) **(11 нче слайд)**

2) Билгеләр кую. *(Һәр укучы үзенең үзбәясен тапшыра.)*

Өй эше

1) Эндәш сүзләр кертеп, җөмләләр төзергә.

2) Әниегезгә бәйрәм открыткасы язарга.

3 нче төр өй эше слайдта. **(12 нче слайд)** Слайдтагы эндәш сүзләрне сезгә өй эшенә тәрҗемә итәргә бирәм.

Кадерле укучыларым, якыннарыгызга эндәш сүзләрнең иң матурларын кулланып эндәшегез. Дәресемне дә шушы слайдтагы Г. Сәгыйровның шигырь юллары белән тәмамлыйсым килә:

Кадерлем, назлым, сөеклем,

Карлыгачым, былбылым;

Җаным-бәгърем, күгәрченем,

Таң йолдызым, күз нурым!

(13 нче слайд)

15

ТУГАН ТЕЛЕМ – ДУСЛЫК ТЕЛЕ

(7 нче сыйныфта исем, сыйфат, сан сүз төркемнәрен кабатлауга багышланган татар теле дәресе)

Ләйсән ВӘЛИЕВА,

Арча районы Иске Чүриле урта мәктәбенең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Максат:

– исем, сыйфат, сан сүз төркемнәре турында белемнәрне искә төшерү;

– исем, сыйфат, сан сүз төркемнәрен сөйләмдә урынлы куллана алуларына ирешү;

– туган телебез белән горурлану хисләре тәрбияләү.

Дәрес тибы: белем һәм күнекмәләрне ныгыту дәресе.

Төп төшенчәләр: исем, ялгызлык, уртаклык, килеш, сан, тартым, тамыр, ясалма, мәгънә, сыйфат, дәрәҗә, ясалыш.

Предметара бәйләнеш: татар әдәбияты, рус теле.

Эш төрләре: әңгәмә, биремнәрне аерым-аерым үтәү, текст белән эш, сәнгатьле уку.

Җиһазлау: сүз төркемнәре язылган таблица, текстлар, терәк схема, үзбәя картасы, буклет.

Дәрес барышы

I. Дәресне оештыру. Уку эшчәнлеген мотивлаштыру

Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру.

Укытучы. Укучылар! Карагыз әле, менә тагын яңа көн туды. Исән-сау булуыбызга, үзебезнең туган җиребездә, әти-әниләребез янәшәсендә бәхетле яшәвебезгә, яраткан мәктәбебездә белем алуыбызга тагын бер кат шатландык. Әйдәгез, шундый матур теләк-омтылышлар, сөенеч-шатлыклар белән дәресебезне башлап җибәрик.

II. Белемнәрне актуальләштерү

Укытучы. Укучылар, без сагынып көткән, тик бик тиз узып киткән җәйге яллар турында сөйләшеп алыйк әле. Әйдәгез, бер уен уйнап алабыз, ул «Дәвам ит» дип атала. Мин башлыйм, минем фикерне икенче укучы дәвам итәр, аның фикерен – өченчесе... Ә соңгы укучы фикерне йомгаклап куярга тиеш була.

– Эх, рәхәт итеп ял иттек тә соң җәйге каникулларда!.. *(Балалар чират буенча җавап бирәләр.)*

Укытучы. Җәйге ялларыгызны бик матур итеп уздыргансыз икән. Сер булмаса, әйтегез әле, каникулларда дусларыгыз белән нинди телләрдә аралаштыгыз? *(Укучылар җавабы тыңланыла.)* Димәк, туган телебез аша күп дуслар тапкансыз. Бүгенге дәресебезне «Туган телем – дуслык теле» дип атасак, сез килешәсезме?

Укучылар, җәйге каникулдан соң инде хәзер яңа көч белән белем алырга килдегез, шулай бит? Бүген инде ничәсе? *(Тактада число языла.)* Атнаның ничәнче көне? Ничек дип атала? Бүген көн нинди? *(Укучылар җавабы.)*

Укытучы. Укучылар, җавапларыгызда нинди сүз төркемнәренә кергән сүзләрне кулландыгыз?

Укучылар. Исем, сыйфат, санны.

Укытучы. Димәк, без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшербез?

Укучылар. Сүз төркемнәре турында.

III. Дәреснең темасын һәм максатын ачыклау

Укытучы. Сез 6 нчы сыйныфта бик күп сүз төркемнәре белән таныштыгыз. Бүгенге дәрестә аларны тагын бер тапкыр искә төшереп китәрбез, грамматик үзенчәлекләрен искә төшерербез, әлеге сүз төркемнәренә морфологик анализ ясарбыз.

IV. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү

1. Тукталышлар алымын кулланып, кечкенә хикәятләр белән танышу.

Укытучы. Укучылар, бүгенге дәресебез башкалардан үзгәрәк булыр: без сезнең белән иҗат итәрбез. Мин сезгә бүген бер хикәя алып килдем, ә без аны кызыклы алым белән укырбыз. Мин укый башлыйм һәм иң кызык урынында туктыйм, ә сез дәвам итәргә тиеш буласыз. (**Искәрмә.** *Күп нокталар куелган урыннарда тукталыш ясала һәм укучыларга әсәрне үзләре теләгәнчә дәвам итү мөмкинлеге бирелә.)*

– Сез иҗат итәргә әзерме? *(Хикәяне тукталышлар белән уку.)*

«Рамил 6 нчы сыйныфта укый. Сыйныфта акыллы, белемле, чибәр егет булып санала ул. Һәр көн иртә белән мәктәп юлында үзе шикелле бер матур кыз белән юллары кисешә. Аның менә шушы кыз белән бик-бик танышасы килә.

Беркөнне ул, бөтен батырлыгын җыеп, сүз башлады:

– Привет, как у тебя дела?

Кыз күз кырые белән генә карап алды да Рамилне бөтенләй күрмәгәнгә сабышып, ашыга-ашыга китеп барды».

Укытучы. Укучылар, кыз нигә шулай китеп барды икән? Ник Рамилнең сәламен алмады?

Укучылар. Ул аңа ошамады, шикләнде, курыкты...

Укытучы *(хикәяне укуын дәвам иттерә). «Рамил бик аптырады. Нигә Рамилгә җавап бирмәде икән ул? Башка кызларның бит Рамил белән дуслашмыйча, сәламенә җавап бирмичә калганнары юк иде.*

Дәресләр беткәнен көтеп җиткерә алмый тилмерде Рамил. Алтынчы дәрес бетүгә, чыгу юлына йөгерде. Чү, әнә бит, ул киенеп чыкканчы, туңдырма сата торган апа янына барып җиткән түгелме? Рамил уктай шунда атылды. Килеп җиткәнче үк, ул сатучы апа белән әлеге кызның сөйләшүен ишетте. Алар саф татарча аралашалар иде. Рамилнең күзләре янып китте».

Укытучы. Балалар, Рамил нигә шулай шатлана икән?

Укучылар. Кызны күргәнгә, кызны куып җиткәнгә...

Укытучы. *«Татар кызы икән бит! Үзебезнеке!» Рамилнең башына килгән иң беренче фикер шушы булды.*

– Сезне сыйларга мөмкинме? – дип сүз башлады ул. – Нинди туңдырма яратасыз?

Кызның йөзе кояштай балкый иде».

Укытучы. Укучылар, ә кыз нигә сөенде икән?

Укучылар. Туңдырма белән сыйлаганга, егет кабат аңа эндәшкәнгә.

Укытучы. *«– Сез татар егетемени? Татарча беләсезмени?*

Менә бит татарча эндәшмәгәч җавап бирмәгән булган икән! Бер-ике минуттан Рамил кызның Нәфисә исемле икәнен, параллель сыйныфта укуын

белә иде инде».

Укытучы. Бу кечкенә генә хикәядән нинди нәтиҗә ясап була, укучылар?

Укучылар. Туган телдә аралашырга кирәк.

Укытучы. Ә ни өчен нәкъ шушы мәсьәләгә тукталдым икән? Бу ел Татарстанда нинди ел дип игълан ителде? Шул уңайдан мәктәбегездә нинди эшләр башкарыла? *(Экранда логотип чыга.)* Укучылар, әлеге хикәя дәресебезнең темасына туры киләме, дәлилләп карагыз әле.

2. Әлеге текст ярдәмендә исем һәм сыйфат сүз төркемнәре турында белемнәрне гомумиләштерү.

Укытучы. Укучылар, экранга карагыз әле. Анда терәк схема бирелгән. Сезнең белемнәргә таянып, без бу схеманы бергәләп тутырырбыз. *(Слайдта күп нокталар урынына куелырга тиешле сүзләрне укучылар әйтә, аннары гына ачыла.)*



Казан шәһәр

Алия кыз



– Берлек – Күплек	Баш килеш Иялек килеше Юнәлеш килеше Төшем килеше Чыгыш килеше Урын-вакыт килеше	**Минем китабым** **Синең китабың** **Аның китабы** **Безнең китабыбыз** **Сезнең китабыгыз** **Аларның китаплары**

Укытучы. Ә хәзер тексттан исемнәрне табып языйк. Әмма бөтен исемнәрне дә түгел, мин сезгә грамматик билгеләрен әйтәм, сез шуңа туры килгән исемнәрне табып язасыз. *(Эш тактада һәм урыннарда башкарыла, сүзләр баганалап языла.)*

– Ялгызлык исемнәрне табып языбыз.

– Күплек сандагы ике исем языбыз.

– Тартым белән төрләнгән бер исем табып языбыз.

– Укучылар, тексттан нинди килештәге исемнәр табарсыз икән?

– Телдән генә бер исемгә морфологик анализ ясыйбыз, ә схема сезгә ярдәмче булыр. *(Укучылар үзбәя карталарында үзләренең белемнәрен бәяли.)*

Укытучы. Укучылар, тактадагы сүзләр нәрсәне белдерде? *(Предметны.)*

– Ә хәзер шулар янына билгене белдергән сүзләр өстәп әйтик әле. Нинди сүзләр өстәдек? *(Сыйфатларны.)*

– Укучылар, сыйфатлар безгә ни өчен кирәк?

– Ә хикәядә без Рамил белән Нәфисәнең нинди булуларын күрдек?

– Ә нинди булырга тырышырга кирәк, укучылар?

Укытучы. Укучылар, менә бу өстәлдә кәгазьләрдә терминнар бирелгән. Әйдәгез, шулар арасыннан сыйфатка караганнарын тактаның менә бу өлешенә урнаштырыйк әле. *(Укучылар ни өчен бу терминны алганнарын дәлилләп китә.)*

– Укучылар, ә калганнарын ни өчен алмадыгыз? Алар турында нәрсә әйтә аласыз? Әйдәгез, аларны тактаның менә бу өлешенә урнаштырыйк әле. *(Укытучы язуларны күтәреп күр-*

сәтә, бергәләп аңлаталар һәм тактаның сан дигән өлешенә урнаштыралар.)

3. Дәреслек буенча эш.
(12 нче күнегү, 7 нче бит.)

Укытучы. Укучылар, сан төркемчәләрен искә төшереп китик әле. Моның өчен сезгә дәреслектәге 12 нче күнегү ярдәм итәр. Җөмләләрне укыйбыз, саннарны табып, төркемчәләрен билгелибез. *(Укучылар күнегүне эшли.)*

Укытучы. Укучылар, менә без өч сүз төркемен дә искә төшереп үттек. Бу схемалар сезнең юл карталарыгызда бирелгән, өй эшен башкарганда, ул сезгә ярдәм итәр, дип ышанам.

V. Өй эше бирү

Укытучы. Өй эшләре юл картагызга язылган:

1. Хикәядән берәр исем, сан, сыйфатка морфологик анализ ясарга.
2. Рамил белән Нәфисәнең дуслыгын ничек күз алдына китерүегез турында хикәяне дәвам иттерергә.
3. Туган тел турында биш мәкаль язып килергә.

VI. Укучыларның белемен бәяләү

Укучыларга, дәрестә катнашканнарын бәяләп, билгеләр куела.

VII. Рефлексия

1. Рефлексив кабатлау.

Укытучы. Укучылар, сез бүгенге дәрестән нинди белемнәр, уй-кичерешләр алып китәсез?

2. **Укытучы.** Балалар, Рамил белән Нәфисәгә кабаттан әйләнеп кайтыйк әле.

– Әйдә, ..., син ... Рамил булырсың, ә син ... Нәфисә булырсың. Сезне бирегә чакырам.

– Рамил, син – чын татар егете. *(Кәләпүш кидертәм.)*

– Нәфисә, син – чын татар кызы. *(Калфак кия.)*

– Рамил, Нәфисә өчен туган телдә сөйләшү мөһим икәнен аңладың инде, синең өчен туган тел нәрсә ул?

– Ә Нәфисә ничек уйлый?

– Рәхмәт, балалар! *(Беләзек кидертәм.)*

– Ә калган укучыларның фикерләрен беләсе килә. *(Калган укучылардан да сорыйм. «Туган тел синең өчен нәрсә ул?» дигән сорауга җавап әйтергә тиешләр.)*

Укучылар. Туган тел ул – әти-әнием теле, туган йорт, туган җир, туганнарым, телем ачылган тел, Тукай теле, безнең тарихыбыз, милли тел, татар теле, дәүләт теле...

Укытучы. Ә минем өчен:

Туган тел ул Ватан белән

Һәрчак бер рәттә торыр:

Кол Шәрифтәй иманлы ул,

Сөембикәдәй горур.

Милләтемне мәгърифәткә,

Гыйлемгә һәрчак әйди:

Тукаебыз кебек бөек,

Әлифба кебек гади.

Укучылар, туган телегез гомерегез буена йөрәк түрегездә саклансын, аны балаларыгызга, оныкларыгызга тапшыра алсагыз иде. Туган телебездә сөйләшик, аны кадерлик, күз карасыдай саклыйк! Бүгенге дәрес күңелләрегездә онытылмаслык хатирә булып калса иде.

Презентациясе белән журнал сайтында https://magarif-uku.ru/tt/tugan-telem/ адресы буенча танышырга мөмкин.

16

СЫЙФАТ ФИГЫЛЬ

(8 нче сыйныфның татар төркемендә татар теле дәресе)

Гөлнара КАМАЛИЕВА,

Казандагы 57 нче урта мәктәп-нең I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Максат:

– сыйфат фигыль турында мәгълүмат бирү;

– сыйфат фигыльне сөйләмдә куллану күнекмәсен булдыру, башка сүз төркемнәреннән аера белү; мөстәкыйль фикерләүгә ирешү;

– әти-әнигә хөрмәт хисе тәрбияләү.

Планлаштырган нәтиҗәләр: сүз төркеме буларак сыйфат фигыльләрне таный, аера һәм куллана белү.

Дәреснең тибы: яңа белемнәрне үзләштерү дәресе.

Төп төшенчәләр: сыйфат фигыль.

Предметара бәйләнеш: әдәбият, рус теле.

Эшне оештыру төрләре: фронталь, индивидуаль, парлап һәм төркемнәрдә эшләү.

Чыганаклар: дәреслек.

Өстәмә: слайдлар, карточкалар, сканворд, таблицалар, күнегүләр җыентыгы.

Дәрес барышы

Оештыру моменты (1 мин)

Хәерле көн! Исәнмесез! Бүгенге көн сезгә шатлык, бәхет кенә китерсен, йөзегездәге елмаюлар беркайчан да сүрелмәсен. Менә шундый матур теләкләр белән дәресебезне башлап җибәрәбез.

Өй эшен тикшерү (3–4 мин)

– Сезнең алдыгызда бәяләү таблицалары бар. Дәрес дәвамында шушы таблицага үзегезгә бәя биреп, таблицаны тутырасыз. Укучылар, хәзер өй эшен тикшерәбез. Ул 3 төрле иде. Таблицада 1 нче пункт – өй эше графасы. Сорауларга җавап биргәндә, сканвордны чишәргә кем чыга? *(Тактага чыга эшли.)*

1. Тестны тикшерәбез. Слайдта дөрес җаваплар, үз-үзегезне тикшерегез. Карточка «Дәвам ит» (Фигыль – ... *(зат яки предметның эшен, хәрәкәтен, хәлен, торышын белдерә, нишли? нишләде? нишләр? сорауларына җавап бирә. Заман, юнәлеш белән төрләнә, барлык-юклыкта килә.)* (Сыйфат – ... *(предметның билгесен белдерә, исемне ачыклап килә. Нинди? кайсы? сорауларына җавап бирә.)*

2. ТЕСТ (7–8 сорау) (3–4мин)

1. Сыйфат нәрсәне белдерә?

а) предметны;

ә) эшне;

б) исемне;

в) предметның билгесен.

2. Синоним сыйфатлар язылган рәтне табыгыз.

а) кысан, иркен;

ә) озын, кыска;

б) таләпчән, тырышкан;

в) тырыш, эшчән.

3. Сыйфат җөмләдә нәрсәне ачыклап килә?

а) санны; б) рәвешне;

ә) исемне; в) фигыльне.

4. Фигыль нәрсәне белдерә?

а) предметны;

ә) предметның билгесен;

б) предметның эшен, хәрәкәтен;

в) предметның санын, микъдарын.

5. Фигыль нинди сорауларга җавап булып килә?

а) кем? нәрсә? ни?

ә) нишли? нишлиләр?

б) нинди? кайсы?

6. Фигыльләр нәрсә белән төрләнә?

а) заман белән;

ә) килеш белән;

б) барлык-юклык белән;

в) заман, зат-сан, юнәлеш белән.

3. Сканворд

Үз-үзегезне тикшерегез. Сканвордтагы сүзләрне укыгыз.

с	а	р	ы	а	к
с	ы	й	ф	а	т
а	л	к	а	р	а
у	с	ф	ш	ә	м
з	ә	и	у	к	ә
г	ң	г	й	ы	х
ә	р	ы	л	ь	ә

Слайдта дөрес җаваплар.

– Яхшы, балалар. Сез өй эшен дөрес башкардыгыз, билгеләрегезне куегыз. Бу белемнәр безгә кирәк булачак. Дәресебез бүген гадәти түгел. Өй эшләре күнегүләреннән без нинди сүз төркемнәре турында кабатладык? *(Сыйфат һәм фигыль.)*

– Әйе, без сыйфат һәм фигыль сүз төркемнәрен кабатладык. Бүгенге дәрестә кагыйдәләрне биография дип атыйк. Биография нәрсә ул? Искә төшерик әле.

(1нче слайд) Биография – кемнең дә булса тормыш юлы тасвирламасы, тәрҗемәи хәле. (Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда: 1 том. – Казан:Татарстан китап нәшрияты, 1977.– 166 б.)

– Укучылар, бүген без дәрестә яңа сүз төркеменең биографиясен әкияти формада язарга тырышырбыз.

(2 нче слайд) Картина.

– Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер гаилә: патша белән патшабикә. Патшаның исеме – Фигыль, патшабикәнең исеме Сыйфат булган. Бала булса, гаилә тулы һәм бәхетле була. Көннәрдән бер көнне боларның бик матур кызлары туган, ди. Аларның холык, сыйфатлары балага күчкән. Бу бала әтисенә дә, әнисенә дә охшаган.

Аңа нинди исем кушканнар дип уйлыйсыз?

– **Сыйфат фигыль** дип исем кушканнар.

Әйе, Фигыль әтисе кебек ул телепортацияне, ягъни вакыт буенча төрле заман формаларын алган, эшләргә һәм хәрәкәт итәргә яраткан, юнәлеш формаларын алган, барлыкта-юклыкта килгән, зат-сан белән төрләнмәгән – **затланышсыз фигыль** булган.

Әнисе – Сыйфат кебек ул нинди? соравына җавап биргән, исем алдында килгән, ә кайвакыт исемләшкән, җөмләдә аергыч булып килгән. **(3 нче слайд)**

Әти-әнисен бик **ярата торган бала** булган. (А4 тактада эленә.)

(4 нче слайд) Әти-әнисен бик ярата торган бала булган. Бу җөмләдә сыйфат фигыльне табыгыз.

(Ярата торган бала.) Әйдәгез, тикшерик, әти-әнисеннән нинди сыйфатлары күчкән?

Сыйфат	Фигыль
Предметның билгесен белдерә.	Предметның эшен, хәрәкәтен, хәлен белдерә.
Нинди? кайсы? сорауларына җавап бирә.	Нишли? нишләде? сорауларына җавап бирә.
Сыйфатлар асыл һәм нисби булалар. Асыл сыйфатлар дәрәҗә белән төрләнәләр.	Заман, юнәлеш белән төрләнә, барлыкта-юклыкта килә. Зат категориясенә мөнәсәбәте ягыннан барлык фигыльләр затланышлы һәм затланышсыз булалар.
Җөмләдә аергыч булып килә.	Җөмләдә хәбәр булып килә.
Сыйфат фигыль үзендә берьюлы сыйфат һәм фигыль билгеләрен берләштерә.	
Нинди? соравына җавап бирә.	
Эш-хәлне предметның билгесе итеп белдерә.	
Заман, юнәлеш белән төрләнә, барлыкта-юклыкта килә. Затланышсыз фигыль.	
Җөмләдә аергыч булып килә.	

Соравы нинди? (Нинди бала?)

Кайчан ярата? *(Хәзер.)* (Үткән заман кушымчасы дип уйлыйсыз, чыннан да, *-ган* – үт.з.кушымчасы, ләкин монда *-а* кушымчалы хәл фигыльгә *торган* ярдәмче фигыле кушылып ясала. Шуңа бу – хәзерге заман сыйфат фигыль. Укучылар, сыйфат фигыльнең заманнарын икенче дәрестә тирәнтен өйрәнәчәкбез.)

Барлыктамы, юклыктамы *(ярата торган – яратмый торганмы?)*, зат-сан белән төрләнми.

Нәрсә алдында килә? *(Исем алдында килә.)*

Җөмләнең нинди кисәге? *(Аергыч.)*

Тәрҗемә итегез әле. *(Любящий ребёнок.)* Рус телендә ничек атала? *(Причастие.)*

(5 нче слайд) Укытучы сөйли. Сыйфат фигыль ясагыз.

– Мин сөйлим, мин нинди укытучы? *(Сөйли торган укытучы, сөйләүче укытучы.)*

Тәрҗемә итегез. *(Говорящий учитель.)*

Рус теле белән чагыштырыйк. Рус теле белән охшашмы? *(Әйе. В русском и татарском языках. Признаки? Признаки одинаковые (обозначает признак по действию. – Эш-хәлне предметның билгесе итеп белдерә.)*

Сораулары? *(Задаём одинаковые вопросы: какой учитель? – Нинди укытучы?)*

Җөмләдә нәрсә булып килә (одинаковые члены предложения – аергыч, определение).

(3 мин)

Әйе, укучылар, без рус теле белән дә чагыштырдык.

– Ничек уйлыйсыз? Дәрескә нинди максатлар куябыз? *(Сыйфат фигыль турында өйрәнәбез.)* (6 мин)

Дәфтәрләрне ачабыз. Теманы язабыз. *(Тактада тема.)* Хәзер китапларыбызда бирелгән 125 нче күнегүне эшлибез. Кагыйдәне укыйбыз. Нинди ике баганага бүләбез? (Проблемалы сорау.) *(Предметның билгесен белдерсә – сыйфат сүз төркеме, икенчесендә предметның билгесен эше аркылы белдерсә, сыйфат фигыль була.)* Тактада эшлибез. Ике укучы кирәк. Син сыйфатларны яз, ә син сыйфат фигыльне яз. Калганнар дәфтәрдә эшләп, дөреслеген тикшерегез. (3 мин)

Сыйфат	Сыйфат фигыль
Матур көн	Күтәрелгән җир
Көзге көн	Кире кайтарылган хат
Ак кар	Сибелгән ярма
Батыр егет	Көтелгән кунаклар
	Җыештырылган бүлмә
	Өлгергән башаклар

Таблицага үз бәягезне куярга онытмагыз. *(Ике укучыны укытучы бәяли.)*

Дәресебезне дәвам итәбез. Укучылар, бирелгән җөмләләрдән сыйфат фигыльләр ясап карагыз әле.

Сезнең алда карточкалар. Бу эшне парларда эшлибез.

Карточкада эш. (Парлап эш) (126 нчы күнегүдәге кебек) (4 мин) Карточкада калын хәрефләр белән бирелгән фигыльләрнең нинди сорауларга җавап бирүен киңәшләшеп ачыклагыз һәм берегез җөмләдә хәбәр, икенчегез җөмләдә аергыч булган очракны языгыз.

Казан – күпне **күргән** шәһәр.

Кунак **кайткан** өйнең тәрәзәләрендә төнгә кадәр ут сүнмәде.

Казан вакыйгаларны күп **күргән.**

Күрше йортка кунак **кайткан**.

Кайсы пар укый?

(6 нчы слайд) Берегез җөмләдә хәбәр булган очракны языгыз.

Казан вакыйгаларны күп **күргән.**

Күрше йортка кунак **кайткан**.

Икенчегез җөмләдә аергыч булган очракны языгыз.

Казан – күпне **күргән** шәһәр.

Кунак **кайткан** өйнең тәрәзәләрендә төнгә кадәр ут сүнмәде.

Бу күнегүләрдән соң фигыльләр арасындагы уртаклык һәм аермалы якларны әйтегез әле. Аермасы –(бер очракта хәбәр була, икенче очракта аергыч була.)

Охшашлыгы? (Балалар җавабы: язылышы, әйтелеше охшаш. фигыльгә дә, сыйфатка да охшаш.)

Ял минуты. Күзләргә гимнастика.

Эшебезне дәвам итәбез. Төркемнәрдә эшлибез. Карточкаларда мәкальләр бирелгән. Төшеп калган сүзләрне туры китереп языгыз. Бу мәкальләрнең мәгънәсен аңлатабыз. 1 нче төркемгә 1 нче мәкаль, икенче төркемгә – 2 нчесе, 3 нчегә – 3 нчесе, ә сезгә – 4 нчесе.

1) Анасына ... (өргән) эт бүре авызына төшәр. (8 мин)

2) Ата-ананы ... (тыңлаган) бала – адәм булган,

... (тыңламаган) бала – әрәм булган.

3) Әни... (суккан) авыртмый.

4) Ата сүзен ... (тыңламаган) баланы атауга (утрау– остров) ыргытканнар.

Нинди сүзләр төшеп калган?

– Сыйфат фигыльләр.

Мәгънәләрен тикшерик. 1 нче төркем укыгыз. *(Әниләргә каршы әйтергә ярамый, балага начар була, бәхетсез була.)*

2 нче төркем. *(Әти-әниләрне тыңларга кирәк, алар дөрес киңәш бирәләр.)*

3 нче төркем. *(Әни сукса да онытыла, чөнки ул әни.)*

Сугу сүзенең туры мәгънәсе генә түгел, балалар. *(Орыша, өйрәтә.)*

Укытучы. 4 нче төркемнең мисалында искергән сүз бар – *атау* сүзе, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә утрау дип бирелгән (остров). Әйдәгез, 4 нче төркем мәкальнең мәгънәсен әйтегез.

4 нче төркем. *(Ата сүзен тыңларга кирәк. Әтисе сүзен тыңламаган баланы беркем яратмый, хөрмәт итми. Әти сүзе – Закон.)*

Бу мәкальләрдән нинди нәтиҗә чыгарабыз. *(Әти-әни – дөньяда иң кадерле кешеләр. Без аларның сүзләрен тыңларга тиешбез. Хөрмәт итәргә, кадерләргә, сакларга тиешбез.)*

Иҗади эш. Төркемнәрдә эш.

РАУНД – РЕЛЛИ ТЕЙБЛ (Өстәлдә берүк вакытта төркемдә эшләү.) Бирелгән җөмләләрне укып, дөрес урнаштырып, шигырь барлыкка килсен. Кайсы төркем тизрәк һәм дөрес эшли. (3 мин)

Җирдә миңа ни кирәк?

Әти дә әни кирәк!

Җирдә миңа ни кирәк?

Без яшәгән өй кирәк!

Әти дә әни кирәк!

Без яшәгән өй кирәк! *(Ш.Галиев)*

Кем тизрәк төзеде. Укыгыз. (Сезнең вариантта отышлы, яхшы. Ә менә Ш.Галиевтә болай бирелгән.)

Сыйфат фигыльне кем таба? Исбатлагыз. (Яшәгән (өй) – сыйфат фигыль, нинди өй? Җөмләдә аергыч булып килә.)

(7 нче слайд)

Рефлексия (3 мин**)**

Укучылар сыйфат фигыль турында нәрсәләр белдек?

(8 нче слайд) Сыйфат фигыль таблицасы (балалар әйтеп бара, слайдта чыгып бара).

Сыйфат фигыль үзендә берьюлы нинди сүз төркемнәренең билгеләрен берләштерә? *(Үзендә берьюлы сыйфат һәм фигыль билгеләрен берләштерә.)*

Нәрсәне белдерә? *(Эш-хәлне предметның билгесе итеп белдерә.*)

Сораулары? *(Нинди? соравына җавап бирә.)*

Җөмләдә нәрсә булып килә? *(Җөмләдә аергыч булып килә.)*

Нәрсә белән төрләнә*? (Заман, юнәлеш белән төрләнә, барлыкта-юклыкта килә. Затланышсыз фигыль.)*

Дәрес сезгә ошадымы?

Барысы дә аңлашылдымы?

Үзеңнең дустыңа теманы аңлата алырсыңмы? Нинди дәрәҗәдә үзләштердең? (Бер-ике баладан сорарга.)

Дәрес барышында сез үзегезгә билгеләр куйдыгыз, шул таблицаларыгызны миңа бирегез. Билгене куярмын. Сыйфат фигыль турында без өйрәнүне алдагы дәресләрдә дә дәвам итәрбез. Хәзер көндәлекне ачып, өй эшен язабыз. Сайлап эшләп килегез.

Өй эше (1 мин).

1) китаптан кагыйдәне өйрәнергә;

2) гаилә темасына карата сыйфат фигыльләр язарга;

3) «Гаиләм» темасына сыйфат фигыльләрне кулланып, хикәя язарга.

Сез бүген дәрестә актив эшләдегез, җавап бирергә тырыштыгыз, фикерләрегезне әйттегез. Афәрин, рәхмәт!

Бәяләү таблицасы

Өй эше	125 нче күнегү	Тәрҗемә-чагыштыру күнегүләре	Карточ-када эш	Мә-каль	Иҗади	Рефлек-сия	Гомуми билге

1) Анасына ... эт бүре авызына төшәр.

2) Ата-ананы ... бала – адәм булган,

... бала – әрәм булган.

3) Әни ... авыртмый.

4) Ата сүзен ... баланы атауга (утрау) ыргытканнар.

(тыңламаган, суккан, тыңламаган, өргән, тыңлаган)

Казан – күпне күргән шәһәр.

Күрше йортка кунак кайткан.

Кунак кайткан өйнең тәрәзәләрендә төнгә кадәр ут сүнмәде.

Казан вакыйгаларны күп күргән.

Р.ФӘХРЕДДИННЕҢ «ӘСМА, ЯКИ ГАМӘЛ ВӘ ҖӘЗА» РОМАНЫ

(9 нчы сыйныфта татар әдәбияты дәресе)

Айгөл ӘХМӘТШИНА,

«Адымнар-Алабуга» күптелле белем бирү комплексының I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Максат:

– укучыларны тәкъдим ителгән әсәрдәге вакыйгалар һәм образлар бирелеше буенча эзлекле фикер йөртергә, әсәрдә күтәрелгән проблемаларга карата шәхси мөнәсәбәтне белдерергә өйрәтү;

– тәнкыйди фикер йөртергә өйрәтү; бәйләнешле сөйләм үстерү;

– гаделлек, саф күңеллелеккә омтылу, тырышлык, намуслык кебек әхлак сыйфатларын тәрбияләү.

Планлаштырылган нәтиҗә: «Әсма, яки Гамәл вә җәза» романын анализлау.

Предметара бәйләнеш: татар әдәбияты, әйләнә-тирә дөнья.

Эшне оештыру төрләре: фронталь, индивидуаль, төркемнәрдә эшләү.

Чыганаклар: дәреслек (Хәсәнова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М., Гарифуллина М.Я. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен. – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2019), интерактив такта, презентация.

Дәрес тибы: рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

Дәреснең технологик картасы

Дәрес этаплары	Укытучы эшчәнлеге	Укучылар эшчәнлеге	Универсаль уку гамәлләре
I. Ориентлашу-мотивлаштыру	Укучылар белән исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру. Интерактив тактада язылган мәкальләрне, канатлы сүзләрне укырга тәкъдим итү («Ни чәчсәң, шуны урырсың» *(Татар халык мәкале)*, «Шәригать үлчәвеннән тыш мал сөймәгез, теләкләрегезгә әсир булмагыз». *(Р.Фәхреддин)*	Укучылар диалогта катнашалар, укыйлар, әдәп-әхлак нормаларын искә төшерәләр.	*КУУГ:* сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү. *ШУУГ:* үзмаксат кую.

II. Уку мәсьәләсен кую	Дәрес эпиграфлары белән эшләү, мәгънәсен аңлату. – Балалар, игътибар белән интерактив тактага карагыз әле. Сез бу ике җөмләнең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? Алар арасында уртаклык бармы? – Укучылар, сезнеңчә, әлеге акыллы фикерләр безнең дәрес темасына ни дәрәҗәдә туры килә? – Укучылар, сезнеңчә, әлеге акыллы фикерләр безнең дәрес темасына ни дәрәҗәдә туры килә?	Диалогта катнашалар, сорауларга җавап бирәләр. **Көтелгән җавап.** Мәкальдә начарлык эшләмәү, башкаларга карата мәрхәмәтле булырга өндәү турында әйтелә, чөнки синең кылган һәр эшең ахыр чиктә үзеңә бумеранг рәвешендә кайтачак. Р.Фәхреддин исә, нәфескә бирелеп, хәрәм мал, ягъни законлы юл белән табылмаган малга кызыкмаска, җинаять юлына басудан сакланырга чакыра. Уртаклык: җинаятьчелек кебек начар гамәл кылсаң, ирегең чикләнү, гомерең өзелү кебек җәзасын татуың бар. Яхшы күңелле булсаң, тормышың да тынычлыкта узачак. Көтелгән җавапларда үтелә торган әсәрдә җинаять кылган кешеләрнең җәза алып, бәхетсезлеккә, я үлемгә дучар булулары, сабыр, инсафлы геройларның бәхеткә лаек булулары турында сүз бара, дигән фикер яңгырый.	*ТБУУГ:* танып белү мәсьәләсен мөстәкыйль ачыклау һәм максат кую. *РУУГ:* кагыйдә, инструкцияләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу. *КУУГ:* коллектив фикер алышуда катнашу.
III. Танып белү эшчәнлеге. Уку мәсьәләсен чишү *(очраган авырлыкларны билгеләү һәм авырлыктан чыгу юлын табу)*	– Укучылар, әсәрне укыганда нинди авырлыклар белән очраштыгыз, барысы да аңлашылдымы? – Әйдәгез, шул сүзләрнең мәгънәсен «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ннән эзләп карыйк.	Укучылар *риясыз, тәкъвалы, нәфес коллары, тәрәккый, мөрит, ишан, мәхәллә, әһел, вәкарьле, мәслихәт* кебек сүзләрнең мәгънәләрен аңламаска мөмкин. Сүзлек белән эшлиләр, аңламаган сүзләрнең мәгънәсен теркәп куялар.	*ТБУУГ:* уку мәсьәләсен чишүдә логик фикерләү, төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру. *КУУГ:* үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү. РУУГ: үз эшчәнлегеңне контрольгә алу.
	Ял минуты		
IV. Яңа белемнәрне ачу	– Укучылар, текст буенча башка авырлыклар юк, дидегез, әйдәгез, әсәргә тагын бер мәртәбә игътибар юнәлтеп, төп геройларга характеристика бирик.	Роман тексты өстендә эшлиләр, образларны тасвирлаган, характеристика биргән урыннарны билгелиләр.	

	(Укытучы образларга характеристика буенча юнәлеш бирә, образларның гаилә хәле, социаль чыгышы, аңа хас әхлак сыйфатлары, башкаларга һәм үз-үзенә мөнәсәбәте, сөйләшү стиле һәм теленә, авторның геройга мөнәсәбәтенә игътибар итәргә кирәклегенә басым ясый.)	Укытучы биргән юнәлешкә нигезләнеп, укучыларның характеристикаларында Әсманы ата-анасы кечкенәдән белемгә, сабакка өйрәтүе ассызыклаWнып, ата-ананың, кызга бәхет сорап, һәрдаим Аллаһыга мөрәҗәгать итүләре, Әсманың авыр көннәрдә (теләнче булып йөрергә мәҗбүр ителгән вакытта) эчке көчен, намусын саклап калуы; Хикмәт хаҗи турында сөйләгәндә, автор-хикәяләүченең тискәре мөнәсәбәте ачык чагылуы, аның турында «надан, риялы, тәкәббер» дип язуы, Хикмәт хаҗиның бик көнче икәнен чагыштырулар ярдәмендә тасвирлануы; Габбас мелла белән Хикмәт хаҗиның гаилә турындагы күзаллаулары туры килмәве нәтиҗәсендә конфликт тууы турында искә алыныр, дип көтелә.	
V. Яңа белемнәрне беренчел ныгыту	– Укучылар, төп геройларга характеристика дөрес бирелде, аларның вакыйгаларга катнашы ачыкланды. Шулардан чыгып, әсәрдә күтәрелгән проблемаларны күрсәтә алырсызмы?	Көтелгән җавапларда хатын-кызның гаилә коруга актив катнашы, яраткан кешесенә кияүгә чыгарга хокукы проблемасы, хатын-кыз иреге мәсьәләсенең куелышы, уңай чишелеше; белем һәм тәрбия бирүдәге катлаулы мәсьәләләрнең ахыргача хәл ителмәве, бары тик Габбас мелла кебек зирәк, укымышлы кешеләрнең дөрес тәрбия бирергә сәләтле икәнлеген ассызыклау, иске карашлы муллаларның халыкны милли үзаңы үсешен тоткарлавы турында фикерләр әйтелә.	*ТБУУГ:* уку мәсьәләсен чишүдә логик фикерләү, төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру. *КУУГ:* үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү. *РУУГ:* үз эшчәнлегеңне контрольгә алу.
VI. Мөстәкыйль эш	– Укучылар, дәрес башында без эпиграфлар укыган идек. Әйдәгез, аларны әсәрнең исеме белән чагыштырып карыйк. – Балалар, гамәл вә җәза тезисын дәфтәргә таблица рәвешендә язып, исбатлап карагыз.	Әсәр геройлары үрнәгендә гамәлнең нәтиҗәсе үзең өчен яхшылык яки яманлык белән тәмамлануы эшнең яхшы яисә яман булуына бәйле икәнлеген исбатлыйлар. Мәсәлән, Габбас мелла – уңай герой – белемле, кызына яхшы тәрбия бирә, мәхәллә халкына карата гадел, ышанычлы, нахакка гаепләнә – бәхетле финалга лаек була, кызы белән очраша, яхшы мәктәптә мөгаллимлек итә.	*РУУГ:* үзконтроль, биремнәрне үтәүнең дөреслеген тикшерү. *ТБУУГ:* уку мәсьәләсен чишүдә логик фикерләү, төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру.

VII. Төркемнәрдә эш	– Укучылар, төркемнәрдә фикер алышыгыз, сорауларга җавап әзерләгез. – Әсәрдә сурәтләнгән тискәре күренешләр безнең җәмгыятьтә очрыйммы? Җавабыгызны дәлилләгез. – «Байлык – бер айлык мәкале», «Шәригать үлчәвеннән тыш, мал сөймәгез, теләкләрегезгә әсир булмагыз» гыйбарәсе романдагы кайсы очракка туры килә? – Әсма, бозык юлга кереп китмәс өчен, көчне кайдан таба?	Күтелгән җавапларда укучылар хәзерге вакытта да ялганчылык, мәкерлек, гаепсез кешегә нахак гаепләр тагу, фахишәлек, теләнчелек, кеше урлау кебек куркыныч проблемалар, җинаятьләрнең таралыша алуын искәртәләр; байлыкның вакытлыча булуын Хикмәт хаҗи тормышы мисалында дәлилләр; Әсманы рухи көчле итеп үстерүдә гаилә тәрбиясенең йогынтысын ассызыклыйлар.	*ШУГГ:* үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау. *ТБУУГ:* фикерләүдә логик чылбыр төзү. *РУУГ:* эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү. *КУУГ:* мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү, иптәшеңнең гамәлләрен бәяләү.
VIII. Уку эшчәнлеген йомгаклау. Рефлексия. Өй эше	– Укучылар, бүгенге дәрес сездә нинди тәэсирләр калдырды? – Укучылар, Ризаэддин Фәхреддин – киңкырлы шәхес. Бүген без аның әдип буларак талантын ачтык. Ә бит ул – күренекле галим дә. Өйдә Р.Фәхреддиннең галим буларак эшчәнлегенә күзәтү ясап килегез. Алдагы дәрестә без шул хакта әңгәмә корачакбыз. Сау булыгыз!	Дәрес уңай тәэсир калдырды, дигән җавап күтелә, кимчелекле яклар аталса, алар анализлана. Саубуллашалар.	*ШУУГ:* үз уңышларың /уңышсызлыкларың сәбәпләре турында фикер йөртү. *РУУГ:* үз эшчәнлегеңне контрольгә алу.

18

М. МӘҺДИЕВНЫҢ «КЕШЕ КИТӘ – ҖЫРЫ КАЛА» ПОВЕСТЕНДА РУХИ-ӘХЛАКЫЙ МӘСЬӘЛӘЛӘР ЧАГЫЛЫШЫ

Людмила ВОРОБЬЕВА,

Казан шәһәренең 177 нче лицейның югары квалификацион категорияле туган (татар) тел укытучысы

Планлаштырылган нәтиҗәләр:

Метапредмет: татар әдәбиятын рус әдәбияты, тарих белән бәйләп өйрәтү.

Предмет: «Кеше китә – җыры кала» повестен (өзекне) анализлау, укучыларда монологик һәм диалогик сөйләм күнекмәләрен камилләштерү.

Шәхескә кагылышлы: укучыларда милләтебезгә хөрмәт, горурлык хисләре, авыл кешеләренә карата игътибарлылык, дуслык, бердәмлек, гафу үтенә белү осталыклары тәрбияләү.

Материал:Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.

Җиһазлау: Мөхәммәт Мәһдиев портреты, «Милли әдәбият китапханәсе» әсәрләр җыентыгы, «Кеше китә – җыры кала» повестеның аудиоязмасы https://old.tatkniga.ru/media-book/rus/mohhamed-mahdiev-keshe-kite-zhyry-kala.html

Дәрес барышы

I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

1. Дәресне оештыру, исәнләшү.
2. Өй эшен тикшерү.
3. Укытучы укучыларга шигырь юллары укырга тәкъдим итә.

Сугыш, ачлык, ятимлек
Көч-куәтне тәмам бетерде.
Авырлыкка алар бирешмәде,
Шул бердәмлек – җиңү китерде.
Сугыш газапларын алар күмәкләшеп,
Иңне-иңгә куеп үткәрде.

Укучылар шигырьне укыйлар һәм тәрҗемә итәләр.

1.Сүзлек эше.

(Ятим – сирота.

Көч-куәт – сила, мощь.

Газап – мучение, страдание.

Иңгә-иң – плечом к плечу.

Бердәмлек – единство.

Бирешмәде – не сдался.

Күмәкләшеп – коллективно.)

2. Бирелгән шигырь буенча әңгәмә кору.

–Бу шигырьдә сүз нәрсә турында бара?

–Авырлыкларга ничек каршы торырга була?

3. Шигырьнең эчтәлеген ачыклау өчен, төп сүзләрне аерып чыгару.

II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү

1. Дәреслек белән эш. *(Укытучы берничә өзек тәкъдим итә.)*

А) Без яши белмәдек синең белән. Тормышның кадерен белмәдек. Юкка-барга сүз чыгарып, синең җаныңны яраладым. Шуның өчен җәза бу. Сугыштан исән кайтсаң, яши белер идек. Иң матур вакытларыбызны юк-бар сүз белән әрәм иттек. Без яши белмәдек...

Ә) Бәхил булыгыз, туганнар, дуслар... Безгә кайтулар булмас инде. Әйе, кайтулар – икеле. Бәхил булыгыз. Тату яшәгез. Үпкәгез булса – онытыгыз.

Б) –Иптәшләр, – диде ул, – бу сугыш канлы, корбанлы булыр. Ә сез җебеп төшмәгез. Колхозны үзебез төзедек, шуны саклагыз. Бер-берегезгә ярдәмче булыгыз. Колхозны аяктан екмагыз, иптәшләр, сау булыгыз...

Бирелгән өзекләр белән сүзләр арасында тәңгәллек урнаштырыгыз. (Бердәмлек, татулык, гафу үтенү.)

2. Бирелгән мәкаль-әйтемнәр кайсы өзекләрнең эчтәлегенә туры килә?

А) Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар.

Ә) Кош канаты белән, кеше дусты белән көчле.

Б) Гафу итә белгән кеше – көчле кеше.

3. Өзекләрнең эчтәлеге буенча әңгәмә кору.

– Татулык-дуслык төшенчәсен ничек аңлыйсыз?

– Ни өчен ачу сакларга ярамый?

– Бүгенге көндә бердәмлек төшенчәсе актуальме? Ни өчен?

4. Дәфтәрдә эш.

Укучылар иҗади эш башкаралар: төп һәм ярдәмче образларны аерып чыгаралар һәм аларны холыклары буенча ике төркемгә бүләләр. *(Үзләре һәм җәмгыять өчен яшәүчеләр.)*

III. Рефлексия

1.– Укучылар, бүген дәрестә нинди мәсьәләләр күтәрелде?

– Бу мәсьәләләр нинди геройлар мисалында чагылыш тапкан? Мисаллар белән дәлилләгез.

2. Бирелгән гыйбрәтле хикәяне тәрҗемә итегез.

Ученик спросил у учителя:

– Ты такой мудрый, никогда не злишься. Помоги и мне быть таким.

Учитель согласился и попросил принести картофель и прозрачный пакет.

– Если ты на кого-нибудь разозлишься или затаишь обиду, то напиши на картофеле имя человека, с которым произошёл конфликт, и положи его в пакет. Ты должен всегда носить этот пакет с собой.

Спустя время пакет наполнился и стал тяжёлым.

– Это уже невозможно носить с собой. Пакет тяжёлый, а картофель испортился.

– Каждый раз, когда ты решишь обидеться или обидеть кого-то, подумай, нужен ли тебе этот груз? – сказал учитель.

3. Йомгак ясау. Өй эше.

А) Тәрҗемә ителгән өзекнең проблемасын күрсәтергә һәм мисаллар белән дәлилләргә.

Ә) Буктрейлер ясарга.